Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 34 (1399) 2 сентябрь 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

6

Татар дөньясы өчен алдынгы карашлы, белемле, зыялы кешеләр үстергән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бүген дә дәрәҗәсен югары тота.

12

Асия ханым татар милли киемнәренә киендереп бизәгән курчаклар Париж, Мюнхен, Ганновер тамашачыларын да сокландырган.

14

Чын-чынлап халык шагыйре булган Нажар ага Нәҗми белән күрешү көнендә жылы бер хатирә булып уелып калды...

Тормыш шавына дәррәү кушылып Чыңлый мәктәптә тәүге кыңгырау!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов указы белән «Нур» Татар драма театры артисты Эльмир Газизуллинга һәм Мәскәүнең «Яңа опера» театры җырчысы, тумышы белән Казаннан булган Владимир Кудашевка «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

● Казанда Россиянең утыздан артык төбәгеннән килгән делегатлар катнашында Милли һәм төбәк гаммәви мәгълүмат чаралары форумы узды.

● Мәскәүдә узган Татарстан мәдәнияте көннәре кысасында балаларны «әкият аша» татар мәдәнияте белән таныштыру турында фикер алыштылар.

● Диния нәзарәтендә татар дин галиме, мәгърифәтче Морат Рәмзинең күренекле хезмәте – Коръән тәфсире иске татар теленнән хәзерге әдәби телгә күчерелә башлады.

● «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте беренче сыйныфка барачак 25 укучыга уку кирәк-яраклары салынган букчалар бүләк итте.

● Туймазы татар дәүләт драма театры Казахстанда узачак халыкара театр фестивалендә Илгиз Зәйниев пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Бәрһан йорты» спектакле белән катнаша.

● Төркиянең Бодрум шәһәрендә ачылган халыкара заманча сәнгать күргәзмәсендә татар рәссамы Айгөл Окутан эшләре тәкъдим ителә.

● 15-18 сентябрь көннәрендә Новосибирск шәһәрендә XIV Себер татар яшьләре фестивале узачак.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Васил ГАЙФУЛЛИН, педагогика фәннәре докторы, Татарстанның элекке мәгариф һәм фән министры:

«Хәзердән үк республикага физика, математика буенча 200әр укытучы җитми. Киләчәктә бит тагын да куркынычрак хәл булачак. Укытучысыз бер генә җәмгыять тә яши алмый. Ә без укытучысыз яшәргә җыенабыз... Шуңа игътибар итәргә кирәк. Элек Казан дәүләт педагогика университеты бар иде, аны бетерделәр, университетка куштылар, һәм әзерләү мәсьәләсе бөтенләй юкка чыкты. Болай булса, без киләчәктә белем бирүчеләр әзерли алмаячакбыз».

СЫНАМЫШЛАР

3 сентябрьдә көн аяз булса, шундый матур көннәр тагын 4 атнага сузыла ● 5 сентябрьгә кадәр торналар китсә, кыш иртә килә ● Сентябрьдә күк күкрәсә, көз озын һәм җылы була ● Сентябрьдә көннәр аяз торса, кыш салкын була ● Имәндә чикләвек күп булса, кыш салкын килә ● Сентябрь башларында тавык каурыйлары коя башласа, кыш суык була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 49 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 35 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **13 сәгать 46 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **9 сентябрьдә 13 сәгать 14 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

2 сентябрь – рәссам, график Рафаил Рәшит улы Кадыйровка 65 яшь (1957).

3 сентябрь – язучы Әбрар Гыйләҗетдин улы Шаминның тууына 110 ел (1912–1979).

7 сентябрь – сәнгать белгече, сәнгать фәннәре кандидаты Фирдәүс Гомәр кызы Ваһаповага 60 яшь (1962).

8 сентябрь – лингвист-тюрколог, җәмәгать эшлеклесе, филология фәннәре докторы Габделхәй Хурам улы Әхәтовның тууына 95 ел (1927–1986);

– Халыкара журналистлар бердәмлеге көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 6 сентябрь.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(3-10 сентябрь)** организм кинәнүгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

**Бүген сәфәр аеның
6 нчы көне**

ҖАН АВАЗЫ



Рүзәл ЮСУПОВ, академик

МАТБУГАТНЫ ЯРАТЫЙК

XXI гасырда, дөньяда югары цивилизация хөкем сөргән заманда, безнең татар матбугатының бәрәкәте кими бара: туган телебездә чыгып килгән газета-журналларның тиражлары күп тапкыр азайды, димәк, газиз телендәге матбугатны укучыларның сафлары да сирәгәйде. Яшермик, газеталарның эчтәлеге, сыйфаты, теле мәсьәләсендә дә проблемалар шактый күп.

Татарча матбугатның абруе төшү бигрәк тә мәдәниятебез, мәгариф һәм телебез өчен зыянлы. Чөнки халык үз телендәге газета-журналларны никадәр күбрәк укыса, алардагы язмалар ни дәрәҗәдә мәгънәле, үтемле һәм гыйбрәтле булса, милләттәшләребезнең рухи тормышларының иминлеге, камиллеге өчен моның файдасы шулкадәр зуррак булачак. Матбугат халыкка аның югары мәдәниятле тормышта яшәвенә дөрес юл күрсәтеп торырлык якты маяк булып хезмәт итәргә тиеш.

Моның өчен хәзерге шартларда безгә, Татарстан халкына һәм республика җитәкчеләренә, туган телләрендәге матбугаттан файдаланучыларның санын арттыру өчен нинди гамәлләр кылырга кирәк икән? Шушы хакта кайбер фикерләребезне уртаклашып алу мәгъкуль.

Халыкның матди һәм рухи тормышы өчен җаваплы рәсми затлар, бу әһәмиятле эш башында торып, татар матбугатын камилләштерүгә юнәлтелгән махсус программа төзеп, кичектермичә аны гамәлгә ашыруга керешсен иде. Программада матбугатны тиешле дәрәҗәдә тотуның конкрет чаралары, аларны гамәлгә ашыру юллары күрсәтелсен. Аңлашылаки, ул уңай нәтиҗәләргә китерерлек булсын өчен, бүгенге матбугатның хәлен, проблемаларын өйрәнеп, эшне яхшыртуга юнәлтелгән тәкъдимнәр туплау зарур. Бу мөһим документта мәдәниятле миллилек рухын саклау, туган телдә аралашуны көчәйтү һәм бигрәк тә халыкның милли аңын үстерү, сәламәт рухына, горурлык сыйфатларына ия булу һәм ныгыту бурычларын яктырту юллары бәян ителергә тиеш.

Газеталарның тиражын нинди чаралар күреп ишәйтергә мөмкин? Бу гаять катлаулы бурычны башкару Татарстан җитәкчеләренең төптән уйланылган житди гамәлләр кылуын һәм халыкның рухи тормышын җанландыруга багышланган активлыгын арттыруны таләп итә.

Беренчедән, хакимият органнарының җаваплы хезмәткәрләренә, халыкка татарча матбугатның әһәмиятен һәм аның милли мәдәниятебезне алга җибәрү өчен зарури чара икәнен аңлатып, халыкның мөмкин кадәр күбрәге газета-журнал укып барсын өчен, аз керемле кешеләргә махсус ярдәм оештыру турында уйларга кирәк. Матбугатны пропагандалау эшен оештыру максатында, җирле идарә органнарыннан, уку йортлары, радио-телевидение, җәмәгать оешмаларыннан файдаланырга мөмкин.

Газета-журналларны яздырып алуга ярдәм итү мәсьәләсендә хакимият органнары аз керемле кешеләргә дәүләт хисабына һич югында берәр республика газетасын бушлай алуны оештыра алыр иде. Матди хәлләре авыр милләттәшләргә матбугатны бушлай ирештерү өчен, зур суммадагы керемле (күп миллионлы) байларны җәлеп итәргә дә мөмкин. Газета-журналларның тиражын арттыру һәм, димәк, матбугатны укучыларны күбәйтү өчен, матбугатның сыйфатын яхшырту мөһим. Бүгенге көндә татарча газеталарның тематикасын киңәйтү, төрләндерү ихтыяҗы зур. "Мәдәни җомга"дан, "Безнең гәҗит", "Татарстан яшьләре" һәм "Сиражи сүзе"ннән кала газеталарда, гомумән алганда, халыкны кызыксындыра, борчый торган темаларга, тормыштагы җитешсезлекләрне, гаделсезлекләрне күрсәтүгә багышланган мәгълүмат аз, әһәмиятсез, вак-төяк хәбәрләр урнаштыру белән мавыгу күренеше хөкем сөрә. Татарча матбугатта хәзер, аеруча әһәмиятле проблемаларны анализлап, аларны хәл итүгә комачаулый торган затларны, кайбер җитәкчеләрнең халык мәнфәгатьләре белән исәпләшмәү очракларын принципиаль бәян итү җитми. Журналистларның күбесе тотрыклылыкны, тыныч яшәүне һичшиксез сакларга дип югарыдан килгән күрсәтмәләрне һәр очракта да тайпылышсыз үтәргә тырыша һәм тормышның уңай якларын гына игълан итү методы белән эш итә. Тормышта бары да ал да гөл генә түгел бит, җитешсезлекләр дә бик күп. Уңышлар белән бергә кимчелекләрне һәм тискәре күренешләрне дә күрсәтү фарыз. "Чирен яшергән үлгән" дип юкка гына әйтмиләр. Тормыш яхшырак булсын өчен, андагы начар якларны да тәгъбир итеп, алардан арыну чараларын тәкъдим итү зарур. Бу аксиома, һәм ул гомумән матбугат хезмәткәрләре эшенең төп методы булырга тиеш.

Югарыдан килгән хаксыз күрсәтмәләр һәм карарлар нәтиҗәсендә милли мәгарифнең нигезен какшатырлык гамәлләр кылына барганда, татарча матбугатның иң әһәмиятле бурычларыннан берсе – татар балаларына туган телләрен нәтиҗәле итеп укытудагы проблемаларны кыю һәм объектив итеп сурәтләү. Журналистлар татар халкының алдынгы милләт буларак уңышлы алга баруының нигезе татар мәктәпләренең нәтиҗәле эшләвендә икәнлегенә нык төшенеп эш итсен иде.

Газета-журналлар халык күңелен җәлеп итсен, кешеләр аларны үз итеп, яратып укысын өчен, тагын бер әһәмиятле шарт – матбугат теленең чын татарча, дөрес, үткен, тәэсирле булуы. Бик аяныч хәл: хәзер каләм ияләренең күбесе язмаларының уңышы шактый дәрәҗәдә телләренең ни дәрәҗәдә оста, матур, камил булуына бәйле икәнен, кызык, әһәмиятле эчтәлекле материал да, тупас ялгышлар белән чуарланып, кытыршы, авыр укыла торган телдә язылган булса, укучыда тиешле канәгатьләнү хисе тудырмаячагын, аның укучыга тәэсир итү көче кимиячәк икәнлеген уйлап бетерми. Газета-журналлардагы, бигрәк тә газеталардагы мәкалә, хәбәрләрнең теле күп очракта коры, "казенный" була, шуның өстенә, еш кына туган телнең табигый сөйләм кагыйдәләре, нормалары да бозыла. Аеруча русчадан тәрҗемә итеп алынган иҗтимагый-сәяси эчтәлекле материалларның телендә тупас ялгышлар җибәрелә, татар теленең үтемле, тәэсирле сүзләре урынына рус теленнән хәрефкә-хәреф тәрҗемә итеп (калькалаштырып) алынган чаралар кулланыла: табигый, матур туган тел төссезләндерелә, фәкыйрьләндерелә.

Татар матбугатының сыйфатын күтәрү белән шөгыльләнүчеләргә шуны искәртеп куюю мәгъкуль: журналистлар, халыкта милли горурлык хисләре уяту һәм ныгыту максатында, газета-журналларда милләтебезне хаклы рәвештә һәръяклап зурлап, олылап һәм күркәм итеп сурәтләү бурычын гамәлгә ашырсын иде. Югыйсә, әле безнең кешеләрдә үзләрен, түбәнсетеп, "өлкән туган" белән чагыштырганда, икенче сортлы итеп санау күренешләре аз түгел. Күп милләттәшләребезнең үз мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, традицияләренә битараф каравы, үз телендә сөйләшергә, аны өйрәнергә һәм балаларын да өйрәтергә теләмәве – күңелләрендә үз халкын ярату хисләренең бик сүлпән булуы, икенче төрле әйткәндә, милли горурлыкларының булмавы белән аңлатыла. Хәзер республика җитәкчелегенең дә, мәгълүмат чаралары, уку йортлары, мәдәният оешмалары һәм җәмәгатьчелекнең иң мөһим бурычы – халыкта милли рух, горурлык хисләре, үзен лаеклы шәхес итеп санау сәләте тәрбияләү. Халык күңеленә игелекле, күркәм сыйфатлар сеңдерми торып, безнең телебез дә, мәдәниятебез дә тиешенчә алга бармаячак һәм ахыргы исәптә үзебез дә алдынгы милләт буларак мантый алмаячакбыз.

Бүген татар телендәге матбугат рухи тормышыбызның иминлеге өчен зур әһәмияткә ия, шулыктан бу мөһим мәгълүмат чарасын тиешле югарылыкта тоту зарур. Матбугатка игътибарны арттырырга кирәклек турында сүз чыкканда, кайберәүләр хәзерге интернет, социаль челтәрләр җәелә барган заманда газетаның әһәмияте кими, кирәге калмый дигән сафсата кора. Мондый караш зарарлы. Бу фикергә таянып эш итсәк, милли мәдәният һәм мәгарифебезгә зур зыян киләчәк. Социаль челтәрләрдәге мәгълүматның үз урыны, үз ихтыяҗы бар. Ләкин ул, гомумән алганда системалы, "тәртипле" чара булмаганлыктан һәм шактый дәрәҗәдә тотрыксыз, "анархияле" барганга, мәдәниятле, классик мәгълүмат чарасы матбугатны алыштыра алмый. Газета-журналлар – культуралы җәмгыять казанышы, аларга урын түрдән булырга тиеш.

МӘК Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

МИЛЛӘТ ГАМЕ – ЯШӘЕШ ЯМЕ

Адәми затның туганлык иерархиясе катлаулы корылган: шәхес-гаилә-туганнар-милләт-тугандаш кавемнәр-кешелек дөньясы. Бу чылбырда инде һәр буынның үз урыны, гармонияле яшәешкә ирешүдә Аллаһ кануннары белән билгеләнгән үз миссиясе бар. Дөнья тотучылар моны яхшы аңлый һәм геосәясәттә үз максатларында бик оста куллана. Алар бу чылбырдан нәкъ менә милләтне төшереп калдырырга омтыла. Максатлары - милли күптөрлелекне бетереп, мәҗбүри глобальләштерү сәясәтен тизләтү аша, Җирдә үз хакимлеген урнаштыру. Дөрес, соңгы елларда, сексуаль азчылыклар хокукын яклыйбыз дигән булып, гаилә институтын да җимерү бара. Моның да геосәяси максатлары яхшы аңлашыла: бер яктан, шул ук милли күптөрлелекне бетерү булса (чөнки милли аң һәм нәсел аңы иң элек гаиләдә формалаша), икенче яктан, дөньяда халык санын киметү. Көнбатыш кыйммәтләренә корылган ясалма системаның икейөзлелеге анда инде ярылып ята: илаһи яшәештән тайпылу һәм рухи гариплек хуплана, ә Хак Тәгалә тарафыннан бар ителгән милләтләрнең хокуклары санга сугылмый гына түгел, алар үзләре дә бетерелә.

Әлбәттә, инсаният өчен иблис азгынлыгы гына милли яшәештән ваз кичүгә китерә торган сәбәп була алмый. Киресенчә, милли күптөрлелекне саклап калуда ул барлык халыкларны уртак максат тирәсендә берләштерергә генә мөмкин. Илаһи миссияле милләт буларак, татар халкы өчен бу инде аеруча зур әһәмияткә ия. Димәк, аңа Аллаһ юлындагы бу эштә дә үрнәк һәм әйдәп баручы көч булу бурычын үтәргә туры киләчәк. Алдан шуны да искәртеп үтик, милли эшләр турында сүз барганда, әлбәттә инде, аның илаһият кануннарына җавап бирә торган сәламәт формасы күздә тотыла. Бүгенге кискен хәлне һәм иң мөмкинлекләрне дә исәпкә алып, ошбу изге эшкә инде һәммәбезгә дә (кемнең кем булуына карамастан) икеләтә илһам һәм яңа көчләр белән алынырга туры киләчәк.

Конкрет эшләр турында сүз барганда бәгъзеләрдән еш кына: «Мин үзем генә нәрсә майтара алам соң?» кебек сораууларны да ишетергә туры килә. Миңа калса, мондый хәл мәсьәләнең асылын аңлап җиткермәүдән килә. Юкса, милләтнең һәр кызы вә улыннан бик гади нәрсәләр таләп ителә бит: яшәү рәвешеңне бүгеннән үк ата-бабаларың рухына туры китереп үзгәрт; тормышта мөһим карарлар кабул иткәндә, яисә җитди гамәлләр кылганда, шәхси файдадан тыш, милләт хакын да исеңдә тот; балаларың вә оныкларыңны ата-бабалар рухында, милли традицияләргә туры китереп тәрбияләә, аларда югары милли аң формалашуын максат ит; гаиләңдә милли рух өстенлегенә ирешә, чөнки синнән башка моны беркем дә эшләмәячәк. Күрүебезчә, сүз нибары яшәү рәвешен илаһият кануннарына туры китереп үзгәртү турында бара һәм гомуми яшәешкә ул берничек тә комачауламый. Киресенчә, аңа рухи ныклык, эчке гармония һәм ямь өсти, шәхесне һәм аның гаиләсен абсолют кыйммәтләр системасына якынайта. Бу таләпләр хәтта бүгенге кырыс шартларда да үтәлерлек. Ә төп принцип анда гади: үз халкымны яратам, башкаларны хөрмәт итәм. Ул чакта инде фашизм яки шовинизм кебек тискәре күренешләргә урын калмаячак.

Инде чын мәгънәсендә милләт гаме белән яшәүчеләр хакында да бер-ике сүз. Үз талантын милләт хакын яклауда эшкә җигеп, аңа мәртәбә өсти торган андыйлар бигрәк тә иҗат әһелләре арасында еш очрый. Туган телләрне яклап бер сүз дә әйтә алмаган җирле парламентка протест йөзеннән, Кремль дивары катына килеп, үзәкләргә үтәрлек итеп оран салган татар җырчысы белән ничек горурланмыйсың!? Милләт өчен җан атып иҗтиһат итүчеләр башка һөнәр ияләре арасында да бар. Татар мәктәпләрен яклап дан казанган гимназия директоры Нурмөхәммәт Хөсәеновның күркәм эшләрен генә алыйк. Улы Илдар белән берлектә, быел Уфада алар «Контуры Великой Татарии» дигән күләмле хезмәтнең беренче китабын (584 бит) бастырып чыгарган. Авторлары әйтүенчә, 3 кыйтганы биләп торган бу Бөек илнең әле өйрәнелә дә башламаган бөек тарихы бар. Евразия һәм Төньяк Африкада «татар» сүзе кергән 600 топоним әле бүгенгәчә сакланып калган... Милләт гаме белән яшәүче галимнәребез дә, шөкер, бар. Әйтик, быел Мәскәүдә Р.Нигъмәтуллин, И.Үтәмешев һ.б. авторлыгында «Татарские ученые» дигән күләмле хезмәт (376 бит) дөнья күргән. Ә мондый фидакярлекнең артуы милләтебезгә бүген саф һава кебек кирәк.

Фоат УРАЗАЙ.

Заманча китапханә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Республика көнендә Казанда капиталь ремонт ясалган «Сандугач» китапханәсендә булды.

13 нче китапханә мәйданы берничә зонага бүленгән. Уку залларында ачык киштәләр оештырылган, шулай ук залда коворкинг – шәхси һәм төркемле эш һәм ял өчен урыннар булдырганнар.

Әлеге муниципаль китапханәнең үзенчәлеге – биредә зур булмаган концерт залы бар, анда әдәби-музыкаль кичә, лекция һәм дискуссияләр үткәреләчәк. Килүчеләргә уңайлы булсын өчен, китапларны кире кайтару станциясе урнаштырылган, аның ярдәмендә укучылар укыган басмаларны мөстәкыйль рәвештә тапшыра ала.

«Апуш» артистлар үстерә

Казан Мэриясе «Апуш» татар балалар театр студиясенең башка мәдәният йортларында бүлекләрен ача һәм яңа кастинглар игълан итә.

Беренче кастинг 4 сентябрь, 12.00 -18.00 сәгатьләрдә Ленин исемендәге мәдәният йортында үтәчәк. Икенче кастинг 11 сентябрьдә, 12.00-18.00 сәгатьләрдә «Чулпан» мәдәният сараенда оештырыла. Анда татар телендә иркен һәм берникадәр кыенлык белән аралашучы 9-15 яшьлек укучылар катнаша ала. Кастингны уңышлы узучылар «Апуш» студиясенә бушлай йөриячәк. Аны Казан Мэриясе финанслый.

Гаризалар teatrstudio_kzn@mail.ru адресы буенча кабул ителә. Анда фамилия, исем, әтисенең исеме, яшь, элемтә өчен телефонны күрсәтергә кирәк.

«Апуш» театр студиясе «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә ел ярым элек эшли башлаган иде. Анда йөрүче балалар бу язны тамашачыны беренче спектакльләре белән дә куандырырга өлгерде.

Эльмира СИРАҖИ.

1 нче биттә – Казанның Киров районында 188 нче күппрофильле лицей ачылу тантанасыннан бер күренеш, 2021 ел. Фото: president.stan.ru/

Җырчыга һәйкәл

Республика көнендә Казанның Татар дәүләт филармониясе бинасы янындагы бакчада ТАССРның халык артисты Рәшит Ваһаповка һәйкәл ачу тантанасы булды. Анда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, җырчының туган ягы – Түбән Новгород өлкәсе губернаторы урынбасары Олег Беркович, Рәшит Ваһаповның бертуган абыйсының оныгы Рәүф Ваһапов, танылган җырчылар, язучылар, галимнәр, музыка сәнгате белгечләре, мәдәният әһелләре һ.б. катнашты. Бәйрәмне Рәшит Ваһапов фестивале лауреатлары һәм Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле ачып җибәрде.

Бөек Ватан сугышы, аннан соңгы иң авыр елларда халкыбыз күңеленә татар моңнары – халкыбыз җырлары, С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, М.Мозаффаров һ.б. композиторларыбыз көйләре Рәшит Ваһапов башкаруында барып ирешкән. Аның моңлы тавышы милләтебезнең хәсрәтләрен таратырга булышкан, шул ук вакытта тенор тавышлы, бөек, кабатланмас җырчыбыз - татар җыр сәнгатен югары дәрәҗәгә күтәргән сәнгатькәрләребезнең берсе. Олуг галимебез Индус Таһиров искәрткәнчә, Рәшит Ваһапов җырларын тыңлаганда, эчке хисләрең кузгала, татарлыгың белән горурлану уяна торган була. Гомумән, ул еллардагы җырчыларның һәрберсе – кабатланмас, аерым моң дәрьясы. «Аларның җырларны башкару осталыгын бүгенге яшьләргә кайтару кирәк», – ди ул.Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев та Рәшит Ваһапов башкаруындагы җыр-моңнар тәрбияви әһәмияткә ия булуын, татар халкының гасырлардан килгән эчке сагышын – йөзен ачып бирүен искәртте. Россиянең халык артисты Зилә Сөнгатуллина да Р.Ваһапов, И.Шакиров, Ә.Авзалова башкаруындагы моңнарыбызны кечкенәдән тыңлап, күңеленә салып үскән.

Юлсызлык чоры булса да, трактор арбаларына, ат чаналарына утырып йөрергә туры килсә дә, Рәшит Ваһапов илнең һәр почмагында, татарлар яшәгән барлык шәһәр, бистә-авылларында булган, халык белән аралашкан. Президент Рөстәм Миңнеханов ачылыш тантанасында Рәшит Ваһаповның Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән концерт бригадасы белән гастрольләргә чыкканын искәртте. «Республика авыл-шәһәрләрендә гастрольләргә йөреп, тыңдагычларның рухын күтәргән, җиңүгә өмет уяткан. Аның шул авыр чорларда җырлы иҗаты халкыбызның иң нечкә хисләрен кузгаткан», – диде.

Бөек җырчы Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев хәтерендә дә бик матур истәлек булып кереп калган. Разил әфәнде артистның «Әлфия» дигән җырын аеруча яратып тыңлый торган булган. Аңа җиде яшь чагында Рәшит Ваһапов шагыйрьнең туган авылы Ташлыкка (Түбән Кама районы) концерт белән килгән. Ул вакытта кунакханәләр юк. Җырчыны ике баянчысы белән Вәлиевләргә фатирга кертәләр. Разил Вәлиевнең әнисе исә концертка бара алмый, татар халкының матур гадәтенчә, кунаклар өчен бәлеш пешерә. Җырчы артист концерттан кайткач Разилнең әнкәе өчен тагын бер тапкыр концерт куя. Бу инде Р.Ваһаповның кече күңелле, башкаларга ихтирамы зур булуы турында да сөйли.

Ваһапов фонды директоры Рифат Фәттахов һәйкәлнең нәкъ менә Татарстан Республикасы көнендә ачылуын тирән символик мәгънәгә ия булуын искәртте. «Аны бөек җырчы итеп, Татарстан, татар халкы күтәрде, вафатыннан соң 60 ел үткәч, Казан Рәшит Ваһаповны милли каһарман итеп бөек пьедесталга бастырды. Рәшит Ваһаповка һәйкәл кую ул - татар җыр сәнгатен зурлау да», – диде Р.Фәттахов. Рөстәм Миңнеханов та һәйкәлне булдыруда хезмәт куючыларга рәхмәтен җиткерде. «Бер көнлек кенә эш түгел ул, фонд гел шушы юнәлештәге эшне даими алып бара», – дип алкышлап рәхмәт белдерүне сорады.

Биш метр биеклектәге һәйкәлнең авторы – скульптор Андрей Ковальчук, архитекторы Герман Бакулин. А.Ковальчук сынны җырчының фотосурәтләренә нигезләнеп эшләгәнен әйтте. «Алар аша җырчының холкын тоемларга тырыштым, эш барышында да җырларын күп тыңладым. Җырдагы хис-тойгылар аша җырчыны аңлый башлыйсың. Һәйкәлдә иң мөһиме – куллар. Бу аңа хас хәрәкәт. Югарыга хәрәкәт фигурада да, постаментта да бар», – диде. Җырчының туганы Рәүф Ваһапов та туганына куелган һәйкәлне, аның урынын бик ошатканын әйтеп, рәхмәт белдерде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Сәнгатькярләргә бүләк

Казанда Бакый Урманче исемендәге премия ияләрен бүләкләделәр. «Сынлы сәнгать» номинациясендә рәссам Әлфия Ильясова, «графика» номинациясендә рәссам-график Диләрә Наврозова, «скульптура» номинациясендә рәссам-скульптор Динар Сәлимов, «декоратив сәнгать» номинациясендә рәссам Луиза Фәсхетдинова һәм «теория һәм сәнгать тарихы, тәнкыйть, сәнгать белеме» номинациясендә сәнгать белгече Нина Горюнова быелгы лауреатлар булды.

Мәдәният министрлыгы бүләгән Казан Кремленең яңартылган бинасында Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова тапшырды. «Бу бик тә дәрәҗәле премия. Карар кабул иткәндә бәхәсләр булмый калмады. Чөнки һәр кандидат сәнгать өлкәсендә зур шәхес. Аларның тәҗрибәләре дә бар, эшләре дә уңышлы. Кандидатлар арасында яшь кешеләрнең булуы минем өчен икеләтә шатлык», – диде министр.

«Бакый Урманче премиясе бирелә башлаганнан бирле беренче тапкыр традицион булмаган сынлы сәнгатькә игътибар иттеләр, – дип сөенечен уртаклашты Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфия Ильясова. – Эшләремне Заманча сәнгать галереясында күрергә мөмкин. Бакый Урманче үзе дә яңалык алып килүче шәхес булган. Мин шулай ук мультимедияле юнәлештә дә эшләдем, бу – сәнгатьтә яңа агым».

«Татарстанның көньяк-көнчыгышында иҗат итүче җирле рәссамнар турында язуымны бәяләгәннәре өчен сөендем. Бу яклар Николай Петров, Мансур Закиров кебек рәссамнарның туган ягы булып тора», – диде сәнгать белгече Нина Горюнова.

Рәссам-скульптор Динар Сәлимов фикеренчә, әлеге премиядә катнашу киләчәктә үсеш ясар өчен зур адым. «Премияне алгач, күбрәк эшләргә илһам килә», – диде ул.

Моннан тыш, үз хезмәте өчен медальләр һәм исемнәр белән тагын 23 сәнгать эшлеклесе бүләкләнде. Алар арасында, Опера һәм балет театрының балет буенча репетиторы Марина Прокопова, Татарстан Милли музее директоры урынбасары Светлана Измайлова, Камал театрының баш рәссамы Сергей Скоморохов, Татарстан Дәүләт симфоник оркестры музыканты Фәгыйль Гыйльманшин, Тинчурин театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов һ.б. бар.

Быел барлыгы 31 гариза килгән. «Сынлы сәнгать» номинациясенә – 10, «графика» номинациясенә – 4, «скульптура» номинациясенә – 4, «декоратив сәнгать» номинациясенә – 9, «теория һәм сәнгать тарихы, тәнкыйть, сәнгать белеме» номинациясенә 4 гариза кабул ителгән. Премия лауреатлары 200 мең сум күләмендә акчалата бүләк ала. Бу кагыйдә барлык номинацияләр өчен дә гамәлдә. Төп номинантларның эш күргәзмәсе быел июль аенда «Хәзинә» галереясында узды.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Сабада Әдәби сабантуй

Сабаның «Сабантуй» мәдәни-спорт комплексында Әдәби сабантуй узды. Монда язучылар, республика районнарыннан һәм чит төбәкләрдән нәфис сүз көрәштерүдә катнашучылар җыелды.

Сабалылар кунакны күңел биреп каршылый белә. Урак, бирнә җыю күренешләрен үзешчәннәребез тел-теш тидермәслек итеп башкарып чыкты. Кунаклар да буш кул белән килмәгән. Колга сөлгеләрдән тиз авырайды, китаплар да күпләп җыелды.

Әдәби сабан туенда катнашучыларны Татарстан Дәүләт Киңәшчесе ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина сәламләде. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкиле Ләйсән Гайфуллина әлеге проектның уку-укыту процессында мәгариф системасына ярдәмче буларак зур роль уйнавын ассызыклады. Шәмәрдән лицееның китапханәләр арасында үткәрелгән республика конкурсында абсолют җиңүче булуын сабалыларның уртак хезмәте дип бәяләде.

Әдәби сабантуй яшүсмерләр өчен татар һәм рус телләрендә эшли торган билингваль «Белем радиосы»на старт бирелүе белән дә истәлекле булды. Аннары сәхнәгә әдәби марафонда җиңүчеләр чакырылды. Проект авторы Раил Гатауллин әйтүенчә, бу марафоннарда җиде йөзгә якын кеше катнашкан. Беренче урынны алган Саба районы китап укучылары сәхнәгә сыймады. Икенче урында – Арча, өченче урында – Әлмәт һәм Апас районнары.

Акрынлап Әдәби сабан туеның төп бәйгесе – әдәби көрәш башланып китте. Әдәби марафон проектының идея авторы һәм җитәкчесе Раил Гатауллин әдәби көрәштә катнашучыларны язучылардан торган җюри бәяләячәген әйтте һәм кагыйдәләр белән таныштырды. Быел әлеге көрәшнең онлайн этабында катнашырга барлыгы 60 гариза кабул ителгән. Язучылар берлегендә үткәрелгән финалистларны барлау җыелышында җюри әгъзаләре катнашчылардан 18 яшькә кадәр катнашучылар арасыннан да 16шар финалистны билгеләгәннәр. Балалар арасында Сарманнан Альзана Шәфигуллина җиңү яулады. 18 яшьтән югарылар арасында Гран-прига беренче турда Һади Такташның «Алсу» поэмасыннан өзек, икенчесендә Әнгам Атнабаевның «Гөлчәчәккә» дигән шигырен сөйләгән, якташ язучыбыз Гөлсинә Галимуллинаның иҗаты белән таныштырган Алисә Гыймадиева лаек булды. Финалистларны «Тәртип» радиосы мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлова да котлады һәм эфирга чыгу мөмкинлеге биргән сертификатлар тапшырды.

Раил Гатауллин әйтүенчә, киләсе елга Әдәби сабантуй эстафетасының кайсы районга тапшырыласы марафонда катнашучылар саныннан һәм активлыгыннан чыгып ачыкланачак.

Фәнил МӘҮЛЕТОВ.

Күршедән гыйбрәт алыйк

Чуашстан Мәгариф министрлыгы мәктәпләрдә чуаш телен атнага өч сәгать укытуны тәкъдим иткән. Бу яхшы да, начар да, ди укытучылар. Чөнки шәһәр мәктәпләрендә хәзерге вакытта чуаш теле бер-ике сәгать кенә укытыла. Әмма авыл балалары аны моңарчы атнасына биш сәгать укыган.

Чуашстан Мәгариф министрлыгы республиканың район башлыкларына мөрәҗәгать итеп, чуаш телен укытуның яңа планын төзергә кирәк дигән. Министрлык фикеренчә, ана телен мәктәпләрдә атнасына өч сәгать укыту зарур.

Район башлыкларына язган хатында мәгариф министры Дмитрий Захаров Чуашстан Конституциясенең 6 нчы маддәсенә сылтанган. Бу маддәдә «Чуашстан республикасы чуаш халкының мәдәниятен саклау һәм үстерүгә җаваплы» диелә.

Министр чуаш телен саклау һәм үстерү дәүләт хакимияте оешмаларының да, җирле үзидарәләрнең дә иң мөһим бурычы дип әйткән. Аеруча бу эштә мәктәпләрнең роле зур дип искәрткән.

Әмма укытучылар берләшмәсе вәкилләре чуаш теленең яңа укыту планын язу тәкъдименә шикләнеп карый.

– Бу документ авыл мәктәпләрен исәпкә алмый. Авылларда, әйтик 5нче сыйныфка чуаш теле һәм әдәбиятына биш сәгать бүлеп бирелгән. Димәк, аларның сәгатьләре кимиячәк, – ди чуаш теле һәм әдәбияты укытучысы Александр Степанов.

Казахстан мәгариф министры балалар башта туган телләрендә язарга һәм укырга өйрәнергә тиеш дип белдергән. Рус телен – икенче сыйныфтан, инглиз телен – өченче сыйныфтан башлап укытачаклар.

Быелгы яңа уку елыннан Казахстан хакимиятләре беренче сыйныф укучыларына берьюлы өч тел укыту тәртибен бетерә. Бу хакта мәгариф министры Әсхәт Аймагамбетов хәбәр иткән.

Түрә сүзләренчә, беренче сыйныфта укучыларга казах теле генә укытылачак. Ул беренче сыйныф укучыларына берьюлы өч тел өйрәнү авыр дигән. «Икенче сыйныфтан рус телен аерым дисциплина буларак өйрәнә башлаячаклар, ә өченче сыйныфтан – инглиз телен», дип белдергән ул.

Шул ук вакытта русча белем алучы беренче һәм икенче сыйныф укучыларының мәктәп программасында ике фән: рус теле һәм казах теле калачак, ә инглизчәгә өченче сыйныфтан өйрәнә башлаячаклар.

● Иң «көчле» паспортлы илләр рейтингында Россия 50 нче урынга куелган. Россия паспорты белән визасыз 119 илгә чыгып була. 2006 елда Россия паспорты визасыз барлыгы 35 илгә, 2010 елда – 83, 2019 елда 117 илгә керү мөмкинлеге биргән. Исемлектә беренче урында – Япония, әлеге дәүләт паспорты белән 193 илгә иркенләп барып була. Икенче урында – Сингапур белән Көньяк Корея (бу илләр халкы визасыз 192 илгә бара ала), өченче урындагы Германия һәм Испания паспорты 189 илгә чыгу мөмкинлеге бирә.

● Британиядә кузәнәкле асфальт уйлап табылган, аның бер квадрат метры бер минут эчендә 1000 литрга кадәр суны «йота» ала.

Яңа милли сәясәттә милләтләргә урын бармы?

Башкортстанда яңа милли сәясәт дәүләт концепциясе кабул ителде. Республика башлыгы Радий Хәбиров фәрманы белән имзаланган документ тамырдан үзгәрешләр кичергән: асылда сүз Башкортстанда яшәүчеләрдән «гомумроссияле үзбилгеләнү» булдыру турында бара, башкорт милләтен саклауга аз урын бирелә.

Ни өчен яңа документ янында Татарстан концепциясе күпкә «милләтче»рәк булып күренә? Аларның аермасы нидә? Бүгенге сәяси вәзгыятьтә Татарстанның милли сәясәтенә үзгәрергә чират җитмәсме?

Белгечләр фикеренчә, Россиядә руслаштыру сәясәте күптән дәвам итә. 2020 елда Конституциягә «дәүләт коручы халык теле» дигән нигезләмә кертелү рус теленең өстенлекле булуын канун белән раслап куйды, бу Россиядәге башка халыкларның руслашуын һәм мәҗбүри ассимиляциясен көчәйтә генә ала.

Яңа концепциянең төп максаты буларак «гомумроссия ватандашлык үзбилгеләнүен» булдыру күрсәтелгән. Башкортстанда яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм телен саклау да шуның кысаларында күзалланган. Гомумроссияле үзаңын үстерү йөзеннән төрле чаралар үткәрү каралган. Беренче чиратта, бу мәгариф өлкәсенә карый. Федераль стандартлар нигезендә белем бирү программаларын, дәреслекләрен арттыру күзаллана. Әлеге чаралар патриотизмны арттырырга, яшьләр хәрби-патриотик хәрәкәтен үстерергә тиеш. Россияле дигән үзаңны булдыру өчен ТВ, радио, матбугат, интернетта язмалар булдыру, аларны тарату, социаль роликлар эшләү кирәклеге әйтелә.

Гомумән, документта «гомумроссияле үзаңы» сүзтезмәсе уннан артык очракта кулланыла. Милли республика булуына карамастан, концепциядә «башкорт» сүзе ике тапкырга азрак очрый.

2021 елда үткәрелгән сораштыру нәтиҗәсе китерелә. Анда Башкортстан халкында үзләрен беренче чиратта россияле дип хис итүчеләр 73,1 процентны тәшкил иткән диелә.

Шул ук вакытта төп проблема буларак «гомумроссия ватандашлык үзбилгеләнүенең юылу» куркынычы барлыгы әйтелә. Моңа төп сәбәп – «радикаль идеяләр үтеп керүе һәм таралуы». Моннан тыш, «Россиянең мәдәни суверенитетын юк итү максатыннан ят кыйммәтләрне тагу, мәгълүмати-психологик диверсияләр» булуы телгә алына. Ә менә руслаша баручы башкорт һәм татар халыклары проблемасы искә алынмый.

Милли сәясәттә күтәрелгән проблемалар арасында сепаратизм мәсьәләсе дә бар. Яшьләр сәясәте кысаларында «милләт ягыннан аерылып тору, сепаратизм, ксенофобия идеологиясен алга сөргән яшьләрнең экстремистик төркемнәренә» карата чаралар күрергә кирәклеге әйтелә.

Моннан тыш, концепциядә «тел проблемасы», «телара проблема» дигән төшенчәләр, аларны булдырмау, профилактикалау турында сүз бара. Ягъни рәсми оешмаларның татар телен башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты дигән төшенчәне дә кулланышка кертеп җибәрүен аклау һәм аңа каршы көрәшүчеләрне «телара проблема» тудыручылар буларак күрсәтүенә ишарә ясала.

Концепциядә рус теленә аерым урын бирелә. «Рус теле милләтара аралашу теле сыйфатында Башкортстан халыкларының бердәмлеген һәм тыгыз бәйләнешләрен тәэмин итә», – диелә. Республикада дәүләт статусын йөрткән башкорт телендә белем алу хокукы булуы, аңа ярдәм күрсәтелергә тиешлеге турындагы сүзләрне генә укырга була.

Әйтергә кирәк, концепциядә башкорт милләтенә күп урын бирелмәгән. Башкортстаннан читтә яшәүче башкортларга тел, мәдәният, тарихны өйрәнүдә ярдәм күрсәтергә кирәклеге әйтелә. Документта «XVI гасырда Башкортстанның ирекле рәвештә Россия дәүләтенә керүе» дә искәртелә.

Россия фәннәр академиясе Уфа федераль тикшеренү үзәгенең Этнология тикшеренүләре институты хезмәткәре Илдар Габдрафыйков сүзләренчә, әлеге концепция Россиядә милли сәясәт дәүләт стратегиясен кабатлый, анда яңа нәрсә юк ди. Шушы стратегия нигезендә бөтен диярлек төбәкләр дә үз документларын булдырды.

– Башкортстанда үзләрен Россия кешеләре дип танучылар саны уртача 70 процент тәшкил итә. Башкортлар арасында ул кимрәк, руслар арасында, киресенчә, күбрәк, ә татарларда урта бер сан. Гомумроссия үзбилгеләнүе болай да югары, шуңа күрә бу концепциянең әллә ни файдасы да, зыяны да юк, өстән кушып ясалган документ, – диде ул.

Габдрафыйков әлеге документта республикага башка төбәкләрдән, якын һәм ерак чит илләрдән мигрантлар килүен проблема дип күрсәтүне хата дип саный.

– Мигрантларны бары тик тискәре фактор дип карарга ярамый, аларның бүген илгә файдасы бик зур, монда «нинди мигрантлар» яки «мигрантларның нинди гамәлләре» кебек өстәмә билгеләмә кирәк иде, – ди галим.

Бүген Россия стратегиясенең нигезен «гомумроссия гражданлык үзаңын һәм күпмилләтле Россия халкының («россиян» милләтенең) рухи берлеген ныгыту» алып тора. Башка халыклар телен, мәдәниятен саклау бу «зур максат» тирәсендә сизелми дә кала.

Россия милли сәясәте стратегиясенә 2018 елда зур үзгәрешләр кертелде. Аны Татарстан җитәкчеләре хуплап каршы алды, ә милли җәмәгатьчелек кискен тәнкыйтьтә торткан иде. Бу стратегиядә башка милләтләрне кабул итмәү чаткыларын күрделәр.

Документта «Россия дәүләте төрле халыкларның берләшүе нигезендә оешты. Ә аның барлыкка китерүче үзәге булып борынгы чордан ук рус халкы торды. Рус халкының берләштерүче роле, күп гасырларга сузылган мәдәниятара һәм этникара багланышлар ярдәмендә Россия җирлегендә уникаль мәдәни күптөрлелек һәм төрле халыкларның рухи уртаклыгы барлыкка килде» диелә.

«Милли стратегия бик куркыныч әйбер. Анда республикалар юк, аларның телләре юк, мәктәпләрдә ике теллелек юк. Элеккеге белән чагыштырып әйтәм. Анда туган телләрне үстерү юк, саклау гына бар. Борынгы заман күлмәкләре кидереп, биетү һәм мәктәпләрдә телләрне бетерү», дип белдерде ул вакытта мәгариф белгече Марат Лотфуллин.

Россия стратегиясе нигезендә кабул ителгән Татарстанның милли сәясәт концепциясе Башкортстанныкы янында күпкә милли рухта язылган кебек күренә. Гәрчә, монда да «россиян милләте» төшенчәләренә аерым урын бирелгән. Шул ук вакытта «гомумроссияле ватандашлык үзбилгеләнүе» белән һәрвакыт янәшә «Татарстан ватандашлык үзбилгеләнүе» кулланыла. Башкортстан концепциясендә республиканың үзаңы турында сүз бармый.

Татарстан – татар халкының мәркәзе, читтә яшәүче татарларның интеллектуаль, икътисади һәм этномәдәни берләшүе өчен шартлар булдырырга тиеш дип язылган документта. Читтә яшәүче ватандашларга Татарстанга кучеп кайтырга ярдәм итү дә каралган. Моннан тыш, Татарстан татар халкының дәүләтчелеге буларак күрсәтелә. Ләкин Татарстан концепциясенең гомере озынмы?

Сәясәт белгече Руслан Айсин бүген Россиядә сәяси вәзгыять үзгәргәндә Татарстанның милли сәясәт концепциясенә дә куркыныч яный ди. Татарстан белән Башкортстан концепциясе арасындагы аерманы ул Радий Хәбировның яңа сәяси шартларга җайлашуы белән аңлатты.

– Татарстан концепциясе дә юкка чыгарга мөмкин. Хәзер сәяси вәзгыять үзгәрде. Бу концепция идеология белән бәйле. Бүген милли тарихка бәйләнәләр, бердәм тарих булырга тиеш дип мәктәптәге дәреслекләргә ревизия ясыйлар. Тарих булмаса, бу концепциянең мәгънәсе калмый. Һәрхәлдә, әлеге документны үзгәртергә теләячәкләр. Монда Татарстанның үзбилгеләнүенә, дәүләтчелегенә, «татарстанлы» дигән төшенчәгә таяну бар. Халык тарафыннан кабул ителгән беренче Конституциядә дә Татарстан ватандашлыгы төшенчәсе бар иде. Хәзер рус дөньясы, православ дине, бер тел, бер милләт дигән идеология алга сөреләчәк. Башкортстанга килгәндә, концепция бүгенге сәяси вәзгыятькә бик туры килә. Кызганычка, татар һәм башкорт милләтенең дә проблемалары күтәрелми диярлек. Башкортстан концепциясе чынбарлыкка туры килми. Тел мәсьәләсе, социаль проблемалар калыкты, җанисәп алдыннан татар телен башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты дип сөйләү булды. Бу – ясалма мәсьәлә. Хәбиров һәм аның такымы башкорт милләте, федерализм, республика статусы белән шөгыльләнми. Бу бары Мәскәү алып барган сәясәтнең бер койрыгы. Иртәгә Мәскәү барыбыз да рус дөньясының бер өлеше дип әйтсә, башкорт элитасы да шуңа кушылачак.

Мәскәү һәм җирле хакимият тел активистларын фетнәчеләр буларак күрә. Әгәр тел өчен көрәшсәң, милләтнең статусы турында сөйләсәң, бу кешене шундук фетнәче, этномилләтче дип атыйлар. Тел өчен функциональ булмаган чаралар – фестивальләр, бәйгеләр, сабантуйлар гына оештырылачак. Мин офыкта татар һәм башкорт телләренең дәүләт статусын бетерелүен күрәм, — диде Р.Айсин.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 140 ел

«Мәдрәсәбездә 25 укытучы татарча һәм гарәпчә белем бирә. 54 фән буенча гыйлем җыючы шәкертләребезнең уңышлары байтак, ел саен берничә Коръән-хафиз да әзерлибез, – ди «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең уку-укыту буенча директор урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин. – «Мөхәммәдия» комплексының архитектура-төзелеш үзенчәлекләрен яңарту максатыннан җитди ремонт, реставрация уздырылгач, биредәге уку шартлары тагын да яхшырды».

Зөлфәт хәзрәт Габдуллин мәдрәсәдә 1999 елдан хезмәт куя. Шушы еллар эчендә биредә барган бар үзгәрешләр дә аның күз алдында. Зөлфәт Габделманнаф улы – олы йөрәкле, киң күңелле, тирән белемле остаз.

– Зөлфәт хәзрәт, әүвәл үзегез белән таныштырып үтсәгезче?

– Мин бу данлыклы мәдрәсәнең директор урынбасары булудан кала, башкалабызның «Тәүфикъ» мәчете имам-хатыйбы һәм Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы да. Мәдрәсә эшендә Галимҗан Баруди хәзрәтләре башлаган традицияләрне дәвам итәргә тырышып, менә инде 23 ел аның үрнәгендә гамәл кылам. Үзем дә шушы мәдрәсәне тәмамладым. Аның өчен җан атып яшим. Бушрак вакыт табылса, шәкертләребез өчен дәреслекләр дә язам. Имам Нәвавинең «40 хәдис» китабына иҗазәм (рөхсәтем) бар. Ш.Мәрҗанигә багышланган фәнни эш алып барам. Гаиләмдәге улларыбызны да яхшы кешеләр булырлык итеп тәрбияләргә тырышам.

– Хәзрәт, улларыгыз да шушы мәдрәсә шәкертләре булдымы?

– Әлхәмдүлилләһ, дүрт улым бар, әмма алар әле кечкенә. Киләчәктә нинди уку йортларын сайларлар, бу хакта соңрак мәгълүм булыр.

– Быел Россия күләмендә иң мәшһүрләрдән саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 140 ел тула. Аның тарихына күз салсак, нәрсәгә аеруча игътибар итәрлек дип саныйсыз?

– Татар зыялыларының күбесенә башлангыч, урта һәм югары дини белем биргән уку йорты бу. Биредә укып чыккан шәхесләр соңрак мәдәният, фән, икътисад һәм сәясәт өлкәләрендә танылган. Алар арасында С.Сәйдәшев, Х.Ямашев, К.Тинчурин, Г.Камал, Б.Урманче, М.Гафури, Ф.Әмирхан һ.б. бар. Россиянең иң борынгы уку йортларыннан берсе булып саналган әлеге мәдрәсәгә Галимҗан Барудиның әтисе Мөхәммәтҗан Галиев тырышлыгы белән 1882 елда нигез салынып, 1883 елда бер катлы кирпеч бина төзелгән. Соңрак бу бина инде өч катлыга әйләнгән. 1901 елда төп бинага тагын өч катлы кирпеч бина өстәлгән. Чөнки укучылар саны да елдан-ел арта, мәдрәсәдә хәтта Урта Азиядән килеп укыйлар. Җәдиди (яңа ысуллы) мәдрәсә буларак, мәгърифәтче, шушы уку йорты мөгаллиме, реформатор һәм философ Г.Баруди биредә төрле фәннәр укытуга игътибар бирә. Тарихка әйләнеп карасаң, искитәрлек: мәдрәсәбезнең ашханәсе, ашсу бүлмәсе, сырхауханәсе, аяк киемнәрен рәтләү һәм дә китаплар төпләү остаханәләре, яшелчә бакчасы һәм хәтта урманчылыгы да булган. Кышкы бакчада бозлавык ясалгач, шәкертләр тимераякта шуган... Алар үз газеталарын да чыгарган: «Мөхәммәдия», «Манзаратул-галәм», «Телескоп». Ә инде 1906 елда мәдрәсәдә хәтта театр булдырылган. Гарәп теле, дин белеме өйрәнү дөньяви фәннәрне үзләштерү белән үрелеп барган. 1913-1914 елларда биредә 20 мөгаллим укыткан. 1909 елда шәкертләр 12 ел укыса, 1913 елда инде 14 еллык укыту кертелгән. Өстәвенә, «Мөхәммәдия»гә Сәгыйть мәдрәсәсе дә кушыла әле... Мәдрәсәгә фарсы телендәге язма – рәхмәт тактасы беркетелгән булуы ук аның иң яхшы уку йорты икәнен раслап торган. Инкыйлаб кына мәдрәсәне аямаган. Ул төрле оешмаларга бирелеп, елдан-ел таралган, тузган. 1993 елда гына, ниһаять, Исхак хәзрәт Лотфуллин, Габдулла хәзрәт Галиулла һәм аларның шәкертләре мәдрәсә бинасына кереп, биредә укуларны яңартып җибәрә. 1998 елны бу йорт дини белем бирергә тиешле оешма бинасы дип тәгаенләнә. Бу уку йортына бик зур авырлыкларны кичерергә туры килде. Биредә төрекләр дә, гарәпләр дә үз укыту системаларын кулланырга теләде. Әмма төрле чит йогынтыларга бирешмәдек. 2020 елда гына башланып китә алган реставрация нәтиҗәсендә мәдрәсә бинасы тулысынча яңартылды һәм уку йорты тулырак көчкә эшләп китте. Биредә хәзер компьютерлар көйләнгән, бүлмәләр җилләтелә, намаз уку бүлмәләре иркен, уку заллары, гарәп телен үзләштерү өчен җайлы лингафон кабинетлар эшли... Барлыгы – биш курс. Беренче өч курста егетләр һәм кызлар аерым укытыла. Физик сәламәтлекләре чикле булганнар өчен дә ике уку сыйныфы эшли. Көндезге, кичке һәм читтән торып белем алу бүлекләрендә быел барлыгы 1200 мөселман белем ала. Көндезге бүлектә укучы ир-атлар һәм хатын-кызлар саны тигез. Ә менә кичке һәм читтән торып уку бүлегендә белем алучылар арасында хатын-кызлар күбрәк.

Мәдрәсәбезнең китапханәсе дә бай. Анда инкыйлабка кадәр үк нәшер ителгән ядкәрләрдән башлап заманча басмаларга кадәр бөтен кирәкле китаплар да бар. Моннан тыш студентларыбыз өчен электрон китапханә дә булдырылган.

Укулар татар телендә алып барыла, шуңа күрә ана телен начар белүчеләр мәдрәсәдә татарча сөйләшергә дә күнегә. Уку процессына килсәк, сүз Коръәнне өйрәнү, гакыйдә, фикъһ, тәфсир, ислам тарихын, татар тарихын, гарәп һәм татар телләрен өйрәнүне күздә тота. Бу телләрдә сөйләшүне чарлау өчен, остазлары белән якыннан аралашу мөмкинчелекләре дә булдырылган.

– Армый-талмый укучы шәкертләренең уңышлары зурмы? Аларга тәрбия бирү максатыннан нинди чаралар үткәрәсез?

– Шәкертләребез киләчәктә халык арасында эшләячәк, димәк, алар татар телен камил белергә тиеш. Телебез буыннар арасында югалып кала алмый. Ул гомуми мәктәпләрдә болай да аз укытыла. Шуңа күрә ана телебез киң кулланышка кертелгән, тел, әдәбият буенча олимпиадалар да узып тора. Әйтик, «Туган тел» сәнгатьле шигырь уку бәйрәмен уздырганда, укучыларыбыз татарча шигырь сөйләде.

Мәдрәсәгә керергә теләүчеләр һәрчак күп, 200 гә якын гариза языла, әмма барысын да кабул итә алмыйбыз. Шуңа күрә, мәсәлән, көндезге бүлегебездә 2021/2022 уку елында 98 егет һәм 113 кыз гына белем алды.

Уку йортында төрле бәйгеләр узып тора. Әйтик, азан әйтү конкурсы уздырабыз, чөнки азан әйтә белү – бик мөһим. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи үә сәлләм әйткән: «Әгәр кешеләр азан әйтүнең һәм намазда беренче сафта торуның әҗер-савабын белсә, алар бу дәрәҗәгә ирешү өчен җирәбә тартыр иде». Азан әйтүнең савабы гаять зур.

Былтыр Коръәнне өйрәнү буенча үткәрелгән бәйгедә беренче урыннарны гына яуладык. Урта һөнәри уку йортлары арасында оештырылган гарәп теле һәм ислам дине белеме буенча Россиякүләм олимпиадаларда да беренче урыннар безнеке булды. Бөтендөнья «Татарча диктант» чарасында да катнаштык. Гамәли сәнгать тә онытылмый. Биредә белем алучы яшь кызлар милли чигү үрнәкләребез буенча бәйгедә уңышлы чыгыш ясады.

– Хәзрәт, шәкертләр арасында Коръәнне яттан өйрәнүчеләр күпме?

– Шөкер, Коръән-хафиз булырга теләүче шәкертләребез бар. 2021 елда да хафизлар хәзерләүче Үзәктә мөселман белемен бирүче оешмалар арасында Коръәннең 30 нчы җүзен белү буенча уздырылган команда бәйгесендә I урынны яуладык. Быел шәкертләребез: 5 егет һәм 5 кыз Коръән-хафиз булу дәрәҗәсенә иреште. Коръәнне уку һәм яттлауның иң яхшы вазифа булуын аңлаган тырышларыбыз ел саен шушы дәрәҗәгә ирешеп килә. Бу зур җаваплылык та бит. Коръән уку бәйгеләре, Болгарга, Болгар ислам академиясенә сәяхәт кылу, Г.Тукай исемендәге халыкара шигырь укучылар бәйгеләрендә катнашу, музейларга, театрларга бару, каберләрне зиярәт кылу һәм шуңа охшаган башка чаралар – күптөрле. Көндезге бүлектә гыйлем эстәүче шәкертләребез төрле мәчетләрдә ислам дине нигезләрен, гарәп телен дә бик теләп укыта. Мәсәлән, «Рамазан», «Нур Ислам», «Ярдәм» мәчетләрендә укырга йөрүче балалар мондый дәресләр булуга бик шат.

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» икәнне истә тотып, актив, спорт сөюче шәкертләребез баскетбол, волейбол, өстәл теннисы уйный, бассейнга йөри. Яшьләребез спорт ярышларында да сынатмый. Мәдрәсә кубогына волейбол ярышлары уза. Футбол командабыз уңышлары аеруча шатландыра.

Мәдәни чараларга килгәндә, Г.Тукай дәүләт музеена барып, шагыйребезнең тормыш юлын аңлаткан экскурсияне гарәп телендә тыңлап кайту күңелләргә хуш килде. Шәкертләребез һәр ел саен татар зиратына барып, анда җирләнгән олуг татар шәхесләребез – Ш.Мәрҗани, Ф.Аитова, хәзрәт Г.Баруди, аның хәләл җефете Мәһруйбикә абыстай, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Ә.Максуди, «Мөхәммәдия»дә озак еллар белем биргән мөгаллимнәребезнең һ.б. рухына дога кыла. Моннан кала шәкертләребез Саба районы Югары Утар авылында, акылга зәгыйфь булган балалар йорт-интернатында тәрбияләнүчеләр янына барып, аларга кирәк-яраклар тарата, шунда тәрбияләнүче берничә дистә бала белән уеннар уйнап, аралашып кайта. Билгеле, мондый чаралар һәркемне булганга шөкер итүгә өйрәтә.

Мәдрәсәбезгә Сүрия, Ливан, Мисыр, Һиндстан, Пакыстан, Гыйрак һ.б. дәүләтләрдән кунаклар да еш килә. Аларның да «Мөхәммәдия»гә кереп, укучыларыбыз белән очрашып, үз нәсыйхәтләрен әйткәне бар.

– Әле бит мәдрәсә базасында дин университеты ачу һәм Галиев мәчете белән берлектә тулы бер комплекс төзү идеясе дә тәкъдим ителгән иде...

– Бу тәкъдим булып кына калды. Безнең «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе – бар халыкка билгеле шөһрәтле уку йорты. Ул шушы статуста кала бирәчәк. Чөнки югары дини белем бирә торган уку йортлары бездә җитәрлек күләмдә. Галим булырга теләгән кешеләр күп. Ә менә төрле төбәкләргә барып, гади халык арасында эшләргә теләүчеләр азрак, аларга кытлык сизелә. Мәдрәсәне тәмамлаучыларыбызны эш урыннары белән үзебез дә тәэмин итәбез. Эш бездә дә җитәрлек. Архивларыбызда иске имля белән язылган язмаларны уку өчен дә ихтыяҗ зур.

– «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ачылуга быел 140 ел тулу уңаеннан нинди чаралар үткәреләчәк?

– Бәйрәм чараларыбыз октябрь уртасында булачак, иншаллаһ. Алар ике өлештән: фәнни һәм бәйрәм өлешеннән торачак. Фәнни конференциябездәге чыгышлар, әлбәттә, мәдрәсәнең тарихына һәм борынгы чорда укыткан остазларыбызга, укыту методларына багышланачак.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ХАТЫН-КЫЗ МОНОЛОГЫ

Мин – ут.
Мин төнлә йолдыздай балкыйм.
Мин – җилдә янган учак һәм
Мичтәге тыңлаучан ялкын.

Мин – ут.
Кешеләргә җылы бирәм.
Аларны яныма дәшеп,
Бер табында көрештерәм.

Мин – ут.
Син күңелемне күрергә
Бик ашыкма. Үтә авыр
Җан үзәгемә керергә.

Мине
Көчсез итү, түбәнсетү
Хокуклары берәүгә дә
Бирелмәгән... җанны сүтү...

Мин – ут.
Чын күңелдән килешәм мин:
Бары ихлас елмаюың
Яктысына бирешәм мин.

Наталья Харлампьева 1952 елның 1 сентябрендә Якутия Республикасының Якутск шәһәре читендә урнашкан Маган авылында дөньяга килә. Якутиянең халык шагыйре, прозаик, публицист, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре. Якутиянең Платон Ойунский исемендәге Дәүләт премиясе һ. б. республика, ил һәм дөньякүләм әдәби бүләкләр иясе. Якутия Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Россия Язучылар берлеге идарәсе сәркатибе. Утызлап китап, шул исәптән татар телендә дөнья күргән «Көзге яңгырлар» (2016) җыентыгы авторы. Якут әдәбияты классикларының әдәби мирасын бастыруга, яшь каләм ияләренә ярдәм итеп, әдәби алмаш тәрбияләүгә зур өлеш кертә.

Наталья ХАРЛАМПЬЕВА

ЯПОН БЛОКНОТЫННАН

Түгәрәк кояш – биек галәмдә,
Түгәрәк кояш – ап-ак әләмдә.

Куе кызыл төс җанга үрелә,
Ә ап-агында – хыял терелә.

Әнә теге карт кырыс күренде,
Ә яшь егетнең башы иелде.

Күңлеккә үскән нәни наратлар,
Йөнтәс йолдызлар, – җирне яраткан...

Очраклы кунак мин монда бары,
Әллә төшемдә булганым бармы?..

* * *
Аңлый алмыйм, нигә төшкә керә:
Яшел хәтфә кебек үләндә
Урман эчендәге алтын бия
Колыны белән йөри үзәндә.

Кояш төсендә ул, җиңел, нечкә,
Йә уйный да җан фәрманга җилә,
Йә колыны җиләненә килә,
Колакларын сагайта бу бия.

Гаепледәй, һаман искә алам,
Бу төш җанга мәлләә камыт үргән?
Гүя бермәл кеше бәхетен мин,
Качып кына, чынбарлыкта күргән.

Очраклы кунак мин монда бары, Әллә төшемдә булганым бармы?..

КӨЗГЕ ЯҢГЫРЛАР

Кай тарафка карасаң да,
Офыкны каплап алган –
Нигәдер, көзге яңгырлар
Бу елда соңга калган.

Шыпырт кына килде алар,
Җылытып суык җирне.
Әллә бу соңаруларда
Бер ният бармы, серме?

Яңгырлар килде ерактан,
Җилләргә куна-куна.
Туган җирем туңып куйды,
Бәхетле булып кына.

Тәрәз төбемдә ишетәм
Тып-тып яңгыр тамганын,
Кышка калган уҗымнарның
Уй-йокыга талганын.

Алда суыклар көтелә,
Иңнәрен бөгә урман.
Көзге яңгыр моңнарында
Җир ябына ак юрган.

ХАТ

«Бар эшләреңне калдыр да
Ишет ялваруымны.
Кайт. Беләсең, синнән башка
Утларда януымны».

Хатымны кулга аласың,
Арганыңны беләсең...
Үтенәм: җаваплар язма,
Юлга чык, өлгерәсең.

Сиңа уныш юлдаш булсын,
Барын да оныт, ярам...
Искә ал, яшь елгасында
Мин кайнар утта янам.

* * *
Төннәрен дә, көннәрен дә
Кулымда каләм ныкка,
Үзгәрми ышаначакмын
Гаделлек, яхшылыкка.

Бу инану ярдәм итсен,
Юк әле уфтанасы.
Явызлык авызлыкланып,
Ахырда булсын җиһанда
Яктылык тантанасы!

* * *
Белмим, нигәдер,
Сүнгәчтен учак,
Өем катына
Килдең син берчак.

Ә язмыш-учак
Салды канатын.
Җил буйлап көлне
Үзең тараттың.

Сер итеп саклыйк
Без үткән юлны,
Читләр кермәсен... –
Буласы булды.

Көннәр артыннан
Көннәр атлады.
Учак урынын
Үлән каплады.

Ишегалдымнан
Кит әле торып...
Шул үләннәрне
Таптаудан курык.

ӘНИЕМ ИСТӘЛЕГЕНӘ

1
Әнием кинәт үлде.
Ул бу җирдә юк инде.
Чакырсаң, кире килмәс,
Күңелем – иләс-миләс.
Йөрәктә – авыр сагыш,
Абый белән икебезне
Ятим калдырды язмыш.
Инде өлкән булсак та,
Гаилә, эш дип торсак та,
Үксезлекне тоябыз.
Сорыланды дөньябыз.

2
Әни еш искә алды
Балалык, яшьлек чагын.
Тайга арасындагы
Үзенең туган ягын.
Ул ихлас кеше булып
Киләчәккә юл алган.
Үз бәхетен табарга
Башта ук хыялланган!..
Илгә зур афәт килеп,
Сугыш булыр алдыннан,
Авырлыклар атлаган
Әниемнең янынннан.

Кайгылар урап алган,
Хәсрәтләр сырып алган...
Ул еллар онытылган,
Үткәннәрдә югалган.
Әни еш искә алды
Зәңгәр сулы күлләрне,
Тыныч, карлы тауларны,
Җәйге кызыл гөлләрне...
Әни туган төбәктә
Яхшы рух хөкем сөрә.
Ул якта булалмадым –
Бик кыен шуңа күрә.

Әни, әни, боларны
Җаныңа якын алма!
Җиде күкләр катыннан
Кызыңа ачуланма!..

3
Әлегә көз сулышы
Сизелми әле, әни.
Җирдә – август.
Елга да
Тизлеген киметәлми.
Кырлар көя эсседә,
Башаклар туялмаган.
Каен көз нуры белән
Сарыга буялмаган.
Ә син килгән ягыңа
Кабат киттең... мәңгегә...
Җаныма суык керде,
Салкын үтте тәнемә...

* * *
Шагыйрьнең ние бар? –
Ә яхшы исеме!
Акчасы, байлыгы,
Кереме-төшеме? –

Анысын кем белсен?
Кем сизсен, кем күрсен?..

Ул тишек кесәгә
Кулларын тыгар да
Иртәдән җыеныр
Юлларга чыгарга.

Ачлыктан, суыктан
Калтырап йөрсә дә,
Юлында авырлык,
Михнәтләр күрсә дә,

Сикермәс, йөгермәс
Ул табыш артыннан –
Теләми, кирәкми
Шайтанга тартылган.

Дөньяда ул ярлы
Яшәсә яшәсен,
Биеккә күтәрсен
Күңелен-кәсәсен.

Тарттырсын угына
Очлы, нык җәясен –
Киләчәк гасырлар
Бирер үз бәясен.

ЧҮЛДӘГЕ ЮЛ

Елга юллары кипкән,
Чиксез сагыш – офыкта.
Ничәнче гасыр инде
Җилләр уйный комлыкта.

Ком тузаны эченнән
Бернәрсә дә күренми.
Ә җаным яңгыр булып
Коеп яварга тели.

Чүлнең кайгылы рухы
Еландай шуып кача.
Күңелем елга булып
Аксын иде, ичмаса.

Чүл рухын аңлый алмыйм,
Кумыйм да комнар аша.
Ул тантана итә дә
Аннары ыңгыраша.

Казах дус элеккечә
Тарта моңлы кубызын.
Күз алдымда – сары чүл,
Ә барыр юлым озын.

* * *
Күз карашы – нәни күпер,
Көтмәгәндә салынган.
Якын җаннар арасында
Гүя очкын кабынган.

Туган җанны әллә каян
Йөрәгем белән тоям.
Елмаюдан, сүз катудан
Ачылып китә дөньям. –

Очраклы әйтелгән сүздән,
Бердәнбер шигъри юлдан,
Өмет йолдызына таба
Сузылган җылы кулдан.

Иртәдән кичкә кадәрле
Мәшәкать чоңгылында
Күңелемдә урын табам
Бер уч ихлас җылыга.

ОЧРАШУ

Кем соң белә, соңгы очрашудан
Ничә еллар, гасыр узганын?
Таныш нурлы йөздә мин күрмәдем
Вакыт эзен, вакыт тузанын.

Еракларда калган мәхәббәтне
Чал дәверләр кая яшерә?
Саубуллаштык, бер сүз табалмадык,
Моңлы күздә калды яшь кенә...

Матур сүзләр хәзер эзләмибез,
Киң Галәмдә очып-селкенеп,
Яннан гына узып китәрбез күк,
Ачылмаган ике сер кебек.

Синнән каушамыйча аерылырмын,
Теләсә дә күңел ташырга...
Бәлкем, язмыш безгә язгандыр ул
Ерак киләчәктә очрашырга...

* * *
...Тавыш ишетермен,
Бер чың ишетермен –
Бала чактагыдай
Үземне хис итәрмен.
Берьюлы дүрт яктан
Дүрт җилне дәшәрмен –
Шигыремә керсен:
Ул яши, мин яшәрмен...

Бәла-казалардан
Дүрт билбавым саклый,
Гайрәтле дүрт камчым
Дошман уен каплый.
Офыкка төбәлгән
Моңлы дүрт карашым,
Дүрт төрле гыйлемем
Дөньяга ярасын.

Нәрсә уйласам да,
Җанга нур кундырам,
Якты дөньясында
Барысын булдырам!
Табигатем белән
Без – бербөтен, бергә...
Бер дәшүем җитә
Дүрт җилне
Шигырьгә...

Якутчадан **Ленар ШӘЕХ** тәрҗемәләре.

Укучылар татар теленнән ник имтихан бирми?

Татарстанның җиде районында 9 нчы сыйныфны тәмамлаган укучыларның берсе дә төп дәүләт имтиханы итеп татар телен сайламаган. 11 нче сыйныфтан соң татар теленнән Бердәм дәүләт имтиханы тапшыру турында әйткән дә юк – андый укучы быел Татарстаннан берәү генә.

Милли мәгариф мәсьәләләре турында «Адымнар» күп телле мәктәбендә «Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү» республикакүләм форумында сөйләштеләр.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халык вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов милли мәгариф өчен борчылуын яшермәде.

– Республикадагы татар балаларының дүрттән бере генә туган телендә белем ала. Бу әле – министрлыктан килгән саннар гына. Чынбарлыкта, ул саннар тагын да эч пошырырлык булырга мөмкин. Укытучыларның, мәгариф бүлекләре, мәктәп җитәкчеләренең, укыту буенча урынбасарларның ни дәрәҗәдә татар җанлы булуы мәктәптә татар телен укытуның әчтәлегенә искиткеч зур йогынты ясый.

М.Әхмәтов бүген әти-әниләр белән мөнәсәбәт тә кискен булуын ассызыклады.

– Бик җайсыз холыклы хәзер әти-әниләр: бөтен җаваплылыкны бакчалар, мәктәпләр өстенә салып куйдылар да, гел таләп итеп кенә торалар. Андый әти-әниләр белән эшләгәндә, әлбәттә, бакча, мәктәп бер гаилә була алмый. Бу, үз чиратында, күп кенә проблема тудыра.

Татар теле язмышына килсәк тә, балама ник кирәк дип, рухи ихтыяҗ тоймыйча, матди ихтыяҗ белән генә яши торган әти-әниләр булганда, шул ук вакытта мәктәп җитәкчесе дә татар җанлы булмаса, ул татар теле укытучысы нишләргә тиеш? Аның хәлен аңлап була. Хезмәтенә зур ихтыяҗ тоймый икән, нишләргә кирәк? Безгә бик күп мәсьәләдә бу мөнәсәбәтне җайга салу таләп ителә. Татар теле укытучыларыннан башка телебез язмышын күз алдына китерү дә читен, – дип мөрәҗәгать итте М.Әхмәтов татар теле укытучыларына.

Аның сүзләренчә, «урыннарда татар җанлы район җитәкчеләре, мәгариф идарәсе башлыклары, аларның мәктәпләргә татар җанлы җитәкчеләр куюы да мөһим».

– Милли мәгариф – телебез, милләтебезнең төп умыртка баганасы. Бердәм, зур гаилә булсак, милләтебезне саклап калу мөмкин. Безнең татар язмышы – гомерлек көрәш, ләкин без – дәүләтле халык. Телебез белән горурланырга хакыбыз бар. Ул – бай, хөрмәткә һәм үстерүгә лаек. Без уртак хезмәттә. Без – сезнең иң якын булышчыларыгыз, – ди М.Әхмәтов. Аның бу сүзләреннән соң, һичшиксез, милли мәгариф хезмәткәрләренең җанына җылы кергәндер...

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закированың чыгышы берникадәр укытучыларның үзләренә дә шелтә рәвешендә яңгырады. Баланың имтихан өчен татар телен сайлау белән кызыксынмавында аларның да азмы-күпме гаебе бар, дигән фикер туды.

– Туган телдән дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыру мәсьәләсе Дәүләт Думасы дәрәҗәсендә яңадан күтәрелде. Канун нигезендә, чыгарылыш сыйныф укучыларына туган тел һәм әдәбият фәннәреннән имтихан тапшыру, 9 нчы сыйныфтан соң төп фәннәрдән туган телдә сынау узу мөмкинлеге бирелә. Республикада моның өчен шартлар тудырылган. Кызганыч, татар телендә төп дәүләт имтиханың бирүчеләр юк дәрәҗәсендә, гәрчә ел саен 8 фәннән имтиханнарга әзерләнү өчен биремнәр һәм имтихан материаллары татарчага тәрҗемә ителә. Никадәр укытучының хезмәтен суга салабыз! Балаларыбызны татар телендә имтихан бирү өчен әзерләмибез.

Быел ана теленнән төп дәүләт имтиханын 1367 бала сайлады, шуларның 1262се – татар теленнән. Моннан тыш, укучылар чуаш (70), удмурт (21), мари (14) телләреннән имтихан бирде. Кукмара, Балтач, Чүпрәле, Әлки, Актаныш районы укытучыларына, имтиханнан курыкмыйча, балаларны әйдәп әзерләгәннәре өчен рәхмәт!

Апас, Буа, Алабуга, Кама Тамагы, Менделеевск, Югары Ослан районнары имтиханның бар икәнен дә белми калды, ахры. Тәтеш районында бары тик чуаш теленнән имтихан бирүчеләр булды. Бу районда балалар татар телен өйрәнмимени?!

Бала 9 нчы сыйныфка күчкәнче, 8 сыйныфтан ук кайсы фәннәрдән имтихан бирәсе билгеләнеп куела. Әгәр 7-8 нче сыйныфта бала белән әзерлек эше алып барыла икән, нәтиҗәсе башка булачак. Бигрәк тә барлык фәннәрне дә «5»кә бирә алмый торган балалар турында сүз бара, алар бит бары тик, имтиханны бирә алмам, дип кенә фәнне сайламый. Әгәр укытучысы «әйдә әле, татар теле, әдәбиятын бергәләп өйрәник, син бит үзең сайлап аласың» дисә, укучы бүген атнага бер генә укытыла торган географияне сайлап алырмы, әллә татар телен сайлармы? Бу бигрәк тә авыл районнарына кагыла. Бүген күпме бала география сайлый! Аны җиңел дип белеп сайлый бит ул. Географиягә караганда, баланың татар телен белү дәрәҗәсе күпкә көчлерәк. Нигә шушы мөмкинчелекне кулланмыйбыз?! Әгәр шуннан файдаланып, «әйдәгез, татар теленнән төп имтихан бирәбез, син бирә алачаксың» дисә, ул бала сайлап алмыймы?!

Бүген 9 нчы сыйныфтан соң, югары уку йортларына керә алмый торган балалар көллиятләргә бара, ә һәрбер көллияттә аттестатның уртача билгесе роль уйный. Шушы бәйгедән үтә алмый торган балалар барысы да 10-11 нче сыйныфларга кала. Безнең бүген 10 сыйныфка йә бик көчле – югары уку йортларына керергә атлыгып торган балалар, йә көллиятләргә керә алмыйча, конкурстан төшеп калганнар килә. Бөтен кешегә дә бишлегә уку сәләте бирелмәгән, әмма ул баланы көллияттә һөнәргә өйрәтеп була бит. Безнең бүген ничә көллияттә татар телендә һөнәр өйрәнелә, шушы һөнәрләргә өйрәнсен өчен баланы алдан әзерләп булмыймы? Әлбәттә, бу – безнең балаларга тел өйрәтүнең бер ысулы. Шуннан отышлы файдалансак иде, – дип мөрәҗәгать итте министр урынбасары.

Шул ук вакытта, ул «туган тел» буенча имтихан нәтиҗәләре бер генә уку йортында да керү сынавы буларак кабул ителмәвен искәртте.

– Сынаулар исемлеге Россия Фән һәм югары белем министрлыгы боерыгы белән расланган. Без әлеге исемлеккә «туган тел» фәнен кертүне сорыйбыз. Җавапта, уку йортлары өстәмә эчке имтихан буларак сынау куя ала, дип күрсәтелде. Бу – мәсьәләне чишү түгел, билгеле, шуңа күрә алга таба да бу юнәлештә эшләячәкбез.

М.Закирова мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен югары дәрәҗәдә укытырга чакырды.

– Һәр мәктәптә эш тиешенчә оештырылса иде. Мәктәпләрдә кимендә ике сәгать татар теле һәм әдәбияты укытылу – безнең өстә. Моны карар итеп кабул итик. Урыннарда дөрес эш планнары оештырылып, татар теле һәм әдәбияты дәресләре югары дәрәҗәдә укытылсын иде. Туган тел укытылмаган бер мәктәп тә калырга тиеш түгел. Әзерлекле укытучыларыбыз да, уку әсбаплары да бар.

М.Закирова татар телле мәктәпләр эшендә алдынгы һәм артта калган районнарны атады. Узган уку елында татар телендә белем бирү күрсәткече республикада 24 процент тәшкил иткән, тәрбия сыйныфларын кушсаң, ул 50 процентка җитә.

– 2021-2022 уку елында 629 татар мәктәбе эшләде, шуларның 118е – филиал. Аларда 80 меңгә якын бала укый. Әйдәп баручылардан Азнакай, Актаныш, Мөслим, Саба, Арча, Балтач, Теләче районнары. Шул ук вакытта, Әлмәт, Зәй, Түбән Кама, Чистай, Чаллы шәһәрләре сыната. Нурлат, Питрәч районнарында туган телдә тәрбия һәм белем бирүгә игътибар көннән-көн кими. Лениногорск, Менделеев, Югары Ослан районнары чын мәгънәсендә борчу тудыра. Рус телендә белем бирә торган мәктәпләрдә соңгы вакытта татар телендә тәрбия сыйныфлары ачу тенденциягә әверелде, тик бу –

саламга ябышуга тиң, үзебезне дә, ата-аналарны да алдау, милләтнең тамырына кайнар су кою түгелме?! Бу мәсьәләгә битараф булмасак иде, – дип мөрәҗәгать итте ул.

Министр урынбасары балалар бакчаларына да тукталды. 100 меңнән артык (100864) татар баласы бакчага йөри. Районнардан алынган мәгълүмат буенча, аларның 56,3 проценты туган телдә белем һәм тәрбия ала. Бакчаларда милли тәрбиягә салкын караш Югары Ослан, Менделеев районнарында күзәтелә. Аксубай, Яшел Үзән, Минзәлә, Чистай, Ютазы районнарында активлык сорала. Әйдәп баручылар буларак Актаныш, Апас, Балтач, Биектау, Кайбыч, Мөслим районнары аталды.

– Соңгы өч елда гына да республикада 75 балалар бакчасы төзелде. Бу бакчаларда туган телдә белем һәм тәрбия өчен шартлар тудырылдымы, татар төркемнәре тупландымы, тиешле кадрлар булдырылдымы? Сорау үзебезгә!

Балалар бакчаларында татар төркемнәренең статусын саклау һәм тиешле дәрәҗәдә эш оештыру бары бездән тора. Катнаш төркемнәр – күз буяу гына! Билгеле, беренче чиратта, әти-әниләр белән эшне дөрес оештыру зур урын ала. Бигрәк тә, бу район үзәкләренә һәм шәһәрләргә кагыла, – дип басым ясады ул.

Форумда берничә белем бирү оешмасы мөдирләре чыгыш ясады. Марат Әхмәтов катнашу форсатыннан файдаланып, әллә ни зур проблема күтәрүчеләр булмады. Казан шәһәренең Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе директоры Рамил Гайнуллиннан М.Әхмәтов «нинди ярдәм кирәк» дип сорагач та, «безгә барысы да җитә» дип җавап кайтарды.

Самара шәһәренең аерым фәннәрне тирәнтен укыта торган «Яктылык» мәктәбе директоры Радик Газизов туган телгә кызыксыну уятуда мәктәп һәм гаиләнең үзара бәйләнеше турында сөйләде.

– Татар теле 1 нче сыйныфтан укытыла, 2-11 нче сыйныфларда телне барлык балалар өч сәгать исәбеннән өйрәнә. Татар әдәбияты һәм татар халкы тарихы дәрес буларак укытыла. Балалар бакчасында өч яшьтән балалар татар телен өйрәнә. Әйтергә кирәк: бүген күп кенә әти-әниләр, БДИ тапшырасы бар дип, балаларын туган телне өйрәнүдән мәхрүм итә. Ә татар телен камил белгән балалар бездә рус теле һәм әдәбиятыннан 100 балл җыя, – ди Р.Газизов.

М.Закирова аны мактап, безнекеләрне дә шушы үрнәктә эшләргә өндәде.

– Татар телендә белем алган балалар рус теленнән 100 балл җыйган! Аңлыйсызмы? Без, мәктәпләрдә Татарстан тарихын өйрәнергә сәгатьләр саны юк, дибез. Күпме җитәкче шуны сәбәп итеп куя! Самарада саф татар телендә фәннәр укытыла, һәм бу балалар имтиханнарны 100 баллга бирә! Бу мәктәпкә керергә чират торалар бит! – диде.

Ата-аналар исеменнән Айсылу Лерон чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, татар классларында да төрле мотивацияле ата-аналар бар. Милләткә, телгә битараф булганнары да очрый. Андыйларны Айсылу махсус исемлек белән кызыктырырга кирәк, дигән фикердә. «Татарча белгән баланың өстенлекләрен, татарча белүнең файдасын күрсәтеп төзелгән исемлек белән ата-аналарны кызыктырыйк, шунда алар да «туктале...» дип уйланырлар, бәлки», – диде ул.

РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисенең урынбасары, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе советы рәисе Илдар Гыйльметдинов та сүз сорады.

– Иң зур игътибар балалар бакчаларына кирәк. Иң нечкә урыныбыз ул. Ике телле тәрбиячеләр балаларны уен, әкият, мультфильм формасында кызыксындырса, ата-анасы белән эшләсәк, мәктәптә аннан соң укыту җиңелрәк булачак. Безнең яһүди дусларыбызның бөтен укыту программалары нәни балаларга юнәлдерелгән. Биш яшькә кадәр балалар 3-4 телне үзләштерә ала, алар шундый программалар белән эшли, – дип мисалга китерде.

И.Гыйльметдинов, бүгенге законнар нигезендә, мәктәптә нинди телдә, нинди программалар нигезендә укытуны мәктәп үзе раслаганын искәртте.

– Ата-аналарның да мәктәпнең укыту программаларын сайлап алуда бер катнашы да юк. Якынча тәкъдим ителгән укыту программаларын алсак, башлангыч класслар өчен бишесенең өчесендә туган телләр, урта мәктәптә алты укыту программасының яртысында туган телдә укыту программалары күрсәтелгән. Барысы да үзебездән тора. Кайсыдыр оешмага сылтарлык нигез юк. Нәтиҗә мәгариф системасы җитәкчелеге, мәктәп директорларының теләгеннән тора... Техникум-училищелар бар, татар телен анда ничек укытабыз? Бу эш системалы рәвештә барамы? Техникумда һәрберсендә укыту төрлечә. Аларда, ресурс үзәкләрендә татарча укытырга кем комачаулый? Беркем комачауламый. Үзебездән генә тора. Ә анда бик күп балабыз укый – 55 процент... Югары уку йортларында татарча ниндидер дәресләр бармы? Кем комачаулык итә вузлар белән эшләргә? Бернинди каршылык юк, ләкин без шөгыльләнмибез, – ди И.Гыйльметдинов.

М.Закирова бик ачынып сөйләгән имтихан темасына да тукталды ул. «11 нче класста ник бала татар теленнән имтихан бирми, дигән сорау туа. Ә ул аны биреп, кая керә? Шуңа бирми дә ул аны», – дияе булды, зал да дәррәү алкышлар белән хуплады.

Дәүләт Думасы депутаты Татарстанда татар теленнән сынау нәтиҗәләре азмы-күпме роль уйнаган өч кенә югары уку йорты булуын искәртте. КФУның филология институты, Яр Чаллыдагы педагогика институты, Казан мәдәният институтында бер бүлек.

– Барысы да, берьюлы биш вузга гариза биреп булсын өчен, җәмгыять белемен тапшыра. Берсенә алмасалар, икенчесенә барып карыйлар. Безгә шушы проблеманы хәл итәргә кирәк, аннары имтихан бирдерү турында уйларга була, – диде. Залдан кабат «афәрин» дигән сүзләр ишетелде.

И.Гыйльметдинов сүзләренчә, Россиядә 24 тел – укыту системасында, 57 тел предмет буларак өйрәтелә.

– Тел соңгы вакытта сәяси мәсьәләгә әйләнде. Федераль үзәктә кечкенә мәсьәләләрне хәл итү дә кыен. Кызганыч, анда милли мәгарифне аңлаган кешеләр юк дәрәҗәсендә. Безгә бергәләп күп мәсьәләләрне, аңлата-аңлата, Кремльгә кадәр барып җитәрлек хәлдә эшләргә туры килә, – диде ул.

Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА.

intertat.tatar

Төп адым – балалар бакчасында

«Бала-Сити» күп телле балалар бакчасында «Туган тел фест 2022» республикакүләм фестивале узды. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар телендә белем бирүче тәрбиячеләр һәм укытучылар үз методикалары буенча остаханәләр үткәрде.

Яшел Үзән районының 21 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Гөлнара Баһавиева татар теленә өйрәткәндә «Мавыктыргыч ковробук» уен әсбабын куллану турында сөйләде. Аның әйтүенчә, балалар бакчасындагы рус телле балалар татар теле дәресләренә бик теләп йөри. «Мавыктыргыч ковробук» балалар белән үстерелешле уеннар, дидактик уеннар, уен-ситуацияләре, сюжетлы-рольле һәм бармак уеннары оештыру өчен кызыклы, мавыктыргыч, уңайлы әсбап. Ул 4-7 яшьтәге балаларда татар теле белән кызыксынуны арттыру, пассив балаларны мавыктыру максатыннан чыгып ясалды», – диде ул.

Казанның Совет районы 177 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Зилия Галимуллина нейропсихологик келәм уйлап тапкан. «Бу келәмдә бала ребус чишә, төрле хәрәкәтләр ясый, әйтергә, аңлатырга тырыша. Монда аның игътибарлыгы, фикер сөреше, ишетеп кабул итү сәләте дә үсеш кичерә», – ди ул.

Татарстанның атказанган артисты Миләүшә Шәйхетдинова укытучылар һәм тәрбиячеләрне җыеп, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү остаханәсен күрсәтте. «Татар телен уйный-уйный өйрәнгән вакытта гына, бала телнең кагыйдәләрен дә өйрәнергә тырыша», – дип аңлатты ул.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов фикеренчә, балалар бакчаларында милли телдә мохит булдыру, милли тәрбия бирү өлкәсендә баланың эшчәнлеген көчәйтергә кирәк.

«Шәһәр җирендә торган татар гаиләләрендә татарча аралашалар, бала татар телендә өйрәнә. Бакчага бара да, туган телен оныта. Кемнедер гаепләп әйтүем түгел, безнең гомуми мохитебез шундый. Без, татарлар, болай да кызык кешеләр: сигез татар янына башка милләт кешесе килеп керсә, русча сөйләшә башлыйбыз, өч татар кешесе очрашса да, үзара русча сөйләшәләр. Татар балалары өчен бакчада мохитне, телне саклау белән бергә эзлекле чылбырда алып барырга кирәк. Бәйге, грантлар белән туган тел, рухи ихтыяҗга булган бушлыкны тутырырга тырыштык. Әмма ул тамырдан чара күрү түгел. Аның өчен гаилә, балалар бакчасы, мәктәп һәм республика тормышында милли мохитнең булуы зарур. Җитәкчелекнең татар җанлы булуы, аларның татар теленең киләчәгенә җаваплы каравы да мөһим», – диде ул.

Марат Әхмәтов үзе җитәкләгән комиссия, Татарстан мәгариф министрлыгы, муниципаль хакимият җитәкчеләре балалар бакчаларындагы милли мохиткә, милли тәрбиянең әһтәлегенә күбрәк игътибар бирергә тиеш дигән фикердә. «Без сезгә мөмкинлек тә тудырырга, икенче яктан, сезнең дә ифрат саф татар күңелле булуыгызга без инанырга тиеш, – диде ул. – Баланы үзенең биргән дәресендә авызына каратып, әсир итеп тота белгән укытучылар бар. Балалар бакчада шундый мохиткә килеп эләгеп, туган телен сөендереп кала алса, киләчәге нинди булса да, туган телен онытмаячак».

«Бала-Сити» халыкара балалар бакчасы генераль директоры Альбина Насыйрова «Туган тел фест» фестивалендә Татарстанның Яшел Үзән, Яр Чаллы, Арча, Түбән Кама, Әлмәт һәм Казан шәһәрләреннән 120 гә якын укытучы, тәрбияче спикер буларак остаханә уздыруын әйтте. Күргәзмәдә татар телендә язылган китаплар тәкъдим ителде, чарада аларның авторлары да катнашты. « Иң кызыклы проектларны туплап, аерым методик әсбап нәшер итәчәкбез һәм аны республиканың барлык татар балалар бакчаларына өләшәчәкбез. Тәрбиячеләр, укытучылар методик әсбапны укып, үзләренең программаларына кертерләр дигән өметтә калабыз», – диде директор.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Атнаның сәяси мизгелләре

ШОС ныгыта алырмы?

Россия саклану министры С.Шойгу Хезмәттәшлекнең Шанхай оешмасы (ШОС) илләре саклану министрларының Үзбәкстанда үткән утырышында коллегаларына оешма потенциалының нәтиҗәлелеген хәрби яктан көчәйтергә тәкъдим иткән. Украинада хәрби хәрәкәт темпларының кимүен ул тыныч халык арасында корбаннар санын киметү ниятендә аңлы рәвештә кабул ителгән карар, ә АКШның Украинадагы максатларын Россиянең егәрен стратегик яктан бетерү, дип аңлаткан. Болардан тыш, хәрби министр үз коллегаларына быел декабрьдә Мәскәүдә ШОС һәм БДБ илләренең, шулай ук дустанә саналган башка илләрнең дә саклану министрлары утырышын үткәреп, коалицион иминлек мәсьәләләрен күтәрергә тәкъдим иткән. Әмма кайбер сәяси вә хәрби күзәтүчеләр мондый планнарга бик сүлпән карый, әлеге оешмаларның аморф хәлендә калуын искәртә.

Бүген Көнчыгыш хәрби округы территориясендә «Восток-2022» дигән стратегик максатлы команда-штаб хәрби өйрәнүләре үткәрелә. Алар 7 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Күзәтүчеләр исә анда ОДКБ һәм ШОС илләреннән, шулай ук Әзәрбайҗан, Алжир, Әрмәнстан, Беларусь, Һиндстан, Казахстан, Кыргызстан, Кытай, Лаос, Монголия, Никарагуа, Сүрия һәм Таҗикстаннан катнашыр, дип көтелә. Гаҗәп хәл, хәтта ошбу кыска хәбәрләрдән үк тә оештыручы якның үз тарафдарларын ишле итеп күрсәтергә тырышуы сизелә. Әлбәттә, психологик яктан бу күп нәрсә турында сөйли.

Башка хәбәрләрдән, бу атнада МАГАТЭ миссиясенең Запорожье АЭСына килергә чыгуы, бу сәфәрнең уңышлы үтүендә Мәскәүнең кызыксынган булуы турында да әйтелә. Шул ук вакытта, миссия Киев аша килгән очракта, аның иминлеген Украина кайгыртырга тиешлеге турында да искәртелә. Хәбәрләрдә шулай ук Украина кораллы көчләренең көньяк юнәлешендә (Херсон өлкәсендә) һөҗүм итәргә маташуы турында әйтелә. Алмания канцлеры Олаф Шольц исә, Украина, Молдова һәм Көнбатыш Балканны (соңрак – Грузияне дә) оешмага әгъза итеп алу хисабына, Европа Берлеген киңәйтергә чакырган.

Фоат УРАЗАЙ.

КУРАЙ

Антон ЧЕХОВ

(Дәвамы. Башы 33 нче санда).

Менә син шуны гына кара: мин бит инде җиденче дистәм белән барам, ә үзем көнтаң атса көтү көтәм, өстәвенә әле егерме тиен көмешкә төннәрен ат сакларга чыгам, йокы да юк, тынмыйм да; ә менә улым үземнән акыллырак, шуны син минем урынга куеп кара – иртәгә үк эш хакын күтәрүне таләп итәчәк яисә хастага сабышачак. Шулай менә эшләр.

Ашарыма ипекәй булса, миңа бүтән нәрсә кирәкми, Ходай тәгалә ипекәйдән аермасын, минем атам да, бабам да ипекәйдән гайре нәрсә ашамаган, ә бүгенге мужикка чәе дә, мәе дә, күмәче дә булсын, йокысын да ул бер яктыдан икенче яктыга шае симертсен, дәвасы да, төрле-төрле шайтан чигүе дә булсын аңа. Ә ник дисеңме? Егәрсезләнде ул – шуңа күрә шулай, чыдарлык хәле юк аның. Йокламас та иде югыйсә – күзе йомыла, берни эшләр хәле юк.

– Дөресе дә шулай шул, – дип ризалашты Мелитон, – юньсезләнде хәзер мужик дигәнең.

– Яшерен-батырын түгел – елдан-ел койтылана барабыз. Байларны алып карасаң инде – алары мужиктан да ныграк бетереште. Хәзерге бариннның дөньяда белмәгәне юк, кирәген дә, кирәкмәсен дә белә, ә белүеннән аның ни файда? Өстенә карасаң, кызганып үләрсең... Ябыктыр үзе, хәлсездер, берәр төрле венгр яисә француз диярсең, сын дисәң сыны юк, кыяфәт дисәң – анысы юк, барин дигән исеме генә бар инде шул. Ни урыны юк мескеннең, ни эше, нәрсә кирәксенгәнен дә белмәссең үзенең. Йә ул кармак тотып балык каптырмакчы булып утыра, йә корсагын кояшка куеп китап укып ята, йә инде гел булмаса мужиклар арасында уралып юкны-барны сөйләнеп йөри, ә тамагы ачлары писерлеккә яллана. Шулай юк-бар белән яши бирә, берәр юньлерәк эш белән шөгыльләнергә кирәктер дип уйлап та карамый. Элеккеге байлар яртылаш генерал була торганнарые, ә хәзергеләре әллә ниткән салам торханнар шунда.

– Чыннан да, бигрәк бетеренделәр инде, – диде Мелитон.

– Аллаһы тәгалә көчләрен алганга күрә бетеренделәр дә инде алар. Ходайга каршы барып кара син!

Мелитон карашын тагын бер ноктага төбәде. Бераз уйланып алгач ул җае белән генә фикер йөртә торган сабыр табигатьле кешеләрчә көрсенеп куйды да башын чайкап болай диде:

– Нидән килә диген син боларны? Бик күп гөнаһ кылабыз, Ходайны оныттык... ахыр заман җитеп килә, күрәмсең. Соң бит инде дөнья да мәңгелек түгелдер – ул да бер бетәргә тиештер.

Көтүче көрсенеп куйды һәм, бу күңелсез сөйләшүне туктатырга теләгәндәй, каен яныннан бер читкәрәк китеп басты да күзе белән генә сыерларын барлый башлады.

– Аһа-һай! Аһа-һай! Ах, мур кыргырлары! – дип кычкырды ул. – Шушы чытырман арасына килеп кермәсәгез! Һай! – диде ул.

Чыраен сытып ул көтүен җыярга дип куакларга таба китте. Мелитон да урыныннан кузгалып, әкрен генә урман кырыйлап китеп барды. Ул аяк астына карап уйланып атлый: үлем җиле кагылмаган нинди дә булса берәр нәрсәне әле һаман да исенә төшерәсе килә иде аның. Кыйгачлап яуган яңгыр пәрдәсендә якты таплар тагын йөгерешә; алар агач башларына кунып, юеш яфраклар арасында юк булды. Дамка куак төбендә яткан бер керпе янына килеп чыкты, хуҗасының игътибарын шуңа юнәлтергә тырышып, улый-улый өрә башлады,

– Кояш тотылдымы сездә, юкмы? – дип кычкырды куаклар арасыннан көтүче.

– Тотылды! – дип җавап бирде Мелитон.

–- Бөтен җирдә дә тотылды дип зарлана шул халык. Күгендә дә тәртип юк дигән сүз була бит инде бу. Тикмәгәдер дисеңмени... Иһи-һи-и!..

Көтүен урман кырыена куып китергәч, көтүче каенга барып сөялде, башын күтәреп күккә карап алды, аннары, ашыкмыйча гына куеныннан кураен чыгарып, уйнап җибәрде. Ул элеккечә үк аңсыз гына уйнады; биш-алтыдан ары нота алмады; әйтерсең лә курай аның кулына беренче мәртәбә килеп элеккән, әйтерсең лә аның тавышы теләр-теләмәс кенә, көй булып оешмыйча, тәртипсез рәвештә генә чыга, әмма дөнья бетүе турында уйланып торган Мелитонга курай тавышы ничектер бик моңсу да, күңелсез дә булып ишетелә иде, шуңа аның бер дә тыңлыйсы килми иде. Гел дерелдәп торган, өзгәләнеп торган иң югарыгы чиелдык ноталар әйтерсең лә юатып булмаслык итеп җылыйлар, әйтерсең лә курай авыру иде һәм нидәндер курка иде, ә инде иң түбәнге ноталар ни өчендер томанны, моңсу агачларны, соры күкне хәтерләтә иде. Мондый музыка шушы һава торышына да, картның үзенә дә, ул сөйләгән сүзләргә дә ятышып тора иде кебек.

Мелитонның зарланасы килде. Ул карт янына килде дә аның мыскыллы сыман моңсу йөзенә, кураена карап мыгырдап куйды:

– Яшәүләре дә читенләште бит, бабай. Яшәрлек рәт калмады. Игеннәрнең уңмавы, хәерчелек дисеңме... Мал-туарның үлеп торуы, авырулар дисеңме... Нужасы теңкәгә тиде.

Приказчикның тулы йөзе бурлаттай кызарды, сагышлы чыраена хатын-кыз кыяфәте чыкты. Үзенең халәтен әйтеп бирү өчен сүз эзләгәндәй, ул бармакларын кыймыл-камыл китерде һәм дәвам итте:

– Сигез бала, хатын... әнкәй дә исән әле, жалунья аена нибары ун тәңкә, ашарга да шуннан. Хәерчелеккә чыдый алмыйча, хатын чистый иблискә әйләнде... Үзем баш күтәрми эчәм. Үзем тәпле, тәртипле кеше мин югыйсә, белемем дә бар. Тыныч кына өйдә утырасы иде дә бит, ә мин менә мылтык күтәреп, көн буе эт кебек чабам, шулай итмәс идем, өйдән гарык булдым.

Теленең бөтенләй кирәксез сүз сөйләгәнен, кирәклесен сөйләмәгәнен тоеп, приказчик кул селтәде дә ачынып болай диде:

– Бетәсе булса тизрәк бетсен иде инде бу дөньясы да! Зерәгә кеше җәфалап сузып торасы юк...

Бабай авызыннан кураен алды да, бер күзен кыса төшеп, кураеның бәләкәй тишегеннән карады. Аның сагышлы йөзенә күз яше кебек эре тамчылар чәчрәгән иде. Ул елмайды.

– Кызганыч шул, туганкай. И Ходаем, бигрәкләр дә кызганыч шул! – диде ул. – Җир, урман, күкләр... Һәртөрле бөҗәкләр – болар барысы да бер-берсенә яраштырып яратылган, һәрберсенең үзенә күрә аңы бар. Бер дә юкка гына әрәм була бит барысы да. Барыннан да бигрәк кеше жәл.

Урман эчендә эре яңгыр шыбырдый башлады. Мелитон яңгыр шаулаган якка таба карап алды, төймәләренең барысын да төймәләде.

– Авылга таба кайтам әле, – диде ул. – Хуш, бабакай. Ни атлы буласың әле син?

– Ярлы Лука булам мин.

– Ярый, хуш, Лука. Тәмле сүзеңә рәхмәт. Дамка, әйдә.

Көтүче белән хушлашкач, Мелитон башта урман кырые буйлап, аннары сазлыкка күчә барган болын буйлап атлар-атламас кына түбән таба төшеп китте. Аяк астында су лычкылдый, әле һаман да яшел һәм сусыл килеш торган кыяк үлән, тапталудан курыккандай, җиргә иелә иде. Сазлык артындагы Комлы елга буенда бабай сөйләгән таллар тора, таллар артыннан күгелҗемләнеп байларның әвене күренә. Бар табигатьтә ямансу, күңелсез вакытның котылгысыз якынлашуы сизелә – тиздән басулар кара-кучкыл төскә керер, җир өсте юеш һәм салкынга әйләнер, еламсар таллар тагын да боеграк күренер, аларның чуклары буйлап күз яшьләре агып төшәр, фәкать торналар гына гомуми афәттән качарга тырышырлар, моңсу табигатьне рәнҗетүдән курыккандай, аларның авазлары да күк йөзендә хәсрәтле, сагышлы булып яңгырар.

Мелитон, курай моңының әкренләп тына баруын тыңлый-тыңлый салмак кына елгага таба атлады. Аның әле һаман да кемгәдер зарланасы килә иде. Ул сагышланып як-ягына каранды һәм аңа күк йөзе дә, җир дә, кояш та, урман да, Дамкасы да чамасыз кызганыч булып тоелды, ә инде курайның иң нечкә авазы сузылып кына һавадан үтеп, елаган кеше тавышыдай калтырана башлагач, табигатьтәге тәртипсезлеккә ул үтә дә гарьләнде, хәтере калды.

Нечкә аваз соңгы тапкыр калтыранып алды да кисәк өзелде, курай тавышы тынып калды.

С.ИБРАҺИМОВА тәрҗемәсе.

Качкару авылы



Татар авылларының тарихын яктырткан басмалар чыгу Татарстан өчен генә түгел, татар дөньясы өчен дә хас. Кулыбызда – шундыйларның күркәм бер үрнәге. Ул әле табадан гына төшкән, 2022 елда нәшер ителгән. «Качкару авылы тарихы» дип исемләнгән бу китапның (Пенза. 438 б.) тышлыгын дүрт манаралы ике катлы «Зөһрә мәчете» бинасы бизи. Бу гыйбадәт йортын әлеге китап авторларының берсе (Бакир Акъегет) төзетә һәм аңа әнисенең исемен бирә. Бу игелекле заттан тыш, Качкару җыентыгын язу һәм төзүдә аның Кадир Акъегет, Идрис Дубин һәм Абдулхак Тенишев кебек авылдашлары да катнаша. Китап татар һәм рус телләрендә язылган.

Качкару (аның рәсми исеме – Кутеевка) Пенза өлкәсе Белинский районына керә. Өлкә үзәгеннән 92 чакрым ераклыкта урнашкан. Ул билгән урыннар – элек-электән безнең әби-бабаларыбыз гомер кичергән төбәкләр һәм илләр (Хәзәр, Болгар дәүләтләре, Алтын Урда, Казан ханлыклары); артык ерак кына түгел– Җучи Олысының Үкәк, Наручат (Мукшы) калалары.

Авылның кайчан нигезләнүе тәмам ачыкланмаган, берәүләр аны 1445 елга нисбәт итә. Әмма рәсми фәндә Качкару тарихын 1698-1700 еллардан башлау кабул ителгән. Аны нигезләүчеләр итеп Ломов, Темников, Кадом, Керенский һ.б. өязләрдән килгән «йомышлы» татарлар исәпләнә. Болар арасында беренчеләрдән булып «Кайбелев Котбеддин — Коти бабай» атала. Авылның Кутеевка исемен дә шушы зат атамасына бәйләп карыйлар. Ә инде Качкару исеме, авторларның берсе А.Тенишевның аңлатуынча, «качу» сүзе белән бәйле. Заманында, имеш, биредә качкыннар, иреккә сусаган кешеләр җыела торган була.

Пенза тарафында яшәүче милләттәшләребез (алар саны 90 мең тирәсе) өлкәнең төрле җирләрендә гомер кичерә. Әмма аларның чагыштырмача оешып яши торган төбәкләре дә бар. Шундыйларның берсе – «Алтыавыл». Бу исем Качкару һәм аның тирәсендәге Мачали, Кикин (Яндовище), Кобылкин (Новоселок), Решетино авылларына карата кулланыла. Бу салаларның барысы да диярлек бер чорда нигезләнә. Кешеләренең күчеп китү географиясе һәм составы белән дә бу авыллар шактый охшаш. Берничә гасырлар буе Алтыавыл халкы үзара аралашып яши. Аларда бер үк исем-фамилияләрнең (Акъегетов, Тенишев, Дубин, Кайбелев, Дашкин...) күпләп кулланылуы, сөйләмнең, гореф-гадәтләрнең уртаклыгы да нәкъ шуның белә аңлатыла. Шунысы кызык: бу төбәктәге аерым нәселләр ДНК ягыннан да тикшерелгән икән. Аларның кайбер нәтиҗәләре әлеге җыентыкта да бәян ителгән (15-17 б.)

Мәгълүм ки, Урта Иделдә, хәзерге Пенза, Тамбов, Ульян, Сарытау өлкәләрендә, Мордовия республикасында элек-электән гомер кичергән татарларның бер өлеше патша хөкүмәтенең колониаль сәясәте аркасында чукынырга, дин һәм милләтләрен алыштырырга мәҗбүр ителә. Лермонтов, Куприн һ.б. күренекле затларның нәселләре татарлар белән бәйләнешле. Урта Иделдәге күп кенә авыл-шәһәрләрнең, географик атамалар татарча яңгырый. Качкару урнашкан районның элеккеге исеме Чембар. Ул – русның мәшһүр заты В.Белинскийның туган җире. Ерак кына түгел – Тархан авылы. Анда бөек М.Лермонтов берничә ел буе үз әбисенең утарында тәрбияләнә. Биредә хәзер искиткеч бай музей. Анда ил һәм халыкара күләмдә төрле чаралар уздырылып тора.

«Алтыавыл»дан татарның шактый гына галим-әдипләре, дин әһелләре, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре, дистәләгән генерал, полковниклар чыккан. Татар мәгърифәтчелек әдәбиятының күренекле вәкилләре Муса Акъегетзадә (1864-1923), Заһир Бигиевнең (1870-1907) асыл ватаннары – шушы «Алтыавыл» төбәге.

Качкару тиз арада үсеп, зураеп китә. 1723 елда анда 53 хуҗалык, 404 ир-ат булса, 1864 елда ир-атлар саны 1666 га, 1896 елда 2391 гә җитә. Соңгы ярты гасырда халык саны әкренләп кими бара. 2004 елда 413 хуҗалык, 1130 кеше булса, 2021 елда авылда яшәүчеләр саны 681 гә генә кала. Шуңа нисбәтән, мәктәптә укучы балалар да азаеп бара.

Качкару халкының элек-электән үк төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. Һөнәрчелек, сәүдә белән көн күрүчеләр дә бар. Шуңа нисбәтән китапта «Авылның оста куллары» исемле бүлек тә бирелгән. Төрле төбәкләр, аеруча Әстерхан, Ростов, Баку, Петербург, Мәскәү белән бәйләнештә яшиләр. Казан белән дә элемтәләре тотрыклы. Күпләгән качкарулылар Пензада гомер кичерә. Алар арасында җитәкче урыннарда, җаваплы тармакларда эшләүчеләр дә бар. Авторлар язуынча, Качкару белән бәйләнешле Байкин Рәшид Заһидулла улы – Россия президенты аппаратында департамент җитәкчесе, Узбеков Вилдан Сөләйман улы Россия прокуратурасы урынбасары булып эшли.

«Качкару... тарихы» – китабында гаять күптөрле факт-мәгълүматлар, документлар тупланган, гыйльми әдәбият та мул файдаланылган. Авыл һәм аның кешеләре турындагы матбугатта басылган язмалар да махсус бер бүлек итеп бирелгән. Җыентыктагы фотосурәтләр, иллюстратив материаллар да авыл турындагы күзаллауларны тулыландыра. Качкаруның җитәкчеләре, колхоз белгечләре, зыялылары махсус бүлекләрдә яктыртыла. Авылда электән бирле мәчет-мәдрәсәләр эшләп килә, шуңа нисбәтән халык белем-мәгърифәт ягыннан шактый югары тора. Чоры белән 4-5 әр мәчет эшләп килә. [Җыентыкның 289 битендә «до Октябрьской революции 1917 года в селе была сплошная неграмотность» диелгән. Әмма бу җөмлә реаль хакыйкать белән һич тә керешми.]

Авторлар алар хакында, имам-муллалар турында да шактый тулы белешмәләр бирә. 36-39 нчы битләрдә, нигездә, XIX гасырга мөнәсәбәтле каберташ язмалары да урнаштырылган. Дистәләгән нәсел шәҗәрәсе дә бар. Илнең башка салаавылларындагы кебек, Качкару халкы да мәмләкәтнең азатлыгын, иминлеген яклап төрле сугышларда катнаша, күпләгән кешеләрнең гомерләре өзелә. Ватан сугышында һәлак булучыларның саны гына да 183 кә җитә. Китапта боларның һәм орденнар белән бүләкләнүчеләрнең исемлеге дә бирелгән. Шунысы гаҗәп: баксаң, 12 генерал [Вилдан Узбеков (генерал-полковник), Рәшид Байкин, Идрис, Илнур, Хәлил Дубиннар, Равил Мусаутов...], 8 полковник (Рифат Акъегетов, Рафик Бибяков...) чыгышлары яисә нәсел-шәҗәрәләре белән Качкаруга мөнәсәбәтле затлар икән. Соңгы ярты гасыр татар дөньясында билгеле шәхес, полковник, Әстерхан төбәгендә җаваплы урыннарда эшләгән Әнвәр Алмаев тумышы белән Качкарунықы. Авторлар Госманлы империясенең атаклы генералы «Шакир паша – Яваев Мөхәммәтшакир улы»ның да үз авыллары белән бәйләнешле булуын искәртә. Халкыбызның Качкару белән бәйләнешле атаклы кешеләре — галим-голямаларына да җыентыкта урын бирелгән. Болар арасында күренекле тюрколог, күп кенә татар филологларының остазы Әдһәм Рәхим улы Тенишев (1921-2004) та бар. 2006-2014 елларда Татарстан Фәннәр академиясен җитәкләгән, мәшһүр химик-технолог, техник фәннәр докторы Әхмәт Мазһар улы Мазһаровны да качкарулылар үз якташлары итеп хисаплый. Аның әби-бабалары бу төбәктән. Әхмәт әфәнденең бабасы Мирхафиз Кайбелев Кышкар мәдрәсәсен тәгәлләгәч, Балтач районының Сосна авылында мулла булып төпләнеп кала. Татарстан телевидениесендә шактый еллар диктор булып эшләгән, күренекле журналист, филокартист Абдулла Дубин да, гәрчә Әстерханда туып-үссә дә, үзен Качкару белән бәйләнешле саный. Шунысы кызыклы: аның бабаларының берсе заманында М.Лермонтов әбисенең Тархандагы утарында хезмәт иткән. «Атаклы кешеләр» бүлегендә бу юлларның авторына да урын бирелгән.

Мин бу авылда тумаган, нәсел-нәсәбемнең дә аның белән бәйләнеше юк. Әмма Качкару Хатыйп Йосыф угылы өчен шактый якын, кадерле. Моның нигезе бар. Тукай әйтмешли, «Гәрчә анда тугмасам да, мин бераз торган идем». Гомеремнең төп өлеше укыту-тәрбия эшләре белән бәйле. Педагогик стажым 60 елга якын. Шуның тәүге адымнарын мин Качкару мәктәбендә ясадым. Безне, Казан университетының IV курс студентларын, читтән торып укуга күчереп, бер елга төрле өлкә-республика мәктәпләренә тараттылар. Язмыш мине Пенза тарафларына ташлады. 1962-1963 уку елында Качкару мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты, бераз вакыт немец теле укыттым. Качкару укытучылары, бигрәк тә мәктәп директоры Якуб ага Сабанчеев, шулай ук укучылар, авыл халкы миңа ярдәм итте. Фатир хуҗасы Айшә апа пешергән коймаклар, тәмле ризыклар әле һаман да искә төшеп тора.

Мин эшләгән чорда Качкару шаулап, тулы канлы тормыш белән яши, мәктәбендә 300 дән артык бала укый иде (хәзер укучылар саны ике-өч дистә генә). Укучылар белән Тарханга, район үзәгенә, Лермонтов, Белинский музейларына барулар хәтергә уелып калган. Аз-маз җирле тарихны да өйрәндем. Бу тарафтагы рус авылларында яшәүчеләрнең бер өлеше - руслашкан татарлар. Заманында Аргамаковога бөек җырчы Ф.Шаляпин да килгән. «Ул, — дип сөйләделәр миңа,— Казанда яшәгән чордан ук үзенә таныш һәм якын булган татар моңнарын тыңларга дип Кутеевкага да бара»...

Гомумән, Качкару турындагы бу китап энциклопедик рәвеш алган. Анда авылның тарихы да, соңгы дәвердә яшәеше дә төрле яктан яктыртылган.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.

Асия Глебова менә 35 елга якын композицияле курчаклар иҗат итү белән мәшгуль. Аның милли киемле курчаклары күп дәүләтләргә таралды, Казанга килгән туристлар да аларны үз итә.

КУРЧАКЛАРДА

«Мәктәптә чакта ук кызлар арасыннан берүзем металлны чокып бизәк ясау түгәрәгенә йөрдем, калганнары малайлар иде, – дип искә ала Асия ханым. – Эшләнмәләрем белән бәйгеләрдә катнаштым һәм шәһәр буенча беренчелекне дә яуладым. Бу шөгылемнең соңрак, курчакларга сугышчан киемнәр ясаганда, кирәге дә чыкты.

Югары белем алгач, заводта икътисадчы булып эшләдем. Декрет ялында исә Казанның 16 нчы һөнәри училищесын тәмамладым. Аннары, төпчек улымны тапкач, заводка әйләнеп кайтасым килмәде. Үзгәртеп кору еллары иде. Баштарак агач әйберләр бизәп саттым. Шуннан соң коллекцион курчаклар ясау шаукымы кузгалды. 1988 елны шушы өлкәне сайладым. Мәскәүгә барсам, мондый курчаклар – кыйммәт, ә үзләре – ямьсез... Осталарның берсе дә үз тәҗрибәләре белән уртаклашмый, әгәр берәр техник алымын сорашсаң, син аларга чын дошман... Ул чакта интернет та юк иде әле. Һәммәсенә үзлегемнән төшендем. Дус рәссамнар да курчаклар ясый башлады, тик бу шөгыль аларны тиз туйдырды, янә картиналар ясауга күчтеләр. Ә мин декоратив-гамәли сәнгатьнең шушы юнәлешеннән беркая да китмәдем.

Әүвәл кибеттәге фабрика курчакларын алып, шуларны үзгәртеп иҗат иттем. Йөзләрен дә яңабаштан буядым, гәүдәләрен дә озынайттым, өсләренә татар киемнәре кидердем. Аларны Сынлы сәнгать галереясы кибетенә алып барган идем, сатучыларның фикере бер булды: «Мондый курчакларны күптән көтә идек, ярый әле килдегез!» Тәүге курчакларым тиз сатылды. Шул акчага кибетләрдән янә 90 курчак сатып алдым да, үземчә үзгәрттем. 1990 елларда хәзерге кебек материал муллыгы да, социаль челтәрләр дә юк иде шул... Татарстан Министрлар Кабинетына юнәлдем. Андагы хезмәткәрләр курчакларымны бүләк өчен алды. Аннары Казан дәүләт университетына юл тоттым, андагы аспирантлар, чит ил кешеләре, курчакларны күпләп алып, почта аша АКШка да салды. Минем белән дуслашып киттеләр. Шулай итеп, милли киемле курчаклар ясау остасы булып таныла башладым. Министрлар Кабинеты белән хезмәттәшлегем әле дә дәвам итә. Ә менә халык һөнәрчелеге һәм кәсепчелеге палатасыннан үз теләгем белән чыктым. Чөнки бу палатаның минем өчен кирәге юк иде», – ди Асия Глебова.

Аның искиткеч эшләнмәләре Франциядәге мәдәни чаралар кысаларындагы күргәзмәләр барышында Парижда, Дижонда күрсәтелгән, соңрак Мюнхен, Ганновер тамашачыларын да сокландырган. Останы төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләргә бүген дә чакырып торалар. Тик ул аларны өнәп бетерми. Күргәзмәләрдә

катнашуның мәшәкате күп. Арадан 2018 елда узган XIX Истанбул Халыкара мәдәният һәм сәнгать күргәзмәсен генә истә тота ул. Ул вакыт Асия ханымны улы Руслан белән бергә Төркиягә чакырганнар. «Башта Бүюкчекмеҗедә, аннары Истанбулда үтте әлеге күләмле чара, – дип искә ала ул. – Без урта гасырлардан сакланып калган, Бөек Ефәк юлында торучы борынгы кунакханәдә тукталдык. Көн саен үз рәтләребезгә зур, борынгы капкалар аша кереп йөрдек, тарихның чын сулышын тойдык. Таш диварлардагы чокып ясалган урыннарга тауарларыбызны тезеп куя идек. Осталык дәресләре дә үткәрдек, кичләрен диңгез буенда төрек эстрадасы артистлары концертларын тамаша кылдык. Безнең тауарларыбызны махсус йөкчеләр ташып йөрде, менә шундый бик югары дәрәҗәдә оештырылган чарага шәһәр башлыгы да килеп, һәрберебез белән сөйләшеп, фотосурәткә дә төште. Ихтирам чиксез иде, намаз өчен бүлмәләр дә булды, төрле экскурсияләр дә оештырылды, һәр остага бүләкләр дә тапшырылды. Әлеге күргәзмәгә бихисап дәүләт осталары җыелган иде, ә Татарстан сәнгатен нибары мин һәм күннән кул эшләнмәләре ясау остасы Анна Буркова тәкъдим итте. Бар осталар канәгать калды. Менә кемнәрдән үрнәк алырга кирәк безнең мәдәният җитәкчеләренә! Төрекләрдән!

Әйе, иң беренче иҗат иткән курчагым - татар кызы кыяфәтле курчак иде. Аны ясап бетергәч тә, әүвәл әтиемә күрсәттем. Әтиемнең исе китте. Ул гомер буе суыткычлар ясады бит. Үз эшен бик яхшы белүче, алтын куллы кеше иде, кызганыч, инде вафат. Әнием Ләлә Зыя кызы да иҗатымны һәрчак күзәтеп бара. Ул гомер буе мотор төзү заводында конструктор булып эшләде. Аның холкы шундый, яңа кул эшләнмәмдә берәр җитешсезлек күрсә, бу хакта миңа әйтми калмый. Әниемдә шушы сыйфат

ТАТАР РУХЫ

булуы яхшы, чөнки калганнар мине гел мактап аптырата.

Нәселебез – сәләтле шәхесләрдән. Дәү әтием Зыя – Бөек Ватан сугышына кадәр Казанда мәшһүр футболчы, ак атка гына атланып йөргән офицер булган, 1937 елда гаиләсе белән Ерак Көнчыгышка киткән, фронтта хәбәрсез югалган. Әбием Галия мандолинада яхшы уйнаган. Әниемнең бабасы Газизҗан, мулла улы, Казандагы Ленин исемендәге республика китапханәсенең беренче директоры булган, шунда 30 ел эшләгән!

Бабам Солтангази дә, аның ике улы да сугыш кичкән, медальләр белән әйләнеп кайта алган. Бабам сугышта да намаз укыган. Әтием Мөгавия 19 яшендә электрик-механик булып, сугыш елларында аэродромдагы очкычларны рәтләгән, бер очкычның чыбыклары тәмам эштән чыккач, шуларны бер төн эчендә рәтләп чыга алган! Аның абыйсы Миңнегази мәктәптә укытты, агач әйберләр ясау остасы, яхшы станокларда бар төр җиһазны ясап, җыя иде. Әтиемнең энесе Рәшит скрипкалар ясады, гомере ахырында муллалыкка укыды. Әтиемнең бертуган энесе Миңнехан Әбдиев исә өч төр гармунда уйный, бик яхшы җырлый да! Башкортстанда бик мәгълүм шәхес. Миңнехан абый – Россиянең атказанган төзүчесе, СССРның танылган уйлап табучысы. Аның исем-дәрәҗәләре бихисап. Аның белән бик горурланабыз. Нәсел рухын тоеп яшибез».

Иҗат башында Асия ханым курчакларны бары тик фотопортретларга карап кына ясаган. «Иң беренче булып бер эшкуар мөрәҗәгать итте, кемгәдер үзенчәлекле курчак бүләк итәргә теләи. «Шушы шәхескә охшатып, курчак ясап бирегез әле», дигәч, эшкә керештем. Мин генерал Мәхмүт Гәрәев өчен аңа охшаш курчак ясадым. Генерал әлеге бүләкне бик ошаткан, хәтта телевизион тапшырулар барганда, әңгәмәләр үтә торган җирләрдә дә шул курчакны үз янына куеп сөйли торган булган (Мәхмүт Әхәт улы 96 яшендә дөнья куйды). Ул, җитәкче урыннарда хезмәт иткән олпат шәхесебез, Россия хәрби фәннәр академиясе президенты иде. Балачагымда әти-әнием аның «Маршал Жуков» китабын укыды, үземнең дә аннан өзекләр укып утырганымны хәтерлим әле... Шушы каһарманның курчагымны ошатып кабул итү – минем өчен зур дәрәҗә!

Шуннан соң андый төр курчаклар шактый ясалды. Аларны күбесенчә юбилей уңаеннан хәрбиләргә бүләк итәләр иде. Ләкин бу төр кул эшләнмәләреннән тәмам туеп туктадым. Менә пандемия килеп, хәйран ял иткәч, янә шушы төр эшләнмәләргә заказлар кабул итә башладым.

– Асия ханым, курчак ясаучылар үз иҗатларында гайре табигый хәлләр, мистика белән очрашулары хакында еш сөйли...

–Минем мистика белән очрашканым булмады. Һәр иҗатчы эшләнмәсенә үз уй-фикерләрен, үз энергетикасын күчерми калмый. Мин бит игелекле йөзле, матур курчаклар гына ясыйм, ә мистика яхшы энергетика белән генә бәйле түгелдер.

– Тик шулай да курчаклар барыбер кешеләр өчен ниндидер резонатор булып исәпләнә...

– Килешәм. Курчакларымны иҗат итә башлар алдыннан уйланам: «Бу курчак кешеләргә ни бирер, аларны нәрсәгә өндәр? Аларның аерым этнотиплы, ябык, матур киемле булулары минем өчен бик мөһим. Чөнки рухи кыйммәтләр, милли киемнәребез – геннарымда. Җаным шушындый төрдәге курчаклар ясавымны таләп итә. Мондый итагатьле курчакларга карап та кешенең эчке тәрбиясе артырга мөмкин. Моңа бер мисал бар. Бер дустым, ир туганына дип, милли киемле, кулларына дисбе тоткан парлы курчак алган иде. Ир туганы аларга карап, һәр көн саен сокланган да үзенең холкының яхшыруын сизгән. Нәтиҗәдә, аракы эчүен бөтенләйгә ташлаган. Дустым миңа бу хакта үзе әйтте. «Курчаклар аша үземә дә мөселманнарга хас сыйфатлар кирәклеген төшендем», – дигән әлеге ир-ат.

– Асия ханым, сезнең курчакларыгыз нинди материаллардан иҗат ителә?

– Курчакларның формаларын үзем ясыйм. Аларның гәүдәләре, башлары – бик чыдам, үтә дә сыйфатлы гипстан. Битләре исә һәрчак чит ил буяуларын кулланып ясала, күбесенең йөзе ялтыравык лак белән дә каплана. Ә куллары пластиктан ясалып, мичтә чыныктырыла. Кул эшләнмәсе сәнгать әсәренә әйләнсен өчен, аңа күп детальләр өстәргә кирәк. Кием-салым өчен мөһим сәйләннәрне үзем тегәм, чигеш өлешләрен дә үзем башкарам. Әмма кайчак һөнәри чигүчеләргә дә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Барысы да – кул хезмәте нәтиҗәсе.

А.Глебова апрель аенда гына ясаган күләмле курчак – Казан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры, ТАССРның халык, Россиянең атказанган артисты, мөхтәрәм Раилә Гарипова образы. Аның фотосы буенча иҗат ителгән. Шул ук вакытта ансамбльнең «Казан кызлары» биючеләре образларын да хәтерләтә. Аны «Созвездие-Йолдызлык» республика яшьләр эстрада сәнгате фестивале җитәкчелегенә бүләк иттеләр.

Оста иҗат иткән интерьер курчаклар арасында иң күләмлеләре һәм гаҗәеп матурлары – Сөембикә-ханбикә һәм аның улы Үтәмешгәрәй сыннары. Беренче тапкыр ул аларны Төркия халыкара күргәзмәсенә алып бару өчен ясаган. «Бу сыннар янына һәрчак халык җыела иде», – дип искә ала әңгәмәдәшем. Өстәвенә, Сөембикә-ханбикә сынындагы бизәнгечләрне дә һөнәри ювелирлар иҗат иткән, башларындагы таҗ-бүрекләрне дә чын тегүчеләр теккән. Яннарына Сөембикә манарасы да ясап куелган. «Сөембикәнең йөзен бер мәктәптә укыган Эльмира Галимова йөзенә карап иҗат иттем. Эльмира Галимова – җырчы һәм композитор, 200 дән артык җыр авторы! Аллаһы Тәгалә аңа тышкы һәм эчке матурлыкны да, талант та насыйп иткән, шуңа күрә дә аның йөзен Сөембикә образы өчен сайлап, башкаларга да күрсәтергә булдым, – дип аңлатты А.Глебова. – Ә Үтәмешгәрәй төпчек улыбызга карап иҗат ителде. Кечкенә чакта улыбыз бик сөйкемле иде». Бу сыннарның икенче варианты да бар, алар «Казан» милли-мәдәни үзәгенә тапшырылган. Димәк, әлеге курчакларның затлы һәм зиннәтле кием-салымнарын да тамашачылар озаклап карый ала.

«Курчакларым Казан кибетләрендә байтак. Үз йөзем, үз брендым бар. Кайчак: «Син бит инде күптән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе булырга тиеш!» – дип тә әйтәләр. Тик мактаулы атларга исем китми. Мин – Аллаһы Тәгаләгә, аның кануннарына ышанып яшим, исем-дәрәҗәләр кешедә тәкәбберлек хисен арттыра», – ди ул.

Асия ханым быел Габдулла Тукай сынын да иҗат итте. Даһи шагыйребезнең «Су анасы» һәм «Шүрәле» әсәрләрен татар, рус, инглиз телләрендә, ике миниатюр китап рәвешендә нәшер итеп, әлеге сын янына өстәде. «Бу сын минем бик күптәнге иҗади хыялым иде!» – ди талант иясе.

Аның гөмбәз астына урнаштырылган бер курчагы хәзер Иске Аракчинодагы Галәм әхрамында. Ул Аллаһы Тәгаләнең туксан тугыз күркәм исемен әйтерлек итеп көйләнгән, һәм Галәм әхрамына килгән туристлар аны озак вакыт сокланып тыңлый. Әлеге курчак матур көйләр белән берләштереп экспозицияләнә. Күргәзмә залында Асия ханымның башка курчаклары да байтак.

Болардан тыш оста башкорт, рус, һинд милли киемле курчакларны да иҗат итә. «Хәзер казак кызы сынын ясарга җыенам. Кубань казакларының хатын-кызлары кулга кылыч тотып бии һәм шул биюләре белән күңелемә илһам өстиләр! Хәзерге чор кешеләре өчен иҗат тагын да мөһимрәктер, чөнки тормышта игелек, уңай караш, мәхәббәт җитми. Аллаһы Тәгалә безне бирегә иҗат итү өчен дә җибәргән. Мин киләчәк буыннарны тәрбияләүдә булышучы сәләтле осталарга юл ачу, балаларыбызны иҗатка этәрү, аларда үз мәдәниятебезгә карата мәхәббәт хисе тәрбияләү яклы», – ди Асия ханым.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Кичә, Уфадагы өенә, Флорида апага шалтыратып, Нажар абыйның өендәме, дачадамы икәнен белешергә булдым. Телефонны Алсу алды. Хәл-әхвәл сорашканнан соң: «Әтием Миңештедә, әнием абыемны Мәскәүдән каршы алырга аэропортка китте, килүегезгә әти бик шатланыр, ул анда ялда», – дип Миңештегә юл өйрәтеп, телефон аша киңәшләрен бирде.

СОҢГЫ КҮРЕШҮ

Ел саен августта ял вакытында без гаиләбез белән җитәкчесе ирем булган фермер хуҗалыгына урып-җыюда ярдәмләшергә Илешкә кайтабыз. Ә бүген шушы уңайдан хөрмәтле Нажар абыйны да күрү теләге безне юлга чакырды.

Табигать тыныч, зәңгәр күктә кошчыклар талпынышы, тулып пешкән гәрәбә ашлыклар арасында зәңгәр күзле күкчәчкәләр сирпелеп кала, каршындагы асфальтта, машина тирбәлүенә ияреп, рәшә артка чигенә, тирә-якта Дүртөйлегә генә хас төзек, тәртипле авыллар күренеп кала. Күңелгә тыныч, рәхәт. Илештә алдарак кайтып киткән ирем, улым көтә. Арткы урында кызым җырлап кайта. Ә иң мөһиме – безне остазым, бөек шагыйрь, гаҗәеп кеше белән очрашу көтә. Дөнья чиксез, яшәү мәгънәле кебек. Дүртөйлегә җиткәч, туктап, Миңештегә юл сорадык. Аны Агыйделнең аръягында диделәр. Мин дә, шофер да бу якта булганыбыз юк. Юлчы алырга булдык, шөкер, күпергә җитәрәк, адым саен кулларына сумка яки төргәк тоткан кешеләр кул күтәрә. Олы яшьтәге бер абыйдан Миңештәгә юл сорадык. Ул үз чиратында: «Венециягә кадәр утыртып алып барсагыз, юлны өйрәтәм», – диде. Безнең сорауны да көтмичә, абый сөйләнә дә башлады: «Беләм инде, безнең якташ Нажар абый янына барасыз», – дип, юл өйрәтә-өйрәтә. Венеция авылының тарихына һәм исеменә тукталды, шагыйрь өчен районның дача салдыруын аңлата-төшендерә, гәп куерта башлады...

Агыйделнең бу ягында мин беренче тапкыр идем. Искиткеч гүзәллек. Янәшәдә агачлар арасыннан ялтырап, Агыйдел күренеп кала. Ике якта мәһабәт карагайлар, каен, юкә агачлары, билгә кадәр үлән, юл буйлап чәчәкләр сибелгән. «Чыннан да, монда туган кешенең һәрберсе шагыйрь булырга тиеш» дип уйладым. Ирексездән үзем үскән, яшәгән Нуриман, гүзәл Сәрвә, Кызыл Чишмә, Павловка табигатенең кыргый матурлыгын янәшә куеп, Нажар абыйның шигырьләрендәге кабатланмас гүзәллекнең кайдан алынганлыгын тойдым.

Барып җитәрәк, уң якта Миңеште күренде. Тау башында машинаны туктатуны үтендем.

... Үлгәч, мине җирләсәгез иде

Миңештенең сез Үрбашына...

«Шушы тау турында язды микән Нажар абый», – дип уйлап куйдым. Әз генә түбәндәрәк яшь карагайлык. Ак чишмә дә якында гына булырга тиеш, күңел дертләп китте... Юк, дөнья матур, яшәү мәңгелек! Бигрәк тә Нажар абый өчен. Олы шәхес, бөек шагыйрь өчен.

Авылга кергәч, колхоз идарәсе янына туктап, Нажар абыйның йортын сораштык һәм, ниһаять, «башка чыккан кешенең өе», ягъни «миңештинский пленник» яшәгән урын. Соңгы хатында ул шаяртып шулайрак язган иде:

«Халисә сеңлем! Яңа йортка, яңа адрес буенча килгән беренче хат синнән! Күңелгә бик тә рәхәт булып китте. Телефон аша да беренче булып синнән хәбәр алган идем.

Хәйдәр Бигичев турындагы истәлекне бүген иртән язып бетердем, дөресрәге, акка күчердем. Ярыйсы гына булып чыкты. Формасы бик кызык тоела, ә исеме – «Әйтелми калган тост».

Мартта Әмирхан Еники абыйның юбилей кичәсе. Фәридә Кудашева белән икебезне чакырды. Авыр булса да, бармый калдыра алмыйм – ул мине бик якын күрә бит. Дүртөйледән туры Казанга «Волга»да китмәкчебез. Истәлекне дә үзем белән алырмындыр – бер үк көнне барып керербездер. Ул истәлек мәсьәләсе ничек итеп Нуриманга барып чыкты соң? Рифат Фәттаховка бәйләме? Кызганычка, мин ул егетне белмим.

Йорт һәм аның урыны, туган җир булгангамы, бик соклангыч кебек, килгәч күрерсең әле.

Ике шигырь яздым. Беренчесе – «Егет сүзе», икенчесе «Берәү» дип атала. Ике депутатлыкка кандидат турында портрет яздым. Басарлармы, хәзер андый гадәт бармы – белмим, әмма берсе бик шәп кеше.

Хәзер үземне «миңештинский пленник» дип атадым. Телевизорга тышкы антенна куелмаган...

Район үзәгендә һәм авылда мөнәсәбәтләр бик яхшы. Йортта 5 февральдә – 81 яшь тулгач яшәтә башладылар. И гомер, әле генә 80 иде бит!

Вакытың булса, язгалап тор. Нигәдер, мин башка чыккан кеше кебек бит әле. Киләчәккә планнар зур.

Сәлам белән Нажар абыең, 24 февраль, 1999 ел».

Мәһабәт, искиткеч зәвыклы итеп салынган йорт. Ихатада җан әсәре сизелми. Сәгать көндезге өчләр тирәсе. Ял итәдер дип уйладым. Үзем әчтән генә шулкадәр юл үтеп, ярты ел буена килеп күрергә вәгъдә биреп тә, берәр җиргә китеп барса, күрми китү дә бик мөмкин дип, курка-курка гына ишек бавын тартам, ишек ачылды, рәхмәт төшкере.

Әй, хөрмәтле Нажар абый, бөек шагыйрь, олы шәхес! Апак чәчләрен артка салып, кухня өстәле тирәсендә җиңел киемдә генә ярып пешергән яңа бәрәңге белән йомырка «сыпыртып» утыра. Башын күтәреп, мине күргәч, өнсез калды. Үзе сөйләнә: «Әй, синме бу, Халисә сеңлем? Кайдан, ничек?» – дип сораша. Үзе шат, күренеп тора.

«Менә бит, мин вәгъдәмдә тордым, сез чакырдыгыз, мин килдем, хәтта үзем генә түгел, юлдашлар да бар», – дидем. Очрашуда гына була торган ыгы-зыгы, кәстрүл, тәлинкә чыңы китте.

Луизаны күреп, гаҗәпләнү кичерде. «Халисә, үзең үзең инде, кызың бигрәк сылу, кемгә охшаган?» – ди. «Әтисенә», – дим.

Без Нажар абый белән кара-каршы утырып, хәл-әхвәл сорашабыз. Луиза кухня тирәсендә булыша. Нажар абый зал өстәленә чиста ашъяулык җәеп куйды. Луиза чынаяклар куя башлаган иде, «Юк, сез минем кадерле кунакларым», – дип, серванттан затлы сервизын ала башлады. Мин үз гомеремдә дә шулкадәр тәмле ризыкны ашаганым булмагандыр, әллә юлдан ачыгып килгәнгәме, әллә җылы, тату мөнәсәбәттәнме?! Уртага бүлеп пешерелгән яшь бәрәңге белән казылык, күчтәнәч балы, баллы бавырсак, тәмле чәй белән рәхәтләнеп сыйландык. Нажар абый ашамады. Ул өстәл аша безне җылы карашы белән күзәтеп утырды. Үзе рус классикларының Луиза исеме кергән әсәрләреннән шигырьләрне яттан укыды, өзекләр китерде.

Мин аның хәтеренә сокланып утырдым «Исемен кем кушты, үзеңме?» – ди. «Әтисе, – дим. – Ул туар алдыннан телевизордан «Башсыз җайдак» дигән фильм бара иде. Шундагы героиня ошады аңа, кызым туса, Луиза була, диде», – димен. «Шәп, – ди Нажар абый, – үзеңә охшаган. Бәхетле генә була күрсен».

Луиза өстәл җыештыра, без сөйләшәбез. «Язасыңмы, Халисә?» – ди. «Соңгы вакытта аз, – дип, – күңел төшенкелеге, нииндидер бушлык, хөкүмәт эше бар энергияне ала, тамак ялына үтә, аһ, кызганыч бу гомер», – дим. «Минем дә андый чакларым булды, үз-үзеңне кочләмә. Үтеп китә ул. Сабыр ит», – ди.

Мин аның хәлләрен сорашам, нинди әсәрләр язганын сорыйм.

«Дүрт шигырь яздым. Туган авылым турында, тыңла», – ди һәм укый:

... Бөтенләйгә кайттым
куеныңа,
Мәңгелеккә синдә калырга...

Шатлыклы обстановка моңсу тынлык белән алышына.

«Ашыкмагыз әле, Нажар абый, сез кешеләргә кирәк. Сез булганда, дөнья матуррак та, баерак та, иртә әле мондый шигырьләргә», – дим. Ул моңсу гына көлемсерәп: «Алай түгел шул, Халисә сеңлем. Миңа ничә яшь икәнен беләсең бит. Әгәр тегеләй-болай була калса, мине шушында җирләячәкләр, Миңеште тау башына. Урынны район, авыл хакимияте башлыкларына да күрсәтеп куйдым, беләләр, монда калырга телим», – диде.

Йөрәк чәнчеп куйды. Замандызның бөек шагыйре, олы шәхесе, талант иясе белән бер чорда яшәвебезнең мәгънәсен аңлап бетердекме икән без?

Нажар абый мине студент елларыннан ук белә, үз кызы кебек яратты, ярдәм итәргә тырышты, иҗатымны бәяләде, авыр чакларымда эш, иҗат, гаилә мәсьәләләрендә дә киңәше белән ярдәм итәргә тырышты, яклады, мин дә, әтисез үскәнгәме икән, аңа тартылдым, үз иттем. Ул минем киңәшчем дә, дустым да, терәгем дә иде.

Иде... Кем уйлаган?

Ә бүген әле ул исән-сау, шат. Өен күрсәтә башлады. Эш бүлмәсенә күтәрелдек. Өстәлдә өр-яңа сигнал данәсе булган «Күңел сәхифәләре» дигән китабы.

«Икенчесен алу белән сиңа

●Сулдан уңга: Дилә Булгакова, Нажар Нәҗми һәм Халисә Мөдәррисова. 1998 елның 28 мартында «Агыйдел» ресторанында юбилейда төшерелгән фоторәсем.

●Миңештәдә Нажар Нәҗминең музей-йорты.

җибәрермен», – ди.

Ике якка тәрәзә аша матур күренеш ачыла. Агыйдел күренә, Роберт Миңнуллин язган «шагыйрь киңлекләре» колач җәя. Нинди хозурлык, яшисе һәм иҗат итәсе генә иде!

Без кәнәфиләргә утырабыз. «Шигырь укы», – ди ул коры гына. Укыйм. «Чукынчык, шәп, яз!» – ди ул. (Шаярып һәм үз итеп, ул «чукынчык» сүзен кулланырга ярата иде.)

Былтыр сентябрь аенда үзе сценариен язып, үзе төшерүне оештырган телевизион фильм героен, озак еллар Нуриман районында Байгилде мәктәбе директоры булып эшләгән Брест крепосте каһарманы, Россия һәм Башкортстанның атказанган укытучысы – үзенең дусты Ришат Сәлих улы Исмәгыйлев турында сораштырып утырды.

Көлешә-көлешә, Байгилдедә бер очрашу вакытында булган кызык хәлне искә төшердек.

1994 елның июнь азагы иде. Искиткеч җылы, матур көн. Очрашуга чакырылган кунаклар арасында иң кадерлесе, билгеле, Нажар абый иде. Тантана авыл клубында кич үтәргә тиеш. Ә хәзер кунакларны табигать кочагына, умарталыкка чакырып, бераз ял иттерергә булдылар.

Җырларда җырланган Караидел буйлары. Язучылар – Сәгыйть Мифтахов, Имай Насыйри, Гайнан Хәйри, Ярулла Вәлиев, Зиннур Насыйбуллиннар яшәгән һәм иҗат иткән яклар...

Нажар абый гүзәл табигатькә сокланып туя алмады. Учак тирәсендә гәп куертабыз. Нажар абый пинжәген салып, якындагы шомырт агачына, хәзерге мәктәп директоры Салават Исмәгыйлев пинжәге янына элеп куйды. Пинжәкләр бер үк төстә иде. Зиннур Насыйбуллинның иҗаты, аның яшьли дөньядан китүе турында борчылып сөйләшелде.

Балык шулпасы, шашлык белән сыйланып, дөнья, яшәеш, шигърият хакында озак кына сөйләшеп утырдык. Бераздан вакытның шактый соң икәнен, клубка кеше җыела башлаганын искә төшереп, кайтырга әзерләндек. Нажар абый, үрелеп, пинжәген алып киде. Кунаклар алдагы машина белән кайтып китте. Салават Ришатович, бераздан кайтып җитәсен әйтеп, торып калды. Без кайтуга, зал тулы иде.

Кунаклар сәхнәгә күтәрелде. Шигырь кичәсе башланды. Сүзне Нажар абыйга бирделәр. Ул микрофон янына килде, язмаларын һәм күзлеген алырга дип кесәсенә тыгылды, тын калды: кесәләр буш иде. Пинҗәге Салаватныкы булып чыкты. Халык көтә, ә ул аңа гына хас шат, яңгыравыклы тавыш белән көлеп җибәрде. Залга ни булганын сөйләп бирде. Ул көлә, халык көлә, без көләбез. Соңыннан: «Юк, мин сезгә буш кесә белән түгел, тулы күңел белән килдем» – дип, бик матур итеп шигырьләрен укыды. Залдан җыр җырлавын үтенделәр, ул ялындырып тормады. «Уфа юкәләре»н җырлап җибәрде. Аңа без кушылдык, безгә зал кушылды.

Икенче вакыйга Нуриман җиренә Нажар абыйның соңгы килүенә бер ел кала, 1998 елның сентябрендә булды. Җылы, ләкин болытлы көн иде.

Нажар абый Ришат Сәлих улы Исмәгыйлев турында фильм төшерергә тиешле төркем белән килде. Кәефе шәптән түгел. «Ашказаным авырта», – ди. Шуңа карамастан, мавыгып-яратып, шагыйрьләрчә эшләде ул фильмны. Авылның тоташ күренеше кирәк иде. Без авыл каршындагы тауга күтәрелдек. Тау башыннан тирә-як уч төбендәге кебек күренә. Күлләр, күлләр... «Әкияттәге кебек», – дип куйды Нажар абый.

Тау башы яшь карагайлык, түбәндә зур күл. Күл аша Ришат Сәлихович йорты. «Минем авыл тавында да шундый ук яшь карагайлар,– диде Нажар абый. – Ак чишмә шунда гына...»

Кич табында ул инде юньләп утыра алмады, ашамады да. Икенче якка чыгып ятты. Мин аның янына чыктым. Озак кына сөйләшеп утырдык.

Ул зарланмады, авырта да димәде. Шигырь укыганда, аның күзләре балкып китә, башын арткарак ташлап, чәчләрен селкеп ала. Ирләрчә горур, рухи көч һәм акыллы мөлаемлык бар иде анда.

Фильмны декабрь аенда күрсәттеләр. Бик фәһемле, хис-тойгылы итеп эшләнгән ул. Үз чоры кешесе, аның кебек үк дәһшәтле сугыш тәмугын үтеп, иҗади укытучылык хезмәте белән шөгыльләнгән замандашы турында. Үзе хакында үзе әйтә алмаган сүзләрне дә герое образы аша әйтә кебек тоелды. Ә без бөек шәхес,олуг шагыйрь турында, үзе исән чакта, юньле бер фильм да төшереп кала алмадык.

Нажар абыйның иҗатын барлап утырам. Күпме кешеләрне белгән ул. Һәр кеше яңа дөнья, яңа ачыш булган. Үзе исән чакта лауреатлар, бөек шәхесләр турында гына түгел, күңел бакчаларын, иҗат кырларын укып, өйрәнеп, яшьләргә дә, башлап язучыларга да, аларның иҗатларына да үз бәһасен биргән. Каләмдәшләре иҗатына игътибарлы булган, укыган, олысыннан алып кечесенә кадәр күрә белгән. Ул шигъриятебезнең киләчәге, үсеше турында уйланган борчылган, җаваплылык тойган. Минем аны соңгы тапкыр күрүемдә аның күңеле тормыш гаме белән тулы иде.

Җыр хакында сүз чыкты һәм ул: «Иртәгә яныма Дүртөйледән әнисе белән яшь композитор кыз Гөлнара Нигъмәтҗанова килә. Минем күңелгә аеручә якын булган «Их, ичмасам, еламасаң икән» дигән шигырьгә көй язган, шуны ишеттерә, түземсезлек белән көтәм», – диде.

Бу йортка чыккач, Әмирхан абый Еники килеп киткән. «Рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык, олыгайган, нинди талант, гомере озын булсын иде. Күңел теләгән кешеләр ешрак килсен иде»,– диде ул.

Иҗади планнары белән уртаклашты. «Автобиографик эссе язып ятам, авыр бара, өлгерергә кирәк. Вакыт кыса»,– диде ул, авыр сулап.

Минем алда инде 80 яшьтән узган кеше утыра. Ләкин карт кеше түгел, олы җанлы, бала күңелле, ап-ачык акыллы, яхшы хәтерле, үткер фикерле, дөнья, яшәү, яшьлек, шигърият турында әңгәмәләшә, ирексездән аның эрудициясенә, укымышлылыгына сокланасың, күңел аның картлыгына ышанмый, чөнки аның белән яшьлек арасында чикләр юк, һәр очрашу, сөйләшү, саф чишмә суы шикелле, күңелне сафландырып җибәрә, тирә-якны яхшырак, матуррак итеп күрсәтә, яңа шигырьләр язарга шаукым бирә. Чын шагыйрь шундый булырга тиештер дә.

Ике атнадан ул пычак астына ятар дип кем уйлаган?

Безгә кузгалырга вакыт иде. Нажар абый безне озата чыкты. Шунда гына нык лы матур йорт тора. «Менә бу йорт минем төп нигез, үзем үз кулларым белән салдым, һәр ниргәсен беләм, анда хәзер нәсел тиешле кеше яши», – диде. Ихата, бакча тирәсен күрсәтте. Бакча тулы яшелчә утыртылган... Помидорлар бик күп, алар әле яшел... Җирләргә килгәндә, алар кызарачак...

«Менә кичә кое казып киттеләр. Тиздән су булачак, менә монысы – мунча урыны, икенче килүдә, кияү белән килегез, мунча кертермен»– ди, үзе көлә.

Капка төбенә җиткәч: «Флорида апаңның чәчкәләрен күрдеңме әле?» – ди. Өй артына алып китте. Анда буйдан-буйга астралар: ак, кызыл, көрән, сары...

Флорида апа. Бу сабыр һәм мөлаем, акыллы шагыйрь хатыны белән бәйле күңелләрдә уелып калган бер күренешне искә алмый булмый. Нажар абыйның 80 яше иде. Кичәдән соң юбилей банкетында миңа каршы биш-алты олы яшьтәге ханымнар утыра. Кайберләрен таныйм: менә Земфира апа, минем университет укытучым, мәрхүм композитор Нариман Сабитовның хатыны, аннан Якуб Колмый абыйның хатыны h.б. Нажар абый, бөтен дусларын җыю белән бергә (ә «Агыйдел» ресторанı кунаклар белән шыгрым тулы иде), үзенең инде мәрхүм булган дусларының тормыш иптәшләрен дә чакырырга күңел киңлеге, юмартлык тапкан.

Ул көнне Флорида апа кунак карап арыган, ләкин аның бәхете тулы иде. Ә «Нефтьчеләр» сараенда Нажар абыйны соңгы юлга озатканда, Флорида апа шагыйрьнең баш очында кайгыдан башын иглән, ә бер читтәрәк шул юбилейда катнашкан тол хатыннар, Флорида апага да үзләре тирәсеннән урын биргән шикелле, шомлы тынлык саклап, сабыр гына басып тора иде. Кем уйлаган?..

Койма янында алмагач үсә. «Сез утырттыгызмы?» – дип сорыйм. «Юк,– ди Нажар абый,– мин әле утыртачакмын, үз нигезем бит!»

Урамга чыгабыз, машина инде кабызылган, берничә минуттан аның белән хушлашачакбыз. «Мине онытмагыз, килеп йөрегез»,– ди Нажар абый. «Килербез,– дим,– үзегезне саклагыз, сез безгә бик кирәк». Ул моңсу гына елмая. Кочаклашып хушлашабыз, машина кузгала.

Нәкъ бала чактагыча: картатаем мине озатып чыга да күздән югалганчы карап кала иде. Нажар абый да ерагая, япа-ялгыз урам уртасында безне, борылышка кереп югалганчы, кул болгап озата.

Ул шактый катлаулы ике гасыр арасын тоташтыручы да, аеручы да. Алтын багана, ак җилкән, якты маяк булып басып кала. Ап-ак чәчләре, чорыбыз шигъриятенең намусы, өмете, ышанычы кебек, җилдә тирбәлә.

Халисә МӨДӘРРИСОВА.
1999 ел.

Хатлар яздым утырып

Безнең авыл хәлләре

Авылларны икегә бүлеп карыйм: урта мәктәбе булганнар һәм булмаганнар. Безнең Урсай беренчесенә керә. Андый авылларны саклап калу җиңелрәк. Чөнки халкы шәһәрләргә качып бетмәгән әле. Эш урыннары да булса, андый авылларны бәхетле киләчәк көтәчәгенә шик юк.

Тик Урсайда урта мәктәп һәм 60 тан артык укучысы булса да, эш урыннары юк. Ел әйләнә эшләп торган терлекчелек фермаларын бетерделәр. Моны махсус рәвештә эшләделәр, өстәге түрәләр алдан планлаштырып оештырды. Колхозлардан калган, безнең ата-бабаларыбыз тырышлыгы белән булдырылган байлыкларны комсыз бәндәләр үзләштерде.

Мисал өчен, сугыш ветераны әтием Миргалим колхозда шофер да, тимерче дә булып эшләде. Минзәләдә махсус курсларда алган белеме белән (соңрак Казан ветеринария институтының айлык курсларында да булды) терлекләрне ясалма орлыкландыру техникы булып эшләп, лаеклы ялга чыкты. 100 сыердан 100 бозау алганы өчен, район җитәкчесе Әнвәр Баһаветдинов имзалаган Мактау кәгазе белән дә бүләкләнде, күп еллар колхоз идарәсе әгъзасы булды. Ә колхоз таралганда, андый алдынгы колхозчыларга бер тиен дә өлеш чыкмады.

Колхоздан калган байлыкны әле булса да талап бетерә алмый «интегәләр». Колхозга бер катнашы булмаган бәндәләр һаман авылда актарына, нидер таба. Авыл советы һәм аның депутатлары да берни белми, авыл белән җинаятьчел төркемнәр идарә итә дип саныйм. 18 август көнне бер фоторәсем төшереп алдым. Андагы экскаватор җәй буе авылның төрле җирләрен чокып, металл ватыклары җыя. Авыл советы бюджетына акча эшлидер дип уйлый күрмәгез, ул акчалар караклар кесәсенә кереп югала. Мин үзем дә 2020 елга кадәр авыл советы депутаты булдым. Авыл советының акчасы булса, урамнарга асфальт түшәләр иде. Урта мәктәбе булып та, урамнары асфальт күрмәгән бердәнбер авыл түгел микән без? Авылыбыз Ык елгасы буенда, җәяүлеләр чыгарлык булса да күпер төзелсә, начармы шул?...

Авылыбыздан Мөслим районына бара торган иске юл буенда «ТАССР-Азнакай районы, Мөслим районы, БАССР-Бакалы районы» дип язылган һәйкәл кебек мәһабәт багана бар иде. Күптән түгел шуны да юк иткәннәр. Түрәләргә суд та юк, чурт та юк!

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ,
хезмәт ветераны.
Азнакай районы.

Хыяллар

Биш еллар элек таныш журналист «Мәскәүдә яшәүче бер танылган абзый белән очрашу була, «Милләт йорты» на кил әле», дип чакыргач, әлләни исем китмичә генә барганым хәтеремдә. Кунак ул вакытта «Мәскәү татарлары штабы» җитәкчесе Рөстәм Фәиз улы Ямалиев булып чыкты. Ишетеп белсәм дә күргәнем, ул җитәкләгән оешма турында язганыбыз юк иде. Р.Ямалиев беренче карашка ук тыныч, һәр гамәлен уйлап башкара торган, чәчрәп чыгуны бик өнәми торган кеше булып тоелды. Танылган галимнәребез, әдипләребез, дин әһелләре катнашында үткән бу утырышта катнашучылар Мәскәүнең татар штабы, аның җитәкчесе, ул алып барган эшчәнлек белән тирәнрәк танышты.

Кешенең холкына да, аның үз-үзен тотышына да гаиләдә нигез салына диюләре – күптән расланган хакыйкать. Рөстәмнең әтисе Фәиз, әнисе Гөлҗәүһәр дә танышлары хәтерендә гаилә җанлы, «эш» дип янып яши торган уңган, булдыклы, игелекле кешеләр буларак кереп калган. Фәиз аганы уен-көлке белән сөйләшергә яратучан, баянда халкыбыз көйләрен яңгыратучы, биюче, кунакчыл кеше итеп тә хәтерлиләр, хәтта «Мунча ташы»ның беренче тамашасының нигездә, Ф.Ямалиев мәзәкләренә корылуын әйтәләр. Әтиләре балаларына шахмат буенча Татарстан чемпионы булуы, Әгерҗе һәм Минзәлә районнары авыл Сабан туйларында татарча көрәштә батыр калуы кебек гамәлләре, эше, яшәеше белән дә үрнәк була, кызы Ленизә, улы Рөстәмне теләсә нинди хәлдә дә кешелекле булып калырга, авырлыклар алдында югалып калмаска өйрәтә. Фәиз аганы, үзе дә көрәшче буларак, Түбән Кама Сабан туйларында бу төр ярышны оештыруга, аңа гадел судьялык итүгә күп көч куючы буларак та хәтерлиләр. Рөстәм Фәиз улының сабырлыгы, тынычлыгы, һәр карарны ныклап уйлап кабул итүе – әнисеннән. Нәсел тамырлары исә Әгерҗе һәм Менделеев районнары чигендәге Уразай авылына, урман һәм тегермән хуҗалары Хәбибҗамал һәм Нурмөхәммәт Җамалиевларга барып тоташа. Аларга татар халкының беренче казые Мөхлисә Бубиның килеп йөрүе дә мәгълүм.

Рөстәм әфәндең балачагы Минзәләдә Биккол авылында үткән. Әтисе Фәиз Нурмөхәммәт улы җитәкләгән «Гигант» күмәк хуҗалыгы тирә-якта уңышлары белән дан тота. ТАССР партия өлкә комитеты секретаре булган Фикрәт Табеев авыл хуҗалыгында яхшы күрсәткечләргә ирешкән колхоз-совхозларга игътибарын кызганмый. Республика җитәкчесе шуңа да, Минзәлә яклары юлы төшкән саен, Фәиз Ямалиев җитәкләгән хуҗалыкка кереп чыга. Бергәләп кармакка балык тоткан, чәй өстәле янында утырган чакларында да сөйләшүләре исә һаман да эш, хуҗалыкны алга җибәрү, республика киләчәге турында. Балык каптырганда, аларга кечкенә Рөстәм исә зур булышчы, ул кармакларга суалчан киертә.

Еллар уза. Орлык үстерү буенча махсуслашкан совхоз җитәкчесе Фәизнең, Кама буенда ак кала төзелә башлагач, күңеле кузгалып китә, гаиләсе белән шунда күченә. Бирегә аны халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты директоры итәләр. Ике ел да үтми, Ф.Ямалиев җитәкчелегендәге комбинат республикабызда беренче урынны алып, күчмә Кызыл байракка ия була.

Казан химия-технология, аннары Ярославль икътисад институтларын, ВЛКСМ югары мәктәбен тәмамлаган Рөстәм дә 1993 елда Мәскәүне яуларга килә. Бу елларда комсомол оешмасы таркала, яшь белгеч предприятиедә эшли башлый һәм ике елдан соң туган ягы Түбән Камага кайтып китә. Әмма «Түбән Кама нефтехим»да җитәкчелек алмашына, гаилә корырга да өлгергән Р.Ямалиев кабат Мәскәүгә юл тота. Бу юлы аның исәбе – башкалада ныклап төпләнү. Ул төзелеш бизнесын башлап җибәрә. Билгеле ки, башкалада ныклап урнашканчы, берничә ел гаиләсеннән аерым яшәргә дә туры килә.

Ф.Табеев 1990 елларда «Китайгородская стена» комплексында ул елларда Советлар Союзының сәүдә министры урынбасары булган Анатолий Козлов янында Татарстаннан Мәскәүгә килгән кешеләрдән торган берләшмәне оештырып җибәрә. Алар арасында сәясәтчеләр дә, табибләр дә, эшмәкәрләр, икътисадчылар, финансистлар һ.б. була. 1995 елда ширкәтне «Клуб деловых людей – ДЛ-16» («Эшлекле кешеләр клубы») исеме белән рәсмиләштерәләр, химаячеләре исә – Козлов, Кузьмин, Табеев. Р.Ямалиев та шушы клубка йөри башлый. Аңа анда яшьләр белән эшләүне йөклиләр. Клуб җитәкчеләре Мәскәүдә Татарстан идеологиясен үткәрү һәм оешмага яңа кешеләрне тарту ниятеннән төрле чаралар уздыра башлый. Хәтта Татарстаннан килүчеләрне берләштергән «Эшлекле кешеләр клубы» урнашкан «Китайгородская стена» комплексы республиканың бер кечерәк биләмәсе кебек була.

Татарстан белән 20 ел җитәкчелек иткән, зур заводлар төзетеп, аның бик күп икътисади мөмкинлекләрен формалаштырган Ф.Табеев Татарстанда үз эшенә бирелгән, фидакяр, югары вөҗданлы белгечләр эшләвен искәртә торган була, аларның Россия башкаласында да үз потенциалларын кулланыр урын табуларын тели. Республиканың элекке җитәкчесе клубта яшьләр катнашында үткәрелгән кичәләрдә аларның чыгышлары белән Татарстаннан иконлекләрен, араларында депутатлар, җитәкчеләр булырга, аларның һәрвакытта да лидерлыкка омтылырга тиешлекләрен, хәтта таләпчән формада кабат-кабат белдерә тора, аларны һәрвакыт бердәм булырга чакыра. Ул яшьләргә «Сезнең һәркайсыгыз Мәскәүдә иң әһәмиятле, мөһим татар», дип юл күрсәтә. Бу очрашулардан егет-кызлар рухланып, яңа уй-хыяллар белән китә торган була. Клуб, дөрестән дә, зур эшчәнлек алып бара, бик күпләр аның ярдәмен дә күрә. Ә галим Азат Зыятдинов белән якыннан аралашып яшәгән, уртак милли идеяләр белән янган Р.Ямалиевны Мәскәүдә егет-кызларның туган халкы мәдәниятенә, теленә битарафлыгы борчый. Шуңа да ул милләтебезне күтәрү, яшьләрнең үз туган телләрендә аралашуы кебек мәсьәләләрне алга куя. Шулай итеп «Эшлекле кешеләр клубы» каршында яшьләрне берләштергән «Татар штабы» барлыкка килә.

Ф.Табеев вафатына 4-5 ел кала Мәскәүдә якташлар очрашуларын тулысынча Р.Ямалиевка тапшыра. Иш-ишен таба. «Штаб» та тора-бара киңәя, милләтен яраткан, үз телендә аралашасы килгән татарларның күбесе «Мәскәү

тормышка аша

татарлары штабы» тирәсенә көннән-көн күбрәк тартыла һәм туплана бара. Моннан тыш алар биредә үз кызыксынулары һәм һөнәрләре буенча да берләшә башлый. «Штаб» каршында хәрбиләр, эчке эшләр органнарында хезмәт куючылар – «Офицерлар», Мәскәүнең медицина уку йортлары студентлары һәм табибләр – «Гиппократ», яшь эшмәкәрләр – «Масштаб», «Каһарманнар», журналистлар, әдипләр – «Милли каләм», «Иҗади зыялылар» клубларына, өлкәнрәкләр – Мәскәү аксакаллары советына, тарихчылар, әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләре берләшмәләренә оешып, үзара аралашып, киңәш-табыш итеп эшлиләр. «Татарча мафия» интеллектуаль уены, «Аулак өй», «Татар яшьләре штабы», «Яшьләр якшәмбесе» кебек проектлар үзенә яңадан-яңа милләттәшләребезне тартып китерә, берләштерә.

Штаб шулай ук яшьләр теләге белән КВН командасын, Татарстанның «Ак Барс» һәм «Нефтехимик» хоккейчылары Мәскәү стадионнарында көч сынашканда, җанатар булып утырган фан-клубларны да оештыра. Оешма тырышлыгы белән «Штаб»та инде шактый еллар дәвамында өч айга бер тапкыр «Беренче намаз» акциясе уздырылып килә. Хәзрәтләрдән динебез турында вәгазь тыңлату, аннары бергәләп намазлыкка басу үз нәтиҗәләрен бирә, милләттәшләребез арасында ислам дине кушканнарны алга куеп яшәүчеләр ишәя бара. Биредә яшьләр очраша, таныша, үзләренә яр таба, никахлаша. Әлбәттә, барысы өчен дә матди чыгымнар таләп ителә. Төп әһәмият исә әлеге дә баягы милли мәдәниятне һәм телебезне саклау һәм татар кадрларын әзерләү юнәлешләренә бирелә, клублар үз эшләрен шушы максатка җайлап алып барырга тырыша. Әлбәттә, мәгариф учреждениеләрендә татар теле кысрыклап чыгарылган заманда, бурыч – аеруча катлаулы.

Шунысы – әйбәт, «Штаб»ка йөрүче кызлар-егетләр үзара татарча аралаша, гаилә кора икән, бу инде оешма эшчәнлегенең күпмедер дәрәҗәдә нәтиҗәсе булуы турында да сөйли. «Эшне иң элек үзеңнән башларга кирәклеген искәртеп торабыз. Һәркемнең күңелендә, бүгеннән башлап балаларым белән татарча гына аралашачакмын, дигән фикер беркетүе әһәмиятле. Менә шул чагында тел өйрәнү мәсьәләсендә күпмедер алга китеш булачак. Гомумән, татар гаиләсе институтына зур игътибар бирергә кирәк. Монда әби-бабаларыбызның ярдәменнән башка гына булмый», – ди Рөстәм әфәнде.

Бүген инде Мәскәүдә Р.Ямалиев җитәкчелегендә дүрт иҗтимагый оешма эшләп килә. Татар һәм төрки халыкларның милли конгрессы, Мәскәү өлкәсе татарларының милли үсеш үзәге, «Эшлекле кешеләр клубы (ДЛ-16)» һәм Мәскәү татарлары штабы. Аларның барысын да татар телендә аралашу аша милли мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны, милләтебезне саклау һәм үстерү кебек уртак максат берләштерә. Милли конгресс исә бүгенге көндә Мәскәүдә Татарстан сәясәтен популярлаштыруда, милли мәсьәләләрне күтәрүдә форпост булып тора. Оешма шул вакытта күләмле социаль проектларны, программаларны тормышка ашыруда Бөтендөнья татар конгрессының ышанычлы партнеры да.

Гомумән, оешмаларның һәркайсы һәрвакыт шаулап-гөрләп тора, биредә төрледән-төрле очрашулар, кичәләрдән тыш, яшьләр катнашында чаралар, флешмоблар, фестивальләр, концертлар уза. Оешманың эшчәнлеге Рамазан аенда тагын да активлаша. Быел Рамазан аендагы догалы-сәгадәтле ифтарлар, Мәскәүдәге «штаб»та һәм мәчетләрдән кала, Татарстанда, хәтта Сочида да узган. Ифтарлар татар морзалары, аксакаллар, милли хәрәкәт ветераннары, галимнәр, яшьләр өчен аерым-аерым оештырылган. Изге аебыз дәвамында исә мәчетләргә, китапханәләргә, мәктәпләргә, балалар йортларына һәм мохтаҗларга хәйрия ярдәме күрсәтелгән.

Узган ел милләттәшләребез өчен зур сынау – җанисәп кампаниясе узды. Р.Ямалиев җитәкчелегендәге оешмалар да милләтебезне бу чарага әзерләүдә дә саллы өлешен кертте. Әйтик, Рөстәм әфәнде финанславында 10000 тираж белән нәшер ителгән «Үз җиремдә – үз телем» – һәр татарның горурлыгын уятырлык, озак еллар дәвамында өстәл китабы булырлык китап. Аны Россиянең 20 шәһәрендә тәкъдим иттеләр.

Бүген өч бала атасы булган Р.Ямалиевның үз акчасына ел саен ветераннарга, мәктәпләргә, мәдәният учреждениеләренә илнең төрле төбәкләрендә нәшер ителә торган татар матбугатын 16000 данәдә яздыруын да әйтергә кирәктер. Ә инде меценатның 5000 данәдә тарала торган газетасы, өстәл календаре теләсә кемнең күңеленә хуш килерлек. Алар барысы да үткәрелә торган кичәләрдә, утырышларда бушлай таратыла. Рөстәм Ямалиев җитәкчелегендә эшчәнлек алып барган оешмалар тарафыннан илдә, республикада барган зур вакыйгалар уңаеннан төшерелгән роликлар (алар шактый күп) интернет киңлекләрендә аеруча популяр. Әлбәттә, хыяллар, ниятләр – зурдан. Әйтик, татар театр студиясе булдыру, меценатлар һәм, әлбәттә, дәүләт ярдәме белән татар студентлары өчен тулай торак төзү, Мәскәү янында татар мәктәбе, балалар бакчасы булган бистә торгызу – шундыйлардан. Штаб шулай ук милләттәшләребезнең бердәм архивын туплауны, федераль татар яшьләре оешмасын, татарлар өчен туган телдә эшләүче бердәм социаль челтәрен булдыруны һәм үз телебездә тапшырулар алып бара торган федераль радиоканал ачуны да күңелендә йөртә. Аның бәхете исә – үйлаганнарының тормышка аша баруында.

Сөембикә КАШАПОВА.

РЕДАКЦИЯДӘН. Бу көннәрдә Рөстәм Фәиз улы үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аны гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, алга таба да игелекле хезмәтендә, гаиләсендә уңышлар телибез.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

3 сентябрь (шимбә). Сәфәр аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 13.51 сәгатьтә калка, 20.41 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.42 сәгать.

Бүген ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булсын. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Баллы укроп суы

Кан тамырларын чистарту өчен, чирек стакан укроп орлыгы, ярты стакан балны термоска салып, өстенә ярты литр кайнап торган су агызалар, тәүлек буе төнәтәләр һәм көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1әр аш кашыгы эчәләр.

4 сентябрь (якшәмбе). Сәфәр аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 15.19 сәгатьтә калка, 21.16 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.37 сәгать.

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Аспиринлы йод

Буыннар сызлаганда, болай дәвалану булыша. Кечкенә шешәдәге 10 миллилитр йодка 5 таблетка аспирин кушып болгаталар. Аспирин эрегәч, йод төссезләнә. Шуны сызлаган буыннарга сөртеп, төнгелеккә аякка - йон оекбаш, кулга – бияләй киеп йокларга яталар.

5 сентябрь (дүшәмбе). Сәфәр аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 16.34 сәгатьтә калка, 22.12 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.32 сәгать.

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Эчәклекне чистарту

Яртышар стакан дөге һәм солы ярмасын юып, 2,5 стакан суда куерганчы пешерәләр дә, берничә көн буе иртән һәм кичен майсыз ашыйлар. Тоз өстәргә ярый. Мондый ботка эчәклектәге бөтен кирәкмәгән нәрсәләрне чыгара, эчәк тышчасындагы җәрәхәтләрне дә төзәтә.

6 сентябрь (сишәмбе). Сәфәр аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 17.26 сәгатьтә калка, 23.32 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.28 сәгать.

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргы мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

7 сентябрь (чәршәмбе). Сәфәр аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,17.58 сәгатьтә калка, 1.07 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.23 сәгать.

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Гөлҗимеш кесәле

Панкреатит булганда, гөлҗимеш кесәле эчү файдалы. 4 стакан су, 50-80 г кипкән гөлҗимеш, 1-1,5 стакан шикәр, 4-6 аш кашыгы бәрәңге крахмалы, 1-2 г лимон кислотасы кирәк. Юылган гөлҗимеш җимешләре өстенә 3 стакан кайнар су салып, 1 сәгать тоталар, аннары йомшарганчы пешерәләр. Сөзеп, башка савытка салалар. Җимешләрне изеп, шуңа кушалар, шикәр, лимон кислотасы өстәп, кайнатып чыгаралар да, 1 стакан салкын суда эретелгән крахмал кушып, кайнатып чыгаргач, уттан алып, стаканнарга бүлеп суыталар.

8 сентябрь (пәнҗешәмбе). Сәфәр аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,18.19 сәгатьтә калка, 2.46 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.19 сәгать.

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Кабак сихәте

Дөньяда кабакның сигез йөздән артык төре бар, шулардан ике йөз төре генә ашарга яраклы. 1 литр май алу өчен 35 кабак кирәк. Әлеге сихәтле май кандагы холестерин микъдарын киметә һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан саклый. Ул A, E, K, B, C, D витаминнарына, селен, натрий, калий, магний, тимер, кальцийга, бета-каротинга бай, фосфор һәм кремний кислоталары да шактый. Кабак 90 процентка судан тора, 100 граммында нибары 25 калория бар. Тутыяга (цинкка) бай булганга, кабак төше бигрәк тә ир-атларга файдалы.

9 сентябрь (җомга). Сәфәр аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,18.32 сәгатьтә калка, 4.22 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 13.14 сәгать.

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Тәмле күмәч

1 стакан җылы сөткә 2 аш кашыгы шикәр, 1-1,5 аш кашыгы коры чүпрә, 6 аш кашыгы он салып, кабарырга куялар. Кабарып менгәч, 50 г эретелгән атланмай, 3 әр аш кашыгы иссез үсемлек мае һәм шикәр, 2 йомырка, 1 чәй кашыгы тоз, 3 стакан чамасы он салып, камыр басалар, җылы урынга куялар. Камыр күтәрелгәч, бертигез түгәрәкләр әвәлиләр, майланган табага ара калдырып тезәләр. 20 минут кабарткач, туглаган йомырка сарысы сөртеп, өстенә умач (1 аш кашыгы шикәр, 2 аш кашыгы он, 1 аш кашыгы атланмай) уып сибәләр дә, газ мичендә пешерәләр.

Ничек ярдәм итәргә?

Килер көннәргә күпме генә зур өметләр баглап яшәсәк тә, иртәме-соңмы, барыбер, бу дөньядан китәчәкбез. Беребез дә монда калмаячагын барыбыз да бик яхшы аңлый. Тик шулай да якыннарыбыз вафат булса, бу зур югалтуны авыр кичерәбез. Һәм аның өчен кайгыра башлыйбыз.

КЕШЕ КАДЕРЕ

Кешене югалткач кына, аның кадерен, үзебез өчен никадәр якын, кирәкле булганын аңлыйбыз. Ә исән вакытында хәлен белергә дә, барып күрергә дә, сөйләшеп утырырга да вакытыбыз юк. Чөнки дөнья мәшәкате баштан ашкан. Үз тормышыбызны җайларга – йортлы булырга, ипотека түләргә, кредитны капларга кирәк. Ә якын кешенең үлеме турында ишеткәч, бу тормыш мәшәкате, вак-төяк бернәрсәдәй, күпмегәдер оныттылып тора. Инде якыныңның (әбиең, бабаң, ата-анаң, туганың) бу тормыш белән мәңгегә исәп-хисабын өзгәнен дә, аны тиешенчә соңгы юлга озатудан тыш, башкача берничек тә ярдәм итә алмаганыңны да аңлыйсың.

Ә шулай да, һәрбер яхшы күңелле кешегә хас булганча, аның өчен әле нидер эшләргә, ничек булса да файда китереп калырга дигән теләк туа. Эшебез күп булса да, вакыт та табарга риза. Әгәр дә ул кеше исән вакытта мондый игътибар булса, күпкә яхшырак булыр иде дә... Нишләмәк кирәк, адәм баласының табигате, холкы шундый инде. Дөрес, бакыйлыкка күчкән туганыңны онытмыйча, аңа һәрвакыт савабы барып торсын дип, игелек кылсаң, бик яхшы. Тик төрле кеше бар. «Үлде. Аның өчен инде барысы да бетте», – дип, бу дөньядан киткән якыннары өчен бернинди гамәл кылмаганнар, кылырга уйламаганнар да очрап куя.

Ә савабы үлгән якыннарыбызга ирешеп файда бирсен өчен динебездә нинди хәерле гамәлләр кылып була? Коръән аятьләрендә һәм Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә нинди гамәлләр турында сөйләнелә соң?

ДОГА КЫЛЫЙК

Иң беренчесе һәм иң файдалысы – бу дөньядан киткәннәребез өчен күп итеп дога кылу. Алар әйтерләр: «И, Раббыбыз, безне ярлыка, бездән әүвәл иман белән дөньядан үткән дин кардәшләребезне дә гафу ит һәм иман китергән кешеләргә безнең күңелләребездә ачуны һәм хөсетлекне калдырма, и, Раббыбыз, Син мәрхәмәтле һәм рәхимлесең!» («Хәшер» сүрәсе, 10 нчы аять). Бу аятьтән күренгәнчә, исән булучылар үзләре арасыннан киткән кардәшләре өчен дога кылып, Раббыларына ялварырлар, гафу итүләрен сорар. Пәйгамбәребез дә кардәшләребез, якыннарыбыз өчен дога кылырга өндәгән һәм җеназа намазын ошбу дога белән укырга кушкан: «И, Аллаһы! Аны ярлыка һәм аңа рәхимле бул, аны коткар һәм гафу ит, аны яхшы кабул ит һәм аның кергән (каберен) киң кыл. Ак киемне пычрактан пакьләгән кебек, Син аны гөнаһ-хаталардан пакьлә, аңа үзенекеннән яхшырак йорт бир, аңа үзенекеннән яхшырак гаилә бир, аңа үзенекеннән яхшырак хатын бир, аны җәннәткә керт һәм кабер газабыннан сакла (яки ут газабыннан сакла)» (Мөслим риваяте).

Аллаһы Тәгалә Коръәндә балаларга үзләренең дөньялыктан киткән ата-аналары рухына дога кылырга куша: «Һәм аларга шәфкать итеп, игелеклек күрсәт. Һәм әйт: «И, Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергән кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл» («Исра» сүрәсе, 24 нче аять)

СӘДАКА БИРИК

Хәзер үзебезгә сорау бирик әле, безнең балалар бу доганы беләме? Без үзебездән соң догачы балалар калдырабызмы? Яки дөнья малына табынучы, күзләре байлык белән томаланган варислар калдырабызмы? Кызганыч, күп кенә эти-әниләр баласының иманы һәм дини тәрбиясе өчен бер дә кайгырмый. Ә бар тәрбия акча ягын, йорт-җирен кайгыртуга гына кайтып кала. Әйе, фани дөньяда мөлкәтнең файдасы күп тияр, әмма каберга барып кергәч, безгә дога, савап, игелекләр кирәк була башлаячак, ә балаларыбыз мондый төшенчәләрне ишетеп, белеп үсәме соң?

Вафат якыннарыбызга ярдәм китерә ала торган гамәлләрнең икенчесе – алар өчен сәдака бирү. «И, Раббым, шушы биргән сәдакамның савабын вафат булган туганымның рухына ирештерсәң иде», – дип күңелдән ниятләп бирсәк, файдасы булыр.

Моңа Бохари җыентыгында килгән хәдис дәлил булып тора: «Сәгъд ибне Губәдә исемле сәхабәнең энисе үлгәч, ул Пәйгамбәребез янына килеп сорый: «И, Рәсүлуллаһ, минем әнием вафат булды, ә мин аның янында була алмадым, аның өчен сәдака бирсәм, файда бирерме? Пәйгамбәребез аңарга: «Әйе», – дип җавап кайтарган». Шушы хәдискә таянып, галимнәр вафат булган кеше исеменнән сәдака бирсәң, ул аңа файда китерә, дигән фикер әйтәләр. Чөнки хәдистә Пәйгамбәребез шушы гамәлгә рөхсәтен биргән. Шуңа да якыннарыбызның хәлен алар исеменнән сәдакалар биреп җиңеләйтә алабыз.

УРАЗА ТОТЫЙК

Өченче гамәл – ураза тоту. Әгәр рамазан аенда уразасын тотып бетерә алмыйча, көннәре казага калган булса яки ураза тотарга дип нәзер әйтеп калдырган булса, вафат якыныбыз өчен ураза тотып, өстендәге бурычын төшереп, аның хәлен җиңеләйтә алабыз. Пәйгамбәребез: «Үлгән кешенең тотасы уразасы калган булса, аның урынына, якыннарыннан (вәлие, җаваплы кешесе) кем дә булса ураза тотсын», – дигән (Бохари риваяте).

Икенче хәдистә болай диелә: «Бервакыт бер кеше Пәйгамбәребез янына килеп, сорый: «И, Аллаһының Илчесе, әнием ай буена ураза тотарга тиеш иде, әмма ул үлеп китте, аның урынына миңа ураза тотарга кирәкме?» Пәйгамбәребез ул кешедән сорый: «Әгәр әниеңнең берәр кешегә әҗәте калган булса, син аны түләр идеңме?». «Әйе», – дип җавап кайтара бу кеше. Пәйгамбәребез исә: «Аллаһы каршында булган бурыч барысыннан да мөһимрәк», – дип әйтә (Бохари риваяте).

Хәдисләрне аңлар өчен, тагын бер мисал китерик. Әгәр кеше рамазан ае җитү белән ураза тота башласа, ә аннары сәфәргә чыгып китеп, ураза тотмаган көннәре калса, кайткач ураза тотуын дәвам итә. Ә рамазан ае беткәч, калган көннәрен каза кылырга ашыкмый, «ярар, тотармын әле, икенче аена кадәр вакыт бар», дип яши бирә. Әлеге кеше кинәт кенә үлеп китә һәм аның фарыз уразасы – сәфәрдә булган вакытта тотмый калган көннәре кала. Вафат булган кешенең якын туганы аның исеменнән ураза тоту бурычын түләсә, хәерле була.

БУЛДЫРА АЛСАК...

Дүртенче гамәл – хаҗ яки гомрә кылу. Әгәр дә берәр туганыбыз кинәт кенә вафат булып, ул хаҗ гыйбадәтен үтәмәгән булса, без аның өчен хаҗ сәфәренә чыга алабыз. Әмма монда бер шарт бар, хаҗ кылучы кеше иң әүвәл үзе өчен хаҗ кылган булса гына бүтән кеше өчен хаҗга бара ала. Пәйгамбәребез янына бер кеше килеп сорый: «Әнием хаҗ кылырга дип нәзер әйткән иде, һәм хаҗ кыла алмыйча үлеп китте, миңа аның өчен хаҗ кылырга ярыймы?» Пәйгамбәребез болай дип җавап бирә: «Әйе, аның өчен хаҗ гамәлен үтә! Әгәр әниеңнең берәр кешегә әҗәте калган булса, син аны түләр идең бит, ә Аллаһ каршында булган бурыч үтәлү – барысыннан да өстенрәк» (Бохари риваяте). Мөмкинлек бар икән, бу олуг гыйбадәтне вафат булган туганыбыз яки якын кешебез өчен үтәргә омтылыйк, бу гамәл аңа файда китерер.

ҮКЕНЕРЛЕК БУЛМАСЫН

Безнең арадан киткәннәребез өчен менә шундый игелекләр кылып, аларга файда китерә алабыз. Көчебездән килгәннәрне эшләргә тырышыйк, иң кимендә, догаларда онытмыйк, алар безнең догаларыбызга бик тә мохтаҗ. Ә исәннәребезгә бу тормышта игелекле, хәерле гамәлләр кылырга, намазларны саклап, үз вакытында укырга дип, Раббыбыздан тәүфыйк сорыйк. Заяга үткән игелексез тормыш өчен үлгәннән соң үкенерлек булмасын, бу тормышны гына уйлап яшимик, киләсе, мәңгелек барачак урыныбызны да кайгыртыйк.

«Берәрсенә үлем килсә, ул: «И, Раббым, мине дөньяга кире кайтар, шаять, мин кылмый калган изге гамәлләрне кылырмын», – дияр. Юк! Бу – аның авызыннан чыккан буш сүз генә. Кыямәткә чаклы аларны терелтмичә тота торган бәрзах (комачау) бар» («Мөэминнәр» сүрәсе, 99-100 нче аятьләр).

Раил ФӘЙЗРАХМАН,
Балык Бистәсе районының
Тәберде Чаллысы мәчете мөгаллиме.

Борынгылар әйткән сүзләр

(Мәкальләр һәм әйтемнәр)

Хуҗи МӘХМҮТОВ

СУДАН КОРЫ ЧЫГУ

Тапкырлык, өлгерлек, хәйлә ярдәмендә катлаулы, хәвефле хәлләрдән дә оста итеп, зыян-зәүрәт күрми генә чыга алуны яки, гаепле була торып та, җәзасыз котылып калуны белдерә торган әйтелмә.

«...Бу җиңел сөякле егетнең үзен бик иркен тотуы, күпне белүе, эшкә өлгерлеге, кычкырып көлүе, шулар өстенә, тагын, кирәк чакта судан коры чыга белүче алдар таз булуы аны кызыктыра...» (Фатих Хөсни. Җәяүле кеше сукмагы).

«[Миңнулла:] Әһә, син әле судан коры чыкмакчы буласың икән. Юк инде, Гафият дус! Чыкмый тор! Алпутның ике сыерын кем алып кайтты? Син алып кайттың...» (Ибраһим Гази. Онытылмас еллар).

Сурәтле тәгъбирләр, кагыйдә буларак, башта туры мәгънәдә туып, соңыннан гына күчерелмә мәгънә хасил итәләр. Бу җәһәттән караганда, суга кереп тә, аннан коры чыгуны реаль төстә күз алдына китерү кыен, әлбәттә. Хәлбуки, әкиятләрдә, риваять-легендаларда әнә шундый очраклар турында да бәян кылына. Ихтимал, «Судан коры чыгу» әйтелмәсенең дә туу тарихы шуларның берәрсенә барып тоташадыр, һәрхәлдә, Заһир Бигиевнең 1890 елда язылган «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар») романында моңа ачык ишарә бар:

«Мәмәт, Габделгафур вә Ибраһим, смотрительнең бүлмәсендән сабырлыклә, гаҗәләсез (ашыкмыйча)чыгып, «Исраил балаларының судан кору чыклыклары кеби», хәбесханәдән кору чыгып хәлас булдылар (котылдылар)» (Романнар, сәяхәтнамә. -Казан, 1991).

Бу мисалдагы «Исраил балалары судан коры чыккан кебек» дигән чагыштыру Муса пәйгамбәр могҗизалары белән бәйләнгән. Инде язылганча, Тур тавында Алладан пәйгамбәрлек һәм шуңа дәлил буларак кулындагы таягына могҗизаи кодрәт алганнан соң, Муса галәйһиссәлам Мисырда яшәүче яһүдиләр (яки Исраил балалары) арасында хак динне тарата башлый. Әммә Мисыр патшасы Фиргавен һәм аның кабиләсе мәҗүсиләр була, алар, Аллаһны танымыйча, потларга табына. Ислам динен кабул иткән өчен Фиргавен Мусаны һәм аның кавемен төрлечә җәберли. Коръәндәге «Духан» («Төтен») сүрәсенең 20-24 нче аятьләрендә әйтелгәнчә, кяферләр Мусаны таш белән бәреп үтерергә җыеналар. Муса, дога кылып, Раббысына зарлана. Аллаһ әйтә: «Төнлә минем бәндәләрем, Ягъкуб балаларын алып, Мисырдан качып китегез, алар исә сезнең артыгыздан куа чыгарлар. Үзегез чыккан диңгездәге юлларны ачык көенә калдыр, чөнки сезнең артыгыздан Фиргавен кавеме кереп батып һәлак булачактыр» (Коръән тәфсире. – Казан, 1992).

Кызыл диңгез култыгына килеп җиткәндә, артларында күп санлы Фиргавен гаскәре дә пәйда була. Муса галәйһиссәлам могҗизалы таягы белән диңгез өстенә суга. Аның сулары шунда ук

ике якка аерылып, уртада коры үтем барлыкка килә. Пәйгамбәр тарафдарлары икенче ярга чыгып беткәндә, әлеге үтемгә Фиргавен гаскәре дә килеп керә. Ләкин диңгез инде яңадан элекке хәленә кайта. Кяферләргә судан коры чыгарга насыйп булмый. Алар диңгез төбендә калып һәлак булалар (Кыйсасел-энбия. – Б. 222).

ТАЛАНТНЫ ҖИРГӘ КҮМҮ

Инҗилдә Гайсә Мәсих (Иисус Христос) сөйләгән гыйбрәтле хикәяләрнең берсендә болай бәян кылына:

Бер кеше чит илләргә киткәндә, хезмәтчеләрен чакырып алып, берсенә биш талант, икенчесенә ике талант һәм өченчесенә бер талант күләмендә акча калдырган. Ул киткәч, биш талант алганы шунда ук үзендәге акчаны әйләнешкә җибәргән һәм шуннан 5 талант табыш алган. Икенчесе, шул ук юл белән, үз акчасын 4 талантка җиткергән. Ә өченче кол чокыр казыган да, үз талантын җиргә күмеп куйган.

Хуҗа кайтып хисап сорагач, беренче кол аңа 5 урынына 10, икенчесе 2 урынына 4 талант китереп биргән. Өченче кол исә җир астына яшереп куйган әлеге бер талантын алып килгән. Хуҗасы аны нык шелтәләгән: «Сиңа талантыңны җиргә күмәргә түгел, ә үстерергә кирәк иде», –дигән. (Маттай, 25: 14-30)

Грек телендәге «талант» (talantion) сүзе борыңгы заманда иң зур авырлык һәм акча берәмлекләре булып йөргән. Аннан ул кешедә теге яки бу өлкәдә була торган гадәттән тыш табигый сәләтне дә белдерә башлаган. Шуның белән бәйләнештә «Талантны җиргә күмү» гыйбарәсе «Алла (табигать) тарафыннан бирелгән сәләтләрне үстермәү, файдага ашырмау» дигән күчерелмә мәгънә хасил иткән. Шушы мәгънәсе белән ул башка халыкларның телләренә дә күчкән. Менә татар матбугатыннан кайбер мисаллар:

«Халык мәкале раслаганча, «талантның бер өлеше тумыштан, тугыз өлеше тырышлыктан» килә. Тагын: «Талантыңа җилкән тек, җил булмаса ишкәк ал!» – дип тә әйтәләр. Тормыш активлыклары җитешмәүдән, «җилкән тегәргә, ишкәк ишәргә» иренүдән табигый сәләтләрен ача алмаучылар да аз түгел. Андыйлар турында «талантын җиргә күмде" дигән гыйбарә дә бар» (Хуҗи Мәхмүтов. Игелекле талант иясе /І Татар иле. - 2002).

«Талантның беренче дошманы – ялкаулык... Район гәзите редакциясендә эшләгәндә минем янга бер егет шигырь күтәреп килде. Менә дигән әсәр, мин аны күтәреп алдым, үзебездә генә түгел, республика гәзитенә җибәреп бастырдым. Инде егетем канатланыр, әсәрләрен яудыра башлар дигән идем. Ә ул икенче шигырен... бер ел үткәч алып килде. Йә, әйтегезче, елына бер шигырь язып, шагыйрь булып буламыни? Шуннан соң ул бөтенләй дә күренмәде.... ата ялкаулыгы белән үзенең талантын күмеп куйды» (Радик Фәезов. Чабата үрергә дә талант кирәк //Мәдәни җомга. – 2006).

ТАУ МӨХӘММӘТКӘ КИЛМӘСӘ, МӨХӘММӘТ ТАУГА КИЛӘ

Дөньяның күп кенә телләрендә билгеле булган бу гыйбарә Мөхәммәт исеме белән генә кулланылмый. Аның килеп чыгышы турында кызыклы гына фаразлар бар. Шулардан кайберләрен үзенең «Канатлы сүзләр» китабында (Казан, 2000) тел галиме һәм педагог Илгизәр Гыйззәтуллин да китереп үткән. Чама белән 1630 елда төзелгән гарәпчә бер мәҗмугада Хуҗа Насретдин турында мондый мәзәк бар икән. Имеш, ул үзен изге кеше дип игълан иткәч, җыелган халык аннан: «Ә син моны ничек исбатлый аласың?» – дип сораган. Хуҗа әйткән: «Ә-әнә теге хөрмә агачын күрәсезме? Хәзер мин аны үз яныма чакырып китерәм», – дигән. Әмма бу могҗиза барып чыкмаган: хөрмә агачы урыныннан кузгалмаган. Ләкин Хуҗа югалып калмаган:

– Без, изгеләр, тәкәббер халык түгел, – дигән ул. – Хөрмә агачы минем янга килмәсә, мин үзем аның янына барам. – Һәм, шул сүзләрне әйтеп, әлеге агачка таба юнәлгән.

Төрекләрнең мондый бер мәкале дә хәзер күзәтелә торган әйтелмәнең ихтимал элгәрләреннән берсе итеп санала. Игътибар итегез: аның текстында «тау» компоненты бар, ягъни ул бу яктан бүгенге вариантка якынрак тора: «Тау, тау, ил гиз син, әгәр ил гизмисең икән, изге үзе ил гизсен...» Ә инде «тау» һәм «Мөхәммәт» сүзләре бергә кулланыла башлауга килсәк, аны инглиз философы Френсис Бэконның «Әхлакый һәм сәяси очерклар»ында (1597) очратабыз. Күрәсең, ул немец, француз телләренә шуннан күчкәндер. Соңга таба Европадан русларга, ә алардан безгә калькалаштырып алынган булса кирәк. Башлыча сөйләмә телебездә кулланыла. Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыелмасында да теркәлгән.

Гыйбарәдә берничә төрле мәгънә төсмере табарга мөмкин. Мәсәлән, Хуҗа Насретдин әйткәнчә, тәкәббер булмау, кечелеклелек күрсәтү. Яки, зарурият кушканда, компромисска бара белү, буйсынырга мәҗбүр булу һ. б.

«Кызның йөзенә, күзенә хәсрәтле төс чыкты, гүя элекке вакытларын хәтерләде: «Ни эшләмәк кирәк? Таулар Мөхәммәткә килмәсәләр, Мөхәммәт үзе аларга барырга тиеш, диләр бугай... Ярый, иртәгә килермен.» (Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 3).

Бу гыйбарә белән бәйле кайбер риваятьләрдә эш киресенчә тора: тау үзен чакырган зат янына «килә»! Бу, мәсәлән, христиан версияләрендә күзәтелә. Италиянең атаклы сәяхәтчесе Марко Поло (1254-1324) юл язмаларында бәян кылынганча, ниндидер бер итекче Багдад хәлифен христиан диненең өстенлегенә ышандырырга тырыша. Хәлиф могҗиза таләп иткәч, ул якындагы тауны үз янына чакыра һәм тау аңа таба «килә башлый!..»

Татар әдәби телендә дә гыйбарәнең тау Мөхәммәт янына килә торган вариантлары очрый. Табигый, мондый әсәрләргә сатирик-юмористик эчтәлек салына. Ләкин, «һәр Мөхәммәт – пәйгамбәр түгел» дигәндәй, монда Рәсүлебезгә (с.г.в.) ироник мөнәсәбәт юк.

Әхмәт Исхакның «Мөхәммәт һәм тау» мәсәлендә тәзү чималлары белән тулган зур гына тау: «Промкомбинат директоры Мөхәммәт килер дә, миндәге байлыклардан файдалануны оештырыр», – дип көтә. Аннан...

«Көтә-көтә тәмам сабыры беткәч,
Аның янына
Карар бирде бер көнне үзе барырга:
«Каршысына тау хәтле тау баргач,
Һичшиксез, игътибар итми калмас...»
Ләкин Мөхәммәтнең секретаре
Җибәрмәде аны бусагадан ары –
Бүген аның үзенә кирәкле
төзү чималларын
Үзәктән җибәрттерүен сорап, елап-елап
Ялвара торган көне Аллага». -

(Әхмәт Исхак. Җырда очрашу).

Соңгы сәяхәт

Ял итәргә кем дә ярата. Тик менә кайберәүләр бөтенләй тугарыла һәм куркынычсызлык кагыйдәләрен санга сукмый башлый. Ел саен йөзләгән турист сәяхәткә чыккан җиреннән кире әйләнеп кайтмый. Мәсәлән, Канададан килеп, Крюгер милли паркында йөргән 23 яшьлек кызны бассейндагы крокодиллар янына барырга ярамый дип кат-кат кисәтәләр. Кыз исә хезмәткәрләрдән көлә генә, тимсахларның чын булуына ышанмый. Үзенең хаклыгын исбатлар өчен, кисәк кенә бассейнга сикерә... Һәм ерткычның нәкъ авызына барып керә. Мескенкәйне берничек тә коткарып кала алмыйлар. Иң бичара турист исә – немец Гейнц Мольке. Ул Көньяк Америка буйлап сәяхәт итә. Амазонка ярыннан барганда, Гейнцка бер күч умарта корты ябырыла. Алардан котылмакчы булып елгага сикергән туристны мизгел эчендә пираньялар ашап бетерә.

(“Лента.ру”).

Азат бул!

Без күбесенчә “Исәнмесез!”, “Хәлләр ничек?” дип исәнләшәбез. Кытайда күрешкәндә: “Син бүген иртән дөге ашадыңмы?” – дип сорыйлар. Японнар исә: “Көн туды”, – дип сәлам бирә. Африкадагы Ботсвана гел корылыктан интегә, шунлыктан анда: “Яңгыр яусын!” – дип сәламләшәләр. Зулуслар исә бер-берсенә: “Мин сине күрәм”, – ди. Немец “Барып буламы?”, француз “Ничек бара?”, италияле “Ничек басып торасың?” дип күрешә. Малайзиядә: “Кая барасың?” – дип сәламләүгә һичшиксез: “Йөреп киләм әле”, – диярге кирәк. Памирда һәр очраган кешегә: “Ару-талуны белмә!” – диләр. Төньяк Америка һиндиләре: “Син – икенче мин ул”, – дип шаккатыра. Гренландиядә: “Нинди матур көн!”, Иранда: “Шаян бул”, – дип сәламләшәләр. Грузиннар: “Гамарджоба!” (“Хаклы бул!” яки “Җиңәргә язсын!”), вайнахлар: “Азат бул!”, Африкадагы басуто кабиләсе: “Сәлам сиңа, ерткыч!”, маорилар: “Бу иртә (көн) өчен рәхмәт!”, Таиландта исә: “Ваааү!” дип күрешәләр.

(“Bloomberg”).

Кошлар йоклыймы?

Күп кошлар бик озак араларга очарга сәләтле. Алар бу күчешләре вакытында йоклыймы соң? Макс Планк институтыннан Нилс Раттенборг тикшеренүе нәтиҗәләреннән күренгәнчә, очканда кошлар йә баш миләренең бер ярымшарын уяу хәлдә калдырып, йә баш миенең ике ярымшарын да вакытлыча эштән туктатып йоклый ала. Күчмә кошлар үзләренең навигация сәләтен “тиз йокы” халәтендә - организм мускуллар тонусын вакытлыча югалткан чакта да саклап кала икән. Акрын йокы вакытында кошлар бер күзен ачып йоклый ала, бу чакта алар әйләнә-тирәлектә ниләр булуын да, куркыныч ерткыч якынлашуын да күрә. Кошларда тиз йокы фазасы имезүчеләрнекеннән шактый кыска, һәр эпизоды еш кына 10 секундтан да кимрәк була. Очканда йоклау сәләтенә ия булсалар да, тикшеренүдә катнашкан фрегатларның тәүлегенә нибары 42 минут кына йоклавы ачыкланган. Ә җирдә чакта кошлар гадәттә тәүлегенә 12 шәр сәгать йокларга ярата. Кошлар табигатендәге мондый кискен каршылык галимнәр өчен һаман табышмак булып кала бирә.

(“Nature Communications”).

Йогышлы чир дә җиңелә икән

1967 елда табибләр, ел саен 2 миллион кешенең гомерен өзә торган кара чәчәк чиреннән ничек тә бөтенләйгә котылырга, дигән максат куя. Моңа 10 ел вакыт китә: соңгы тапкыр чәчәк белән чирләүче 1978 елда теркәлә, 1979 елда авыруның юкка чыгуы рәсми рәвештә таныла. Бүгенгә бу кешеләр бөтенләйгә котылган бердәнбер чир санала. Тагын бер мәкерле чир – ВИЧ инде 35 миллион кешенең гомерен өзгән, 36,7 миллион кеше шул диагноз белән яши һәм нибары бер кеше бу авырудан тулысынча сихәтләнгән. Ул – Тимоти Браун. Аңа генетик мутацияле донордан арка мие күчереп утырту булышкан – әлеге үзгәргән геннар Тимотиның иммун күзәнәкләрен инфекцияләргә бирешми торганга әйләндергән. Дәва курсы бик катлаулы булып, пациентның иммун системасын тулысынча юкка чыгара язса да, бүген Браун сау-сәламәт.

(“МедНовости.ру”).

Ике ел язылачак

Россия мөфтиләренең хәер-фатихасы белән Коръәннең кульязма мүсхәфен язуга керешү тантанасы быел гыйнварда Казанның Кол Шәриф мәчетендә үткәрелгән иде. Әлеге эшне башкарып чыгу өчен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин 12 белгечтән торган экспертлар комиссиясен туплаган. Кульязма мүсхәфләр әзерләү тәҗрибәсе бүгенге көндә Согыд Гарәбстаны, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бәһрәйн, Күвәйт, Катар, Ливия, Марокко һәм Пакыстанда бар. Теге яки бу сүзне төгәл һәм хатасыз язар өчен, Казан белгечләренә беренчел чыганакларга, фәнни тикшеренүләргә мөрәҗәгать итәргә, һәр хәрефне һәм авазны кат-кат тикшерергә туры киләчәк. Шул ук вакытта, мүсхәфтә сүз-хәрефләрне дөрес һәм сәнгати итеп язудан тыш, аларны ачык һәм аңлаешлы итеп язу турында да онытмаска кирәк. Чөнки гарәп булмаган укучы гарәп язуын аңламаска мөмкин. Мүсхәфне төзегәндә кануни яктан хаталар китмәсен өчен, нәзарәт белгечләре Муса Бигиевнең «Тасхих рәсми хат» һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең «Фәваид әл-Мүһиммә» хезмәтләренә дә таяна. Әлеге эшкә консультант сыйфатында дөньякүләм танылган мөселман галиме, дин әһеле, Дубайның Коръән әзерләү комиссиясе башлыгы шәех Мәэмүн әр-Рави җәлеп ителгән. Казан каллиграфы Артур Писаренко башта бер битне кулдан яза да, аннары программада электрон нөсхәгә күчереп, белгечләр комиссиясенә тапшыра, аннан соң аларның төзәтмәләрен кертә – шул рәвешле бер биткә ике көн вакыт китә. Мәсәлән, Коръәннең соңгы җүзе (утыздан бер өлеше) иң беренче булып күчерелгән, моңа каллиграфның 70 көн вакыты киткән. Хаттат әйтүенчә, соңгы җүзне язуы иң авыры санала, чөнки ул иң күп һәм иң кыска сүрә вә аятьләрне үз эченә ала (36 сүрәдән, 564 аятьтән тора). Шунысы да мөһим: хафизлар Коръәнне ятлауны соңгы җүздән башлый. Сүрәләрнең күп булуы юл һәм биттә хәрефләр белән сүзләрне композицион урнаштыруны катлауландыра. Гарәп каллиграфиясе сәнгать кенә түгел, фән ул, чөнки аның эчендә бөтен нәрсә системалаштырылган, төрле математик формулалар файдаланыла, шул формалар буенча хәрефләр төзелә.

(“Realnoevremya.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

5 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». 6+
17.00 «Татарлар». 12+
17.30, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
19.00 Хоккей. ЦСКА - «Ак Барс». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Каравай». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Рәдиф Гаташ турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+
10.30, 21.00 «СЕДЬМАЯ РУНА». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ». 16+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Джинглики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Вторая леди».
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 Цвет времени. Эдгар Дега.
8.35 Легенды мирового кино.
9.05, 16.45 «СОФИЯ».
10.15, 20.45 «Александр Ширвиндт. Ушедшая натура».
11.10 «Найти друг друга».
12.15, 21.40 «СЁГУН».
13.55 Линия жизни. Дмитрий Харатьян.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Екатеринбург. Особняк Тупиковых».
15.50 Острова. Изабелла Юрьева.
16.30 «Забытое ремесло».
17.40 Мастера мирового исполнительского искусства. Дэниел Хардинг и Оркестр де Пари.
18.25 Цвет времени. Рене Магритт.
18.40 «Ключ к разгадке древних сокровищ».
19.45 Главная роль.
20.00 «Семинар». Павел Сурков. «Тайна Фредди Меркьюри».
23.35 Юбилей Ирины Никитиной. «Энигма. София Губайдулина».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+

Сишәмбе

6 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00 «Заман көзгесе». 6+
23.50 «Видеоспорт». 12+
0.15 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Галимҗан Ибраһимов турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+
10.30, 21.00 «СЕДЬМАЯ РУНА». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ». 16+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Джинглики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Хождение Кутузова за море».
7.35, 18.40 «Ключ к разгадке древних сокровищ».
8.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
8.35 Легенды мирового кино.
9.05, 16.45 «СОФИЯ».
10.15, 20.45 «Александр Ширвиндт. Ушедшая натура».
11.10 «Белый медведь».
12.15 «Лесной дворец Асташово».
12.40, 21.40 «СЁГУН».
14.15 «Игра в бисер» «Поэзия Юрия Ряшенцева».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Грядущее свершается сейчас».
16.30 «Забытое ремесло».
17.40 Мастера мирового исполнительского искусства. Максим Венгеров, Лонг Ю и Шанхайский симфонический оркестр.
19.45 Главная роль.
20.00 «Почерк эпохи». «Всеволод Багрицкий. Осколки...»
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
23.35 «Энигма. София Губайдулина».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+

Чәршәмбе

7 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00, 0.40 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00 Документальный фильм. 12+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20 «Йөрәктән-йөрәккә». Равил Шәрәфиев турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.15, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+
22.10 «УЕННАН УЙМАК». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+
10.30, 21.00 «СЕДЬМАЯ РУНА». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВОЗМЕЗДИЕ». 16+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.20 «Джинглики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Хождение Кутузова за море».
7.35, 18.40 «Ключ к разгадке древних сокровищ».
8.20 Цвет времени. Карандаш.
8.35 Легенды мирового кино.
9.05, 16.45 «СОФИЯ».
10.15, 20.45 «Александр Ширвиндт. Ушедшая натура».
11.10 ХХ век. «Репортаж из прошлого. По воспоминаниям Владимира Гиляровского» «Минувшее проходит предо мною...»
12.10 «Глеб Плаксин. Сопротивление русского француза».
12.40, 21.40 «СЁГУН».
14.15 Искусственный отбор.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Кирилл Молчанов».
16.30 Цвет времени. Николай Ге.
17.40 Мастера мирового исполнительского искусства. Риккардо Шайи и Люцернский фестивальный оркестр.
19.45 Главная роль.
20.00 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
23.35 «Энигма. Риккардо Мути».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+

Пәнҗешәмбе

8 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 0.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Адмирал». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 Церемония открытия Казанского международного фестиваля мусульманского кино.

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Гөлзада Сафиуллина турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 XYIII Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең ачылу тантанасы. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.10 «УЕННАН УЙМАК». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+
10.30, 21.00 «СЕДЬМАЯ РУНА». 16+
11.30 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВОЗМЕЗДИЕ». 16+
14.35 «Ученые люди». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «Пока станица спит». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Хождение Кутузова за море».
7.35 «Ключ к разгадке древних сокровищ».
8.20 Цвет времени. Клод Моне.
8.35 Легенды мирового кино.
9.05, 16.25 «СОФИЯ».
10.15, 20.45 «Александр Ширвиндт. Ушедшая натура».
11.10 XX век. «Репортаж из прошлого. По воспоминаниям Владимира Гиляровского» «Друзья и встречи».
12.10 «Лев Оборин. Первый из Страны Советов».
12.40, 21.40 «СЁГУН».
14.15 Абсолютный слух.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Сарафан для самарчанки».
15.45 «Александр Иванов-Крамской. Битва за гитару».
17.20 Большие и маленькие.
19.45 «Хлеб, «Север» и кобальт».
23.35 «Энигма. Риккардо Мути».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+

Җомга

9 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «ПЕЛИКАН». 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Вера Минкина турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Җәүдәт Фәйзи турында телеочерк. 6+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «УЕННАН УЙМАК». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+
10.30, 21.00 «СЕДЬМАЯ РУНА». 16+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПРЕДЕЛ РИСКА». 16+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «Пока станица спит». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голосящий КиВиН-2022». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.40 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.25, 10.00, 15.00, 19.30, 23.15 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Хождение Кутузова за море».
7.35, 18.40 «Ключ к разгадке древних сокровищ».
8.35 Легенды мирового кино.
9.05, 16.25 «СОФИЯ».
10.15, 20.45 «Александр Ширвиндт. Ушедшая натура».
11.15 Цвет времени. Михаил Врубель.
11.25 «Запечатленное время».
12.00, 21.40 «СЁГУН».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Человек-оркестр».
17.20 Мастера мирового исполнительского искусства. Эммануэль Паю, Даниэль Баренбойм и Оркестр Западно-Восточный Диван.
19.45 Главная роль.
20.00 Искатели. «Пропавшая экспедиция».
23.35 «ХОЛОДНЫМ ДНЕМ В ПАРКЕ».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ». 16+
21.40 «РИКОШЕТ». 16+
23.40 «Своя правда». 16+

Шимбә

10 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Спектакль «Минем исемем Кызыл». 12+
16.30 «Гомер - татлы мизгел». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ГАМБИТ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Айрат Арсланов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Ничек сезнең хәләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Шулдыр ул яратү» Габделфәт Сафин концерты. 6+
21.45 Спектакль «Әбиләргә ни җитми?» 12+

«ЭФИР»

5.00 «Самые важные открытия человечества». 12+
5.30 «Ученые люди». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
8.25 «Вокруг света во время декрета». 12+
8.50 «КОГОТЬ ИЗ МАВРИТАНИИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БОРГ/МАКИНРОЙ». 16+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЭТО ЧЕРТОВО СЕРДЦЕ». 16+
22.50 «КОГДА ЗОВЕТ СЕРДЦЕ 5». 16+
0.20 «НОЧНЫЕ СТРАЖ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.30 «ПРИХОДИТЕ ЗАВТРА».
15.25 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ». 12+
16.55 «Архитектор времени». 12+
18.00 Вечерние новости.
18.20 «Сегодня вечером». 16+
19.50, 21.35 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
23.00 «ПРО ЛЮБОВЬ». 18+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «Доктор Мясников». 12+
12.55 «И ШАРИК ВЕРНЁТСЯ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «НЕ ТВОЁ ДЕЛО». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.40 «ЗДРАВСТВУЙ, МОСКВА!»
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00 Неизвестные маршруты России. «Северная Осетия. От Владикавказа до Цейского ущелья».
10.40 «ДОЛГАЯ СЧАСТЛИВАЯ ЖИЗНЬ».
11.55 Земля людей. «Крымские эстонцы. Дом весны».
12.25 Черные дыры. Белые пятна.
13.05 «Великие мифы. Одиссея».
13.35 «Большой Барьерный риф - живое сокровище».
14.25 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.20 Лаборатория будущего. «Психрофилы».
15.35 «ЗЕЛЕНЫЙ ОГОНЕК».
16.45 Светлана Захарова, Ильдар Абдразаков, Дмитрий Маслеев, Игорь Петренко, Юрий Башмет на VIII Международном фестивале искусств П.И. Чайковского в Клину.
18.55 «Александр Ширвиндт. Ушедшая натура».
19.50 «ТРОЕ В ЛОДКЕ, НЕ СЧИТАЯ СОБАКИ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб, Шаболовка, 37.

«НТВ»

5.00 «Спето в СССР. Я шагаю по Москве». 12+
5.45 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 «Шоу Аватар». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

11 сентябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 16+
6.00 «Бер язмыш - ике моң». «Фәридә - Алсу» дуэтының юбилей кичәсе. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильм. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20, 0.45 «Әйләнә деньяя». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 Спектакль «Шулай булды шул». 12+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ДЖУНГЛИ ЗОВУТ. В ПОИСКАХ МАРСУПИЛАМИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Каеннарым белән». 12+
8.40 «Кояшларың белән кил син миңа». 6+
9.15 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.15 «Туган авылым». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.35 «Челтер чишмә буенда». Асаф Вәлиевнең юбилей концерты. 6+
16.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Әлфия Авзалова турында телеочерк. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Йөрәк маем». 12+
23.25 «Шаян хәлләр». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Самые важные открытия человечества». 12+
5.30 «Ученые люди». 12+
6.30 «Без химии». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЭТО ЧЕРТОВО СЕРДЦЕ». 16+
14.50 «Путеводитель по вселенной». 12+
15.20 «Все как у зверей». 12+
15.50 «КОГОТЬ ИЗ МАВРИТАНИИ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «БОРГ/МАКИНРОЙ». 16+
23.00 «РОБЕРТ - КОРОЛЬ ШОТЛАНДИИ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.25, 6.10 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «1812. Бородино». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
13.35 К 85-летию со дня рождения Иосифа Кобзона. «Песня моя - судьба моя». 12+
14.40 «СУДЬБА РЕЗИДЕНТА». 12+
17.40 «Свои». 16+
19.05 «Голос 60+». 12+
21.00 «Время».
22.35 «ТОБОЛ». 16+

«РОССИЯ»

5.35 «НЕЛЁГКОЕ СЧАСТЬЕ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 «Большие перемены».
12.55 «И ШАРИК ВЕРНЁТСЯ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 Мультфильмы.
7.10 «ТРОЕ В ЛОДКЕ, НЕ СЧИТАЯ СОБАКИ».
9.20 «Обыкновенный концерт».
9.50 Диалоги о животных.
10.35 Большие и маленькие.
12.40 Невский ковчег. Теория невозможного. Иван Ратиев.
13.10 «Игра в бисер» «Вениамин Каверин. «Барон Брамбеус».
13.50 «Элементы» с Александром Боровским».
14.20 «ПОДКИДЫШ».
15.30 «Александр Ширяев. Запоздавшая премьера».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 Передача знаний.
18.35 «Романтика романса». «Лучший город земли». 10 песен о Москве.
19.30 Новости культуры.
20.10 85 лет со дня рождения Иосифа Кобзона. «Песни разных лет». Иосиф Кобзон, Валерий Халилов и Симфонический оркестр Министерства обороны Российской Федерации.
21.15 «ДОЛГАЯ СЧАСТЛИВАЯ ЖИЗНЬ».
22.30 Опера «Сказка о царе Салтане».

«НТВ»

5.10 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
10.55 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Ты супер!» 6+
22.40 «Звезды сошлись». 16+

Балаларга һәм яшүсмерләргә карата кылынган җинаятьләрнең кайберләре ике якның да ризалыгы-ирегә буенча эшләнә. Әйтик, аларны хәмер белән сыйлаучылар, балигъ булмаганнарны эчкечелеккә тарту хакындагы 151 нче маддә буенча җавапка тартылырга мөмкин. 16 яше тулмаганнар белән гыйшык уеннары исә хәзерге заманда шактый киң таралган җинаять санала.

Ирекле һәм хурлыклы мутлыклар

Быел 20 мартта Чаллыдагы перинаталь үзәккә 16 яшьлек Адилә Газизова (кайбер исемнәр үзгәртелә) китерелә. Моңа кадәр көмәнле буларак исәптә тормаган яшүсмер шул көнне үк сау-сәламәт кыз бала тудыра һәм дүрт көннән өенә озатыла. Әлбәттә, шәһәр полициясе игътибарыннан читтә калмый бу хәл. Бала тудыру йортында чакта ук, Адилә сабыйның атасы 31 яшьлек Александр Погромский дип белдерә. Алар белән беренче әңгәмәдән соң тикшерүне Тукай районы полициясенә тапшырырга туры килә. Чөнки җенси якынлыкларның шәһәр янындагы Мәләкәс авылында булуы ачыклана.

Ошбу хәлләргә этәргән сәбәпләрне ачыклау ниятеннән әлеге ике кешенең тормыш агышларына кыскача тукталып үтик. Адилә тулы булмаган гаиләдә, тәгәлрәге күбрәк Чаллыдагы әбисе янында үсә, шәһәр мәктәбендә укый, бик үк тәртиплеләрдән булмаган 1972 елгы әнисе соңгы елларда Илгиз атлы ир-ат белән Мәләкәстә яши, башлыча, читкә китеп эшләүче ир кешенең өендә тора, җирле теплицада эшли. Хәер, күргән-белгәннәр әчәргә хирыс хатын-кызның анда да рәтләп эшләмәвен әйтәләр. Ул гына да түгел, әнисе янына еш килүче, җәйге айларда тоташтан диярлек авылда торучы кыз бала өчен борчылуларын белдергән чит хатын-кызлар да бар. Чөнки әлеге хуҗалыкта килмешәк сәрхушләр күп. Иртә белән теплицаның көнкүреш йортыннан чыгуын күргәч, димәк, аның шунда кунып йөрүен аңлагач, кызыйны тиргәп-кисәтеп куйган хатыннар да күп була. Ошбу бинада ирләр яши бит. Әнисе дә Адиләнең 8 нче сыйныфын тәмамлаганнан соң тыңлаусызлануын, дәресләрен калдыра башлавын әйтә, берничә көн өйгә кайтмыйча йөрүеннән зарлана.

Гаиләсендә җылы мөнәсәбәт күрмәгән кыз А.Погромскийга елыша башлый. Әйтергә кирәк, теплицада эшләүчеләр аның турында бары тик уңай фикердә. Үзе Донецк өлкәсеннән ул. Татарстанда күптәннән яшәсә дә, гел Украина гражданы санала. 2016 елда ук Ирина атлы кыз белән танышкан, тиздән кызлары туган, ләкин 2020 елда аерылышканнар. Сәбәбен матди кыенлыклар белән аңлаталар. Хатын баласы белән эти-әнисе янына күченгән, Александр алдан Тукай районындагы бүдәнә фермасында, аннан соң Мәләкәстәге тегермәндә эшләгән, шундагы көнкүреш бүлмәсендә торган, ләкин кызын матди ярдәменнән ташламаган.

Әйтүләренә караганда, гашыйкларның хисләре беренче мәртәбә 2020 елның 20 августында йөгәннән ычкына. Шуннан соң берничә тапкыр яратышкач, кызның Чаллыга укырга китүе сәбәпле, очрашмый торалар. Ә Яңа ел бәйрәменнән соң яшь туташ, укуын калдырып, Мәләкәскә килгәләп йөри башлый. Очрашулар узган елның августына чаклы дәвам итә. Кызның өчдүрт көн рәттән ир-ат янында кунып йөргән вакытлары да була. Ләкин тикшерү комитетының Минзәлә районара бүлегеннән Илдар Романов кузгаткан җинаять эшендә 2021 елның 10 июненә, ягъни гүзәл затка 16 яшь тулган көнгә кадәр булган якынлыклар гына санап үтелә. Чөнки 17 нче яшенә аяк баскан кызлар белән булган мондый хилафлыклар өчен законда җинаять җәзасы бирү каралмаган. Погромский да кызга 15 кенә яшь икәнен белмәдем дип бара. Кыз, август аенда балага узуымны аңладым, бу хакта Погромскийга хәбәр итмәдем, ди. Шуннан соң аларның аралары суына. Гыйнвар аенда Александр гаиләсенә кайта, түләүле фатирда яшиләр, кызы бакчага йөри башлый. 2 мартта полиция хезмәткәрләреннән Адиләнең бала табуын ишетә, аның үзенеке булуына шикләнүен белдерсә дә, ярдәм итәчәген әйтә. Яшь ана исә башка партнерым булмады дип, кызының атасы Погромский икәненә шикләнмәвен белдерә. 13 яшендә сыйныфташ малае белән беренче якынлык кылуын да яшерми ул. Мондый «күңел ачулар» хәмерсез генә булмый, гадәттә. Тикшерү барышында ир кешенең яшүсмер кызны сыра белән сыйлавы да мәгълүм була. Шул рәвешле, Погромский яшь кешене эчкечелеккә тартуда да гаепләнә.

* * *

Азнакай районының Актүбә бистәсендә яшәүче хатын-кыз полициягә үз опекасындагы 13 яшьлек оныгының шактый өлкән егет белән йөрүен әйтеп шикләнүләрен белдерә, тикшерергә куша. Әбинең борчылулары раслана, әмма ул әйткән егет түгел, ә 19 яшьлек икенче бер студентның гөнаһлы икәне ачыклана. Кызый әбисе алдында әңгәмә корганда, полиция хезмәткәрләренә 2002 елгы Р. Сабиров белән якынлык кылуларын сөйләп бирә. Әлбәттә, Алисәне табиб-гинекологка караталар, ул кызның гыйффәтлекне күптән югалтуы турында белдерә.1956 елгы әби мут егетне җавапка тартуны сорап гариза язгач, аның өстендә болытлар куера. Тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Раил Газетдинов 13 яшьлек кыз бала белән ирекле рәвештә булган биш очрак буенча җинаять эше кузгата.

Шул яклардагы Карповка авылында булган соңгысына аерым тукталып үтик, чөнки ул кичтә иртә җитлеккән туташның Сабиров кына түгел, тагын бер егет кочагына керүе дә ачыклана әле. Әлмәттә укып йөргән ошбу егет тә бәлале була, чөнки аңа карата да 134 нче маддә буенча эш ачыла. Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, 2021 елның май аенда бер төркем яшьләр Карповкадагы шәхси йортта Р. Сабировның туган көнен бәйрәм итәләр. Кичкә таба гашыйклар, ягъни хуҗа белән яшь кыз яратышып алу җаен таба. Соңрак алар Актүбәдәге паркта йөриләр. Монда инде яшь туташ 2002 елгы И. Сәхибуллин белән югалып тора.

Шунысы хак, мондый гыйшыклы уеннар турында сүз чыкмый калмый. Гадәттә, яшьләр үзара сөйләшәләр, серләрен уртаклашалар. Бу очракта егетләр икесе дә кызга 13 яшь кенә икәнен белмәдем, аның белән җенси мөнәсәбәткә кергәнем булмады дип гаепләрен кире кага. Ә тикшерү барышында бу хакта ишеттем, белдем дип торган таныш-белешләр һәм барысын да тәфсилләп сөйләп биргән зарар күрүче күрсәтмәләренә өстенлек бирелә, билгеле.

Бар яктан да уңай бәяләнүче егетләрнең эше чын мәгънәсендә хөрти була. Чөнки зарар күрүче кызга 14 тулып өлгермәгән булса, аның ише ирекле кылынган гамәлләр өчен законда 3 тән 10 елга чаклы иректән мәхрүм итү каралган, хәтта гаепләнүчеләргә шартлы хөкем бирү дә тыела. Азнакай шәһәр суды җинаять эше кузгатылгач ук, аларның икесен дә сак астына алырга карар кыла. Шул рәвешле, студентлар дүрт-биш ай буе Бөгелмәдәге тикшерү изоляторында утыра. Шулай да хөкемдар аларга җиңелрәк җәза бирү җаен таба, берсенә 720 сәгатьлек мәҗбүри эшләр, икенчесенә 8 айга ирегең чикләү дигән җәза билгеләп суд залында азат итә.

Күптән түгел шул ук Азнакай районында яшәүче ике егеткә бер үк яшь кыз белән уйнашлык кылган өчен «хөкем ителгән» дигән мөһер сугылды. Туташларның бусына 15 булганга, алар 300 сәгатьлек мәҗбүри эшләр алып котылды. Аларның гаепләрен танып тәүбә итүләре дә исәпкә алынды,билгеле.

Без капчыкны март аенда тишеп чыга, ягъни 9 нчы сыйныфта укучы кыз полиция хезмәткәрләренә җенси тормыш белән яшәвен сөйләп бирә. Моны табиб-гинеколог тикшерүе дә раслый. Инспекторлардан бу хакта белеп алган әни кеше яман егетләргә җәза бирүне сорап гариза яза, Раил Газетдинов бер үк көнне ике җинаять эше кузгата, дүрт-биш көн эчендә тикшерүне тәгәлләп, 21, 23 яшьләрендәге егетләргә рәсми гаепләү белдереп тә куя. Чөнки җинаять эшләре бер генә эпизодтан тора, ягъни 2021 елның 10 ноябрендә 1999 елгы Д.Рәхимуллин белән аның машинасында якынлык кылына. Хак булса, сөйгән ярының яманатын шул ук көнне чыгара егет, ягъни бу турыда дусты И.Бәйрәмханова җиткерә. Ике атнадан анысы да өлкәннәр рөхсәте белән кыз фатирында кунып кала һәм теләгенә ирешә.

* * *

Балигъ булган ирләр өчен бала-чага белән булган мондый мутлыкларның зур күңелсезлекләргә китерүен раслаучы мисаллар гаять күп. Яңа 18 яшен тутырган Чистай егетенең эше август аенда судка тапшырылды. Зарар күрүче як барысы да кыздан башлангыч ала, аның теләге белән килеп чыга дип А.Юрковны кырыс җәзага тартмауны сораса да, аның берничә елга колониягә китү куркынычы зур.

Быел февраль аенда танышып-дуслашып китә алар. Кыз әнисе белән вакытлы фатирда яши, егет сөйгәне янына шунда килеп йөри. Икесенең әйтүенә караганда, 20 мартта хуҗабикә эштә чакта бер тапкыр якынлык кылалар, тагын ике ай чамасы узгач очрашмый башлыйлар. Укучы бала әлеге аерылышуны авыр кичерә булса кирәк, 16 июньдә, әйтүенчә, ахырына кадәр җиткерелмәгән кыска вакытлы якынлык хакында әнисенә сөйләп бирә. Шул рәвешле, хәбәр полициягә барып җитә. Вакыйганы А.Юрков та шулай ук сурәтли, гаебен тануын белдерә. Экспертиза, гадиләштереп әйткәндә, зарар күрүченең гыйффәтлелеге бозылмаган, әмма җенси мөнәсәбәт булу мөмкинлеге кире кагылмый дигән нәтиҗә ясый.

Тикшерү комитетының Чистай районара бүлегеннән Ленара Гыйбадуллина япь-яшь егеткә 3 тән 10 елга чаклы иректән мәхрүм итү каралган җинаятьтә рәсми гаепләү белдерә.

Наил ВАХИТОВ.

Табигатьне үз иткән иҗатчы

Рәссам Эдуард Хәбибуллин иҗатын яратучылар аның һәрбер пейзажына мөкиббән! Туган як табигатебезне ясамыйча түзә алмыйм, ди рәссам үзе.

Эдуард Хәбибуллин 1972 елда Алабуга шәһәрендә туган. «Әтием Илдус һәм әнием Луиза – иҗатчылар түгел, алар гомер буе төзелеш белән бәйле һөнәрләрдә булдылар, – ди әңгәмәдәшем. – Гаиләдә без дүрт бала үстек. Минем ике абыем һәм сеңлем бар, әмма алар да башка профессияләрдә. Әнием рәсем ясарга һәвәслегемне күреп, Алабуганың 1 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбенә бирде, анда алты ел белем алдым. Аннары Мамадышның 87 нче һөнәр училищесына укырга кердем. Әлеге училищеда «Сәнгати бизәү эшләрен башкаручы» белгече дипломын алдым. Анда хәзер дә бу һөнәргә өйрәтәләр дип беләм...

1990 елда армия сафларына чакырылдым, бер ел – Германиядә, тагы бер ел Кемерово хезмәт итәргә туры килде. Армиядән соң Алабугада бизәү эшләре белән шөгыльләнә башладым. Әмма көннәрдән бер көнне картиналар ясарга алынырмын дигән уй башыма да кермәде...»

«Пейзажларны кайчан ясый башладыгыз соң?» – дим әңгәмәдәшемә. «Чынлыкта, баштан ук пейзажлар гына ясадым. Мин бит сәнгать мәктәбендә дә табигатьне сурәтләргә теләп кенә кергән идем! Табигать күренешләрен бик яратам!

Миңа 26 яшь чагында бер рәссам дустым белән Алабуга автомобиль заводында үз һөнәребез буенча эшли башладык. Ә ул буш вакытларында картиналар иҗат итә иде. Шулай итеп әлеге мавыгуын миңа да «йоктырды». Әүвәл мин картина күчермәләрен генә ясадым. Иҗат юлымны мәшһүр рәссамнар И.И.Шишкин, И.И.Левитан һәм А.К.Саврасов һ.б. әсәрләрен күчереп ясап караудан башладым. Алар яхшы килеп чыкты. 1998 елдан башланган шөгылем инде бу... Ә минем үз картиналарымны исә 2008 елдан алып иҗат итәм. Күпләр ошата. Тик мин тыйнак холыклы... Үземнең «Туган як» дип аталган иң беренче шәхси күргәзмәмне дә Алабуга дәүләт музей-тыюлыгында бары 2012 елда гына ачтым».

Талантлы рәссамны академик сынлы сәнгатьне үтә дә яратучы кытайлар да күреп алган. Рәссамнан үзләренә, күмәк күргәзмә ачу тантанасына килүен дә үтенгәннәр. Тик Эдуард Илдус улы үзе генә чит дәүләткә барудан баш тарткан. 2015 елда Кытайның Шаньдун каласында узган кытай каллиграфиясе һәм сынлы

сәнгать күргәзмәсендә милләттәшебезнең утыз картинасы экспозицияләнгән! 2021 елда үз туган каласының Мәдәният йортында узган шәхси күргәзмәсенә дә халык бик теләп килгән.

Бүгенге көндә Эдуард Хәбибуллин – ирекле рәссам. Аның картиналарындагы детальләштерүләрне күреп сокланмаган кеше юктыр! «Талантыгыз алдында баш иябез!», «Искиткеч хезмәтләр! Картиналарга карагач, сурәттән урман авазларын ишеткән кебек булабыз, урман исен дә сизәбез!», «Нәфис тә, романтик та бу пейзажлар!» дигән бәяләмәләр дә күпне сөйли.

Эдуард Илдус улының картиналары Россия, Кытай, Германия, Австрия, Польша, Чехия, АКШ, Белоруссия, Украина, Төркиядә һ.б. дәүләтләрдәге тупланмаларда саклана. Әлбәттә, мондый детальле пейзажны ясау өчен сабырлык, титаник хезмәт сөючәнлек таләп ителә. Сәләтле рәссамыбызга олуг уңышлар насыйп булсын!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазлаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 2.09.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2800 данә

Заказ 2768

16+